**Ләбиб Лерон**

# Кояшны кочкан малай

Шигырьләр, җырлар, әкиятләр, мәзәкиятләр, шигъри әкиятләр, әкият-пьесалар

КАЗАН
«МӘГАРИФ» НӘШРИЯТЫ
2004

УДК 821.512.145-1/-9-93
ББК 84(2Рос=Тат)6
Л47

Рәссамы
АЛЛА АЙСЕНА

**Лерон Ләбиб**

Кояшны кочкан малай: Шигырьләр, җырлар, әкиятләр, мәзәкиятләр, шигъри әкиятләр, әкият-пьесалар.— Казан: Мәгариф, 2004.— 303 б.

ISBN 5-7761-1327-x

ISBN 5-7761-1327-x

© «Мәгариф» нәшрияты, 2004

# САЛАВАТ КҮПЕРЕНӘ МЕНГӘН МАЛАЙ

*(Әкиятче турында әкият)*

Әүвәл-әүвәл заманда булган, ди, әкияти бер җир. Әби-бабайлар шунда урнашып, аңа Актаныш дигән исем биргәннәр, ди. Әкиятстан дигән бу илдә гел кояшлы яңгырлар яуган, яшел күгендә җиләкләр җемелдәшкән, каеннар аланда чәчәк җыеп йөргән, шүрәлеләре гармун уйнаган, бакалары җырлаган, бүреләре шигырь язган, сыерлары канатланып очып йөргән, ди. Анда яшәүче кешеләр турында әйткән дә юк инде, алар җырлап, шигырь сөйләп кенә аңлашканнар. Кайчандыр ата-бабалары яшәгән Агыйдел, Сөн елгалары буендагы әнә шул могҗизалы илдә Ләбиб исемле бер малай туган, ди. Ул бала чагында бик күп әкиятләр, җырлар тыңлаган. Үсә төшкәч, китапханәдәге барлык китапларны да укып бетергән. Ул гына җитмәгәч, мәктәптәге барлык сыйныфларны тәмамлаган. Инде нишләргә? Бердәнбер көнне зур Идел ягында кояшлы яңгыр явып, күктә салават күпере балкыган. Күзләрен шәһре Казан якларына текәп, малай хыялга бирелгән: анда әле ул тотып карамаган китаплар бихисап, диләр. Капчыгын алган да Ләбиб киткән салават күпереннән атлап Казанга таба. Агыйдел елгасына җитәрәк, аны кемдер куып җиткән, ди. «Мин дә синең белән барам, капчыгыңа мине дә сал, минем дә гыйлемле буласым килә»,— дигән. Бу — әкияткә, хыялга бай Балачак икән. Ләбиб аны да үзе белән алып киткән. Сәләтле егет университетка кергәндә дә аны калдырмаган, капчыгыннан алып, йөрәгенә яшергән. Балачак аның йөрәгеннән шигырьләр, әкиятләр булып чыга башлаган. Ә Ләбибнең күңелендә һаман да салават күпере нурлана, ди. Яшь егет кыюсыз гына «Салават күпере» исемле нәниләр журналының ишеген шакыган, ди. Балачагын туган ягында онытып калдырмаган малайны анда бик яратып кабул иткәннәр, ди.

Шул көннән алып «Салават күпере» журналында Ләбиб Лерон исемле шагыйрь пәйда булган, ди.

Әкиятләр укый торгач,
Тәмам шомардым, малай,
Ошбу әкиятне үзем
Уйлап чыгардым, малай,—

дип, балалар өчен хикмәтле хикәятләр, әкәмәт әкиятләр, шигырь-җырлар, сәхнә мәзәкләре, шалтмылтфильмнар яза башлаган.

Ә язганнары... укып туя алмаслык үзе бер искитмәле кызык китапка әверелгән.

Чыкканчы ук укырга дип, мин аны Ләбибнең үзеннән сорап алдым. Ике көн, ике төн өзелә алмыйча укыдым. Өченче төнне менә шул сүзләрне яздым. Һәм ул бүләк иткән татлы йокысызлыкны сагынып, хикмәтле, саф, кабатланмас балачактан илһамланып, үзем дә шигырь язып куйдым:

Озын буйлы, матур уйлы
Һәм мыеклы абый ул,
Үзе бик җитди булса да,
Бик кызыклы абый ул,
Китап сөйгән һәр баланы
Дусты итеп саный ул.

*Илдар Юзеев,*
Татарстанның халык шагыйре,
Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты.
19 май, 2003 ел.

**ТӨСЛЕ ШИГЫРЬЛӘР**

## ТАТАР БАЛАСЫ

Калфак кигән кыз баланың
Багып алчы йөзенә:
Нинди гүзәл татар кызы! —
Күз тимәсен үзенә.

Килешеп тора түбәтәй
Аның күркәм йөзенә:
Нинди матур татар улы! —
Күз тимәсен үзенә.

Үзе тыйнак, үзе горур,
Хак сүз булыр әйткәне.
Яратыр газиз Ватанны,
Сөяр әткәй-әнкәйне!

Дәү булгач та шулай калыр —
Татар баласы булып.
Әйтерләр:
— Татар кызы бу!
Диярләр:
— Татар улы!

## И ЯМЬЛЕ ДӘ СОҢ ДӨНЬЯ!

Һәр фасыл үзенчә ямьле, әйеме?!

Кыш — ябалак-ябалак булып яуган карлары, агач-куакларны сарган ап-ак бәсләре, дуамал бураннары, тәрәзә пыялаларындагы кар абагалары... белән матур.

Яз — ләйсән яңгырлары, җылы яклардан кайткан кошларның тәүге чыр-чулары, кәгазь көймәле гөрләвекләре, кар эрүгә борын төрткән чирәмнәре, умырзаялары... белән гүзәл.

Җәй — алсу, сусыл җиләкләре, хәтфә үләннәре, исәп-хисапсыз чәчкәләре, талгын гына тирбәлешкән иген кырлары, шифалы, җылы яңгырлары... белән соклангыч.

Көз...

Әйе, көз дә — матур, гүзәл, соклангыч.

Ә-әнә Сентябрь малае, шукланып, агачлардагы алтынсу, сары яфракларны җиргә сибеп йөри...

Ә-әнә Җил малае әлеге яфраклар белән куышлы уйный...

Кояшсылу аларның кыланмышларын сокланып күзәтә. Үзе дә сизмәстән, уенга кушыла...

Ә-әнә чәчәктәй киенгән малайлар һәм кызлар, газиз әти-әниләре, кадерле әби-бабайлары, абый-апалары белән җитәкләшеп, ясле-бакчага, мәктәпкә ашыга. Аларны, Кояшсылу кебек елмаеп, тәрбияче апалар, укытучылар каршы ала...

И ямьле дә соң, күңелле дә соң дөнья!

Шулай бит?!

## ТАТАР ТЕЛЕ ДӘРЕСЕНДӘ

Дамир абый әйтеп тора,
Кабатлап бара Сара:
— Мин барам,
Син барасың,
Ул бара...
Кинәт Сара туктады да
Уңга, сулга карады:
— Аңламыйча калдым,
абый,
Ә без кая барабыз?

## ХӘЕРЛЕ ИРТӘ!

Әтәчтән дә иртәрәк
Уяндым мин, әлбәттә:
— Хәерле иртә, әннәм!
Хәерле иртә, әттәм!

Үзем урын җыям мин,
Үзем юына алам...
— Хәерле иртә, әбкәм!
Хәерле иртә, бабам!

Мәктәпкә үзем барам,
Калалар мине мактап...
— Хәерле иртә, апам!
Хәерле иртә, мәктәп!

## СИЗМИ КАЛГАНБЫЗ...

Җәй узмас, диеп
Уйлаган идек:
Таңнан кичкәчә
Уйнаган идек.

Сизми калганбыз
Көз килгәнен дә,
Тәүге яфраклар
Өзелгәнен дә...

Әле һаман да
Сизмәс идек без,
Көзнең килгәнен
Белмәс идек без —

Кыңгырау чыңы
Искә төшерде:

Көзнең килүен
Шунда төшендек.

## КӨЗГЕ БАКЧАДА

Кагылмыймын алмаларга,
Чәчәкләрне дә өзмим.
Читтән генә, сокланып, мин
Күзәтеп йөрим көзне.

...Әллә инде күзәткәнне
Сизеп, көз миннән качкан?! —
Алма булып елмая ул
Түрдәге алмагачта...

Алмагачтан ары таба
Атламадым карыш та.
Кай арада көз алмадан
Әйләнде көнбагышка?

Сап-сары чуклары җилдә
Җилферди дә җилферди...
Көнбагышын чүпли чыпчык:
«Миңа әзер җимдер»,— ди...

Күрмичә дә калдым көзне —
Яшерде сары чаган...
...Көз, яфракка әверелеп,
Очты күрше бакчага.

## БАКЧАБЫЗДА БЕР БАЛА БАР...

Бакчабызда бер бала бар —
Шундый да ипле инде:
Кайчак әбием әйткәндәй,
Бигрәк тәртипле инде!

Малайлар һәм кызлар белән
Бик әдәпле сөйләшә.
Үзендә булган тәм-томны
Барсына да өләшә.

Көчсезләрне кыерсытмый,
Рәнҗетми ул кызларны...
Ялгыш кына орынса да:
«Гафу ит!» — ди кызарып.
Уйнаганда ул һәммәсен
Көлдерә, шаккаттыра.

Тәрбияче апабыз да
Гел аны мактап тора.

Ул баланың кем икәнен
Син белмисең, мин беләм:
Мактануны белми торган
Ул малай үзем булам!

## БУТАЛМЫШ ИЛЕНДӘ

Буталмыш дигән илдә
Бервакыт булдым мин дә.
Һәм шунда йөргән мәлдә
Мин күрдем мондый хәлләр:

Анда кәҗә:
— Мияу! — ди,
— Му-у! — дип, мәче мияулый...

Сабый әйтә:
— Миһаһай!
— Мһау! Мһау! — ди бахбай...

Анда сыер:
— Мәм-мәм! — ди,
— Микикики! — ди маэмай...

Ә бит бездә бүтәнчә:
Бездә «Мәм-мәм!» — ди мәче...

Туктале, буталдым мин,
Нәрсәдер бутадым мин.
Әйдә, син матур итеп,
Бир әле дөрес әйтеп!

## БУ — КАЙВАКЫТ? ӘЙТ, БАЛАМ!

*(Тукайга ияреп)*

Күз төпләрен угалап,
Кояш уянып килә...
«Кик-ри-күк! Торыгыз!» — дип,
Әтәч куанып көлә.
Кеше эшкә кузгала —
Бу — кайвакыт? Әйт, балам!

Сайрар кошлар «чут» та «чут»

Гөрләшә дә серләшә.
Агачларның яфраклары
Лепер-лепер сөйләшә...
Күктә кояш чайкала —
Бу — кайвакыт? Әйт, балам!

Ак болытлар, кызарып,
Еракларга юл ала.
Биек таулар артына
Кояш кереп югала...
Көн сүрелә кай ара —
Бу — кайвакыт? Әйт, балам!

Тәрәзәдән ай карый,
Йолдызлар җем-җем яна.
Акрын гына, талгын гына
Тынлык иңә дөньяга...
Кеше йокыга тала —
Бу — кайвакыт? Әйт, балам!

## КЫШКЫ СУРӘТ

Бөтерчектәй бөтерелә,
Йә тирбәлә ак карлар...
Кыш — буяучы, табигатьне
Буяп чыккан, акшарлап!

Куе зәңгәр томан булып
Урманга эңгер төшә.
«Җиһан тыныч йокласын»,— дип,
Җил йөри мендәр түшәп...

Чиксезлектә, җем-җем балкып,
Йолдызлар нидер көтә.
Шунда очып китәр сыман
Чыршы — яшел ракета!

Ылыс-канатларда — бәсләр,
Яна әнә елкылдап...
Вакыт безгә алып килә
Яңа ел — яңа китап!

## РАДИОГА САЛКЫН ТИГӘН

Энемнең тавышы беткән —
Көч-хәл белән сөйләшә.
Салкын тигән. Шуңа күрә
Мәтрүшкәле чәй эчә.

...Беркөн безнең радиога
Нидер булды — сөйләми.
Чыжылдый шунда... Йөткерә —
Бер ничек тә көйләнми.

Нишләтергә инде моны
Әйбәт сөйләсен өчен?
Энем әйтә:
«Салкын тигән.
Мәтрүшкәле чәй эчсен!»

## ЧАҢГЫ БЕЛӘН ДУС БУЛСАҢ

Һәр ял көнне тауда шуам,
Рәхәт шул чөнки анда.
Кем белә, бәлки, тиздән мин
Булырмын чемпион да.

Чемпион да булмам, бәлки,
Тик шуны яхшы беләм:
Сырхау һәрчак читтә йөри,
Дус булсаң чаңгы белән.

## КӨЯЛӘЙ

Бияләйгә көя төшкән,
Бияләйне көя тишкән...
Карап торам бияләйгә —
Әверелгән көяләйгә!

## ТЕЛЕВИЗОР КАРАГАНДА

...Бар көченә, әй, йөгерә,
Әй, йөгерә бер кенгерә!
Артыннан һич калышмыйча
Бүре йөгерә.

Сумкасында баласы бар
Кенгерәнең!
Йөгерә-ә-ә...
Бүре тотты дигәндә,
Мин телевизорны сүндереп өлгерәм!

## МИНЕМ БАТЫР КУЯНЫМ

Бу әниләр,
Бу әтиләр,

Бу әбиләр:
— Һәрнәрсәдән курка инде,
Бигрәкләр дә куркак инде,
Куркак инде
Куян! — диләр...
Ә мин менә,
Ә мин менә,
Ә мин менә
Һич ышанмыйм куяннарның,
Шундый йомшак наяннарның
Бигрәк куркак
Икәненә...
Минем әнә,
Минем әнә,
Минем әнә
Өйдә матур куяным бар,
Ап-ак, батыр куяным бар,
Булса да бик
Нәни генә!
Курыкмый ул,
Курыкмый ул,
Курыкмый ул
Минем бармак янавымнан,
Чиертеп алсам танавына
Селкенеп тә
Карамый ул.
Кишер сорап,
Кишер сорап,
Кишер сорап,
Минем кыю, шук куяным —
Минем уенчык куяным! —
Күзләремә
Карап тора.

## ТҮЗМӘДЕМ

Бертуктаусыз — бум да бум!
Бертуктаусыз — дөп тә дөп!
Бертуктаусыз — гөрс тә гөрс!..

Дөрес!
Шушы кадәр бәрүгә,
Шушы кадәр кыйнауга,
Шушы кадәр сугуга
Мин түзә алмас идем...

Ә бу ничек түзәдер?
Ә бу ничек чыдыйдыр?

Ә ул, бәлки, сиздермичә,
Эчтән генә елыйдыр?!

Мин түзмәдем. Үземә:
—Житте! — дидем.— Мин ардым...
Һәм барабан өстенә
Таякларны ташладым...

## ЙӨРИ ТОРГАН УРЫНДЫК

Әтинең киң җилкәсендә
Алмаш-тилмәш утырдык.
Энем әйтә:
— Син, әтием,
Йөри торган урындык!

## ГӨЛЛӘР РӘХМӘТЕ

Мин, сокланып, карап йөрим —
Бүлмә тулы гөлләр белән:
Сез — ничектер, белмим, ә мин...
Мин аларның телен беләм.

Безнең кебек түгел инде —
Үзләренчә сөйләшәләр...
Елмаешып, бер-берсенә:
— Гөлкәем,— дип эндәшәләр.

Ал кояшка карыйлар да:
— Бүген көн бик матур! —диләр...
Алар шулай сөйләшкәндә
Яктырыплар китә өйләр.

— Бик сусадык. Безгә тагын
Сулар сипче, Әхмәт! — диләр...
...Мин су сибәм. Алар миңа,
Чәчәк атып:
— Рәхмәт! — диләр.

## ПЕСИ БУЛСАҢ ИДЕ

*(Охшату)*

Песи булсаң иде хәзер!
Әнә ничек,
Белеп кенә, ял итә...

*Марсель Галиев*

Песиләргә рәхәт тә соң —

Утын ярасы да юк,
Себерәсе юк идән дә,
Суга барасы да юк...

Әни миңа гел эш куша —
Каян таба диген син!
...Ятып кына торыр идем,
Әгәр булсам мин песи.

Әнә безнең песиебез
Җайлап кына менгән дә,
Бөгәрләнеп, мыштым гына
Ята йомшак мендәрдә.

Кара инде бу песинең
Рәхәтләнеп ятуын!..
...Әни миңа тагын дәшә:
— Суга барып кайт, улым!

Песи булсаң иде хәзер,
Ял итеп ятсаң иде;
Төштә генә, бик тиз генә
Су алып кайтсаң иде...

Шулай дидем дә песине
Уяттым йокысыннан:
— Төшеп тор әле, песикәй,
Минем дә йоклыйсым бар!..

Мендәремә башны төрттем —
Шундый ла рәхәт инде!
Әйтсен менә хәзер песи:
— Их, Марсель булсаң иде!

Әйтмәде ул миңа алай,
Ул миңа болай диде:
— Синең белән уйнамыйм мин,
Син — ялкау малай! — диде.

## ХУШ КИЛӘСЕҢ, ЯҢА ЕЛ!

Янә бер ел артта калды,
Калды артта моңаеп...
Ниләр безгә вәгъдә итә? —
Алдыбызда: Яңа ел!

Булыр микән йөзе һәрчак
Кояш кебек гел көләч?

Куандырыр микән безне
Һәрбер көне — ул килгәч?!

Яңа елкай, балкып кил син,
Шатлык белән генә кил:
Әтиләр дә, әниләр дә,
Бабайлар да, әбиләр дә,
Апалар да, абыйлар да,
Һәм, әлбәттә, сабыйлар да —
Сөенсеннәр гелән-гел!
Хуш киләсең, Яңа ел!

## ЯЗ — БӘЙРӘМНӘР ФАСЫЛЫ

Март. Апрель. Май.

Язгы кояшның назлы нурларын тоеп, кыш буена кар астында татлы йокымсыраган үләннәр уяна, бөреләр уяна...

Язның тәүге чәчәге умырзая кояшка елмая, безгә елмая...

Без дә елмаябыз, ямьле яз килгәнгә куанабыз.

Яз. Һава саф. Табигатьтән хуш ис аңкый: үлән исе, бөре исе, чәчәк исе...

Күңелләребездә — бәйрәм хисе.

Әйе-әйе, бәйрәм хисе күңелләребездә. Чөнки яз — бәйрәмнәр фасылы.

## ӘНИ БӘЙРӘМЕ

Айсылу да уянган... Күр:
Бәхтияр дә уянган!
Бишектәге Ләйләгөл дә
Уянганга куанган...

Уянганга, куанганга
Бер сәбәп бардыр әле?!
Бар икән шул... Бүген, бүген...
Бүген — Әни бәйрәме!

Әбинең дә, бабайның да
Авызлары җырылган.
Әти, абый, чәчәк тотып,
Тора табын кырында.

Ник елмая алар бүген?
Белсәң, безгә әйт әле?
— Ник әйтмәскә! Бүген, бүген...
Бүген — Әни бәйрәме!

## КӨЛӘ-КӨЛӘ КЕМ КИЛӘ?

Сыерчыклар булып сайрый-сайрый,
Гөрләвекләр булып җырлый-җырлый
Һәм чәчәкләр булып көлә-көлә,
Җиргә-илгә Апрель килә...

Бөре булып борын төртә-төртә,
Яңгыр булып тәрәз чиртә-чиртә,
Язгы җилләр булып исә-исә,
Назлы кояш булып балкый-балкый,
Күрәсеңме, Апрель атлый...

## АПРЕЛЬ

Апрель, апрель...
Ярсып-кайнап,
Бозлар аккан ай да ул.
Апрель, апрель...
Җылы яктан
Кошлар кайткан ай да ул.

Апрель, апрель...
Чәчкәләрне
Сагынып көткән ай да.
Апрель, апрель...
Халкыбызны
Тукайлы иткән ай да!

Апрель, апрель...
Ләйсән яңгыр
Яуган тәүге яз ае.
Апрель, апрель...
Җан-тәннәрне
Иркәләгән наз ае!

## КОЯШЛЫ ЯҢГЫР

Ява яңгыр...
Күктә — кояш
Һәм салават күпере!
Йөзеп йөри ак болытлар,
Ак күбектәй күпереп.

Ява яңгыр...
Һәммәбез дә
Әй, сөенә, шатлана.
Күк йөзендә алсу кояш,
Җирдә — яшел тантана!
Ява яңгыр...
Әй, сибәли

Җәйнең җылы яңгыры.
Баш очында серле аһәң —
Төсле җырлар яңгырый...

## НӘКЫЯ

Иреннәрен бөрештереп,
Ирек сызгыра белә.
Бармагын авызга кабып,
Барый сызгыра белә...

Ә үземне, үземне —
Әйтеп тә тормыйм инде!

Тик шулай да кайчагында
Мин бик уфтанып куям:
Җилләр чыгарырлык итеп
Бер сызгырса Нәкыя!

Шундый итеп сызгырырга
Каян өйрәнгән диген?
Кемнән өйрәнгән диген?
Кыз башы белән.
Бигрәк инде...
Һе.

## КАЗЛАР ҺӘМ БӘБКӘЛӘР

Каңгылдаша-каңгылдаша,
Казлар үлән йолкыйлар.
Ә бәбкәләр, тәмләп кенә...
Тәмләп кенә... йоклыйлар.

## НӘНИ ДИМӘГЕЗ МИҢА

Нәни димәгез миңа!
Илләр турында уйлыйм,
Җирләр турында уйлыйм мин,
Гөлләр турында уйлыйм.

Нәни димәгез миңа,
Нәни димәгез.

Июньнең бер иртәсендә
Нигә ал таң атмаган?
«Көт. Кайтам»,— дип киткән бабам

Ник сугыштан кайтмаган?

Нәни димәгез миңа,
Нәни димәгез.

Ишетәм мин кайлардадыр
Зар елыйлар нәниләр.
«Берүк сугыш булмасын»,— дип,
Теләк тели әниләр.

Шулар турында уйлыйм мин...
Нәни димәгез миңа,
Нәни димәгез.
Нәни димәгез!

## КОЯШНЫ КОЧКАН МАЛАЙ

Шатланып әни көлә,
Шатланып әти көлә! —
Кояшны кочардай булып,
Тәпиләп малай килә...

Әнисен кочкан малай,
Әтисен кочкан малай...
Ямь-яшел бәпкә үләнен
Учына кыскан малай!

«Ән-нә-нә» дигән була,
«Әт-тә-тә» дигән була...
Кояшка кулларын сузып,
Елмайган, көлгән була...

Төштә генә булса да
Кош булып очкан малай...
...Тәпи-тәпи атлап килә
Кояшны кочкан малай!

## ҖӘЙ КӨТӘ БЕЗНЕ...

Урман, аланнар...
Иркен болыннар...
Чәчәк... Күбәләк...
Нәни колыннар...

Аяз күк йөзе...
Кояш нурлары...
Челтерәп ага
Чишмә сулары.

Хәтфә үләннәр...
Зәңгәр күл буе...
Малай-шалайлар,
Кызлар көлүе...

Яшел Гүзәллек
Җилкетә безне:
Түземсезләнеп,
ҖӘЙ көтә безне!

## СОКЛАНГЫЧ ДӨНЬЯ

Сокланглыч та соң бу дөнья —
Кояшы бар, ае бар...
Чәчәк җыеп йөри сыман
Аланлыкта каеннар...

Үләннәрнең баш очында
Уйный күгелҗем рәшә...
Яшел күктә, йолдызлар күк,
Җиләкләр җемелдәшә...

Күбәләкләр, бөтерелеп,
Чәчәкләргә куналар...
Ак тузганак болытлары
Офыкларга юл ала...

## МИҢЛЕГАТА БОРЧАК АТА

Әй мактана, әй мактана Миңлегата,
Авызыннан бер өзлексез «борчак ата»:
— Курыкмыйм,— ди Миңлегата,— бернидән дә,
Курыкмыйм,— ди,— аюдан да, бүредән дә...

Әйтеп куйды аңа кемдер шул чагында:
— Ләкин, диген, янда әти булса гына!

## ҖИЛ КӨЙМӘСЕ

Ясадым мин ак кәгазьгә
Сап-сары күл рәсемен.
Күл түгел лә,
Чүл рәсемен!
Күрәсезме?!
Ә-ә-әнә сары
Чүл өстендә
Йөзеп бара
Кәгазь көймә...
Сары дулкын,

Сары эзләр,
Суырылып,
Арттан килә.

...Йөзә көймә.
Куркып куям:
«Җилләр күккә чөймәсме?»
Чөйсә чөйсен, димен, аннан,
Ул бит — чүл көймәсе.
Җил көймәсе!

## МӘЧЕ БАЛАЛАРЫ

Бу мәчеләр,
Әллә миннән күрмәкчеләр,—
Койма башына үрмәләп
Менмәкчеләр.
Соң...
Егылып төшсәләр,
Йә
Башларын тишсәләр?..
Аһ!..
Ни буласын әллә инде
Белмиләрме
Бу мәчеләр? —
Койма башына
Һаман
Үрмәләп менмәкчеләр.

Искә төшкәч
Әле генә,
Мин бит менә
Менми торам,
Ни буласын белеп торам.
Шуңа күрә
Эчтән генә
Мәчеләрдән көлеп торам:
Әтиләре генә күрсен —
Колакларын борачак бит,
Кызартканчы борачак —
Аңларлар әле шулчак!

## КОЯШ — ЭНЕМ УЕНЧЫГЫ

Минем энем әйтсәме?
Энем әйтсә — әйтә ул:
— Бир,— ди,— миңа кояшны!
Кояш — минем тәтәй ул!

## САБАН ТУЕ, САБАН ТУЕ...

Әгәренки-мәгәренки,
Көтмәгәндә алай-болай,
Очар тәлинкәдән ялгыш
Төшеп калса берәр малай...
Нинди булыр икән уе —
Күрсә безнең сабан туен?
Ничек алыр сулышкаен
Күрсә әгәр, ике малай
Капчык белән сугышканын?
Күзе челт-мелт итәр микән,
Күргәч, чүлмәк ваткан чакны?
Тынсыз калып торыр микән,
Күргәч, атлар чапкан чакны?
Ниләр уйлар, күрсә әгәр
Капчык киеп йөгергәнне,
Озын колганың очыннан
Чуар әтәч төшергәнне?
Олы-чага, кызый-мызый,
Авызына кашык кабып,
Шул кашыкка күкәй салып
Йөгергәнне күрсә әгәр,
Торыр микән хәйран калып?
...Нәп-нәкъ шулай булыр иде,
Миндәй хәйран калыр иде.

## СӘБӘП НИДӘ?

...Булмады...
Нәкыйп, Нәҗип, Булатны
Тәки җиңеп булмады!
Югыйсә кышлар буе
Таудан кайтып кермәдем;
Булмагандыр болай ук
Чаңгы шуып йөргәнем.
Булмагандыр болай ук
Чанада шууларым.
Акбай белән бергәләп
Куяннар кууларым...

Гер күтәрдем көн саен,
Ныгысын, дип, беләкләр:
Вакыт булмады хәтта
Су ташырга чиләкләп.
Вакыт булмады бер дә
Әнигә булышырга:

Идәннәр себерергә
Һәм казлар куышырга...
Шулай көннәр уздылар,
Җитте сабантуйлары...
Җитте...
Тик малайларны
Тәки егып булмады.
Батыр калып булмады!
...Нигә батыр калмадым,
Нигә җиңәлмәдем мин?—
Беләсезме?!
Сәбәбен
Үзем беләлмадым мин.

## МАРАТ БАРГАН ҖЫЛЫ ЯККА...

Җәйге каникулда чакта,
Ял итәргә быел да
Марат барган җылы якка —
Кара диңгез буена!

Әнисе белән барган ул,
Әтисе белән барган!..
Акулалар тоттым, диеп
Алдашырга шомарган.

Хәзер менә сөйли миңа
Кара диңгез турында.
Минем төшкә дә кермәгән
Матур ташлар кулында...

Сөйли Марат:
— Көне буе
Су коендым мин анда.
Зур-зур балыклар каптырдым,
Йөрдем катамаранда!

Мин дә әйттем:
— Быел җәйдә
Су буенда йөрдем,— дип,—
Тик Кара диңгезне түгел,
Ак диңгезне күрдем,— дип.

Әйттем:
— Көне буе суда
Йөзә алмадым,— диеп,—
Һәм катамараннарда да
Йөри алмадым,— диеп...

— Күрә алмадым шул,— дидем,—

Диңгездәге давылны.
Әйттем: хәтта бармак чаклы
Балык тоталмавымны...

— Чөнки,— дидем,— диңгез бик тә
Салкын иде чамасыз...
Бераз гына коенды тик
Безнең песи баласы.

Ышанмады миңа Марат:
— Алдашасың син,— диде.
Миңа нәрсә?! Ышанмаса,
Бик исем китте инде!

Ә менә песи баласы
Коенды бит! Әлбәттә,
Диңгездә түгел, анысы...
Сөтле зәңгәр чиләктә!

## АВТОБУШЛАР

Циркка бармакчы идек:
Торабыз тукталышта.
Буш автобуслар выж да выж
Узалар туктамыйча.

Әнә тагын бер автобус
Җилдереп узып бара...
Бу юлы да утыралмый
Калырбызмыни карап?..
Китте.
Мин тагын каранам:
«Килмиме автобуслар?»
Энем әйтә:
— Ә соң кая
Китteләр автобушлар?

## КӨЗГЕ КИРӘК

Чәчең матур таралганмы,
Чиста микән йөзең?
Моны белү өчен сиңа,
Әйе, кирәк көзге.
Килешәме кигән кием,
Йөз-кыяфәт ничек?
Әйе-әйе, көзге кирәк
Сиңа моның өчен.
Көзгеләргә күз салмаган
Кеше, әйе, сирәк...

Бу шигырьне уку өчен
Хәтта
Күзге кирәк.

## ҖӘЙГЕ БӘХӘС

Җәйнең ямьле бер көнендә,
Яр буенда — чирәмдә
Өч малай бәхәс куерта
Керми генә тирәнгә...

— Бәхәсләшеп торасы юк,
Җәй — минем җәй! — ди Һашим.—
Җәй көнендә бертуктаусыз
Иң күп җиләк мин ашыйм!

— Булышам әти-әнигә
Печән әзерләшергә...
Шуңа бу җәй — минем җәй! — дип,
Сүзен бирми Бәшир дә.

— Җәй көнендә мин туганмын —
Минем җәй! — ди Фасил да...
...Җәй ул барчабызныкы да,
Уйлап баксаң, асылда.

## БОЛАН БАЛАСЫ

Болан баласы.
Болында болан баласы.
Болында ялгыз болан баласы!
Кайда икән аның анасы?

Болында болан баласы...
Уйный-сикерә болан баласы.
Болын кадәрле болында
Колын кадәрле болан баласы!
Кайда икән аның анасы?

Болында болан баласы...
Кич җиткәнче уйнап каласы.
Кояшкача чабасы да чабасы!..
Болында болан баласы...
Кайда икән аның анасы!

Кеше апалар, Кеше абыйлар!
Күрмәдегезме, белмәдегезме —
Кайда икән аның анасы?
Кайда икән аның газиз анасы?
Табасы иде бит,

Табасы иде бит аның анасын!

Болында...
Ялгыз...
Болан баласы...
Болын баласы...

## БАКАЛАР

Су өстендә бакалар
Чупырдашып яталар.
Качышлымы уйныйлар? —
Калкалар да баталар...
Аргы ярдан малайлар
Балык тотып кайталар.
Күрә алар: бакалар
Калкалар да баталар...
Малайларга, әй, кызык:
Ярга сузылып яталар,
Һәм, «Огонь!» дип кычкырып,
Чуерташлар аталар.
— Мин тидердем!
— Мин! — диеп
Мактанышып аталар.
Ә бакалар, бакалар
Калкалар да баталар...
Арыгачтын малайлар
Атуны туктаталар.
Күрә алар: бакалар
Суда чалкан яталар.

...Башлар түбән иелгән,
Лычма су гел аркалар.
Малайлар, телсез калып,
Су буеннан кайталар...
Күз алдында бакалар
Калкалар да баталар...

## БЕЗ — ТАБИГАТЬ БАЛАСЫ

Рәсем ясыйм ак кәгазьгә
Төсле буяулар белән:
Юлбарысны ясап куйдым
Төлке-куяннар белән.

Рәсемемдә тычкан белән
Аю бии бергәләп.
Бал кортлары очып йөри,
Канат җилпи күбәләк.

Мәтәлчек атып уйныйлар
Мәче, керпе, арыслан...
Ташбакалар, пыр туздырып,
Атлар белән ярыша!

Рәсемемдә кошлар сайрый,
Чикерткәләр сикерә.
Балык малайлары белән
Күлдә кәҗә су керә.
Үзе кадәр йөк күтәргән
Бер кырмыска малае.
Маймыл, аңа караган да,
Кашып тора маңгаен...

Үземне дә, дусларны да
Сыйдырдым мин рәсемгә:
Юан гәүдәле булса да,
Сыйды хәтта Рәсим дә!

...Ак кәгазьгә сыйган кадәр
Ясагачтын барсын да,
«Без — табигать баласы!» — дип
Яздым рәсем астына.

## ЯҢГЫРНЫҢ ЯЛ КӨНЕ

Уф! Ардым!..
Инде бер атна бардыр —
Ява да ява яңгыр,
Ява да ява яңгыр...

Дүшәмбе — яшенләде.
Сишәмбе — сибәләде...
Чәршәмбе — койды гына!
Пәнҗешәмбе — чиләкләп...
Җомга көн — төшкә кадәр...
Шимбә көн кичкә кадәр
Яуды да яуды яңгыр,
Яуды да яуды яңгыр!

Бүген менә — якшәмбе.
Инде кич җитеп килә.
Иртәдән бирле күктә
Кояш елмая, көлә...
...Кер бавына әнием
Кибәргә керләр элә...

## СВЕТОФОР — ТӘМЛЕТАМАК?!

Светофордан
Сорадым бүген:
— Нигә кып-кызыл
Синең бер күзең?

Елмаеп, миңа
Ул болай диде:
— Кызыл помидор
Ашаган идем...

Светофордан
Сорадым тагы:
— Икенче күзең
Нигә сап-сары?

Елмаеп, янә
Ул болай диде:
— Иртән лимонлап
Чәй эчкән идем...

Сорамый тагы
Буламы түзеп:
— Нигә ямь-яшел
Өченче күзең?

Балкып елмайды
Һәм әйтте аннан:
— Ашаган идем
Ямь-яшел алма...

Шаярта ла ул —
Беләм ич инде!
...Шулай да торам
Ялмап ирнемне.

## МИЛИЦИОНЕР АБЫЙ

Кайчандыр ул безнең кебек
Булган шаян бер сабый.
Хәзер инде дәү кеше ул —
Милиционер абый!
Үскән ул да китап укып,
Кинолар карый-карый...
Хыялый сабый булган ул
Милиционер абый.
Сораганнар аннан:
— Үскәч,
Кем буласың син, сабый?
Чатнатып җавап биргән ул:

— Милиционер абый!
Һәм өстәгән: «Килә минем
Кыю, батыр буласым...
Аннары соң килә тагын
Тәртипсез малайларның
Колакларын борасым!..»

Кайчандыр ул безнең кебек
Булган шаян бер сабый.
Хәзер инде дәү кеше ул —
Милиционер абый.
Өлкәннәр дә, балалар да
Аны ерактан таный:
Яхшы кешеләр дусты ул,
Явызларның дошманы!
Хәзер инде дәү абый ул —
Милиционер абый!
...Ул кайчандыр сабый булган,
Без дә әлегә сабый.

## ҮРДӘК ХЫЯЛЫ

Үрдәк әйтә:
— Бак-бак-бак!
Күлдә балык вак-вак-вак!
Эре булсын — күл тулсын,
Авызга кереп торсын!

## САРУТ

«Чүп үләне» диеп кенә
Уйлый күпләр — беләм мин.
Белмәгәннәр өчен әйтәм:
Бик файдалы үлән мин.

Дару да мин, ризык та мин —
Булганда ак тамырым...
— Татлы тамыр миндә ул! — дип,
Мин сезгә мактанырмын.

## ӘНИС

Әнисә әнис җыйган,
Әнис тә әнис җыйган,
Фәнисә әнис җыйган,
Фәнис тә әнис җыйган...
Алар җыйган әнисне
Әнисәнең әнисе
Һәм Әниснең әнисе,

Фәнисәнең әнисе
Һәм Фәниснең әнисе
Сибәр бәлеш эченә
Йә бәрәңге өстенә...
Өйгә шулчак әниснең
Әй, таралыр хуш исе!

## КУЯННАР САНАМЫШЫ

Бер, ике, өч...
Куяннарда бөтен көч!
Дүрт, биш...
Безне җиңеп булмый һич!
Алты, җиде...
Куркаклар башын иде!
Сигез, тугыз, ун...
Алты бүре — алты тун!
Без тук бүген, бүре ач —
Әнә килә, тизрәк кач!..

## АЧУЛАНДЫМ

Бик шуклансам, йә булмаса,
Тәртип боза башласам,
Уенчык машиналарымны
Пыр туздырып ташласам,
Әтием дә, әнием дә,
Бабам белән әбием дә:
— Бик шаян син, Айдар,— диләр,
— Бик наян син, Айдар,— диләр.
— Ул кадәрле шуклыкларны
Табасың син кайдан? — диләр.

Ни диим, белмим үзем дә...
Бер көнне түздем-түздем дә:
— Яхшылыкка, пөхтәлеккә
Ничек кенә өйрәтим мин? —
Дия-дия, ачуландым
Көзгедәге сурәтемне.

## САРАВАТТА КЕМ ЯТА?

*(Буталмыш)*

Йә, әйтегез, нәрсә ул — КА?
Йә, әйтегез, нәрсә ул — РА?
Йә, әйтегез, нәрсә ул — ВАТ?
Әйе, дөрес, ул — КАРАВАТ!
Ә хәзер, йә, әйтегез:

Нәрсә ул — СА?
Нәрсә ул — ЛА?
Нәрсә ул — ВАТ?
Әйе, әйе, «нәрсә» түгел,
Ә «кем», ягъни САЛАВАТ!
Йә, әйтегез инде хәзер:
САЛАВАТта кем ята?
Юк ла инде, ялгыш әйттем...
САРАВАТта кем ята?
Тьфү! Тагын ялгыш әйттем...
КАЛАВАТта кем ята?
— САРАВАТ!
Ә кем соң ул — САРАВАТ?
Кая китте САЛАВАТ?

## БУЛЫШЧЫ

Хәтерли ул бик яхшы:
«Әбигә булышкан бар,
Әтигә булышкан бар...
Әни идән юганда
Идән дә юышкан бар...»

Бүген менә Ләйләгә
Булышып алды әле:
— Аз кабам! — дип алгачтын,
Кабак чаклы алмасын
Сыпырып салды әле!
Алмадан соң аннары
Чиясе дә калмады,
Кәнфите дә калмады...
Ләйлә дә тик тормады —
Иреннәрен ялмады.
Менә шул.

## КЕМ БӘХЕТЛЕ?

Нилнең бар агач аты:
Ул гел шуңа атлана.
Маэмае да бар Нилнең,
Шуның белән мактана.

Попугае, мәчесе,
Пианиносы да бар...
Юк әйбере генә юк —
Өендә барсы да бар!

— Мин синнән бәхетлерәк! —

Диде шулчак Гыйлемдар.
— Ничек инде? — диде Нил.
— Чөнки минем энем бар!

## ҮЗЕНӘ ОХШАГАН

Айсылу аптырады:
Җыр да җырлап карады,
Сөйләде әкият тә,
Биеп күрсәтте хәтта!

Айсылу аптырады:
Бармак янап карады,
«Кәнфит бирмим бүтән»,— дип
Ачуланып карады...

Юк, курчагы тыңламый —
Йокламый да йокламый!

...Охшаса охшар икән
Айсылуга шулчаклы:
Айсылу йокламыйча,
Йокламады курчагы.

## ГАҖӘП ХӘЛЛӘР

Мәзәкнең дә мәзәге,
Кызыкның да кызыгы:
Су буенда — комлыкта
Әби ята кызынып!

Әкәмәт тә әкәмәт:
Шатлыгыннан кычкырып,
Су эчендә — сай җирдә
Бабай ята пычтырдап!

Гаҗәпнең дә гаҗәбе,
Хикмәтнең дә хикмәте:
Чирәмлектә, комлыкта
Мәтәлчек ата әти!

Искитмәле тамаша
Булыр икән шулчаклы:
Башка әниләр белән
Әни уйный курчаклы!

Ә мин... Ә мин... Мин менә,
Чыдый алмыйча, көлеп,
Утырам шул хәлләрне
Күз алдына китереп.

## АРЫГАН МАЛАЙ ЗАРЫ

Бүген бик нык арылды.
Иртә-таңнан торылып,
Күл буена барылды...

Каз тәннәре чыкканчы
Су чәчрәтеп йөзелде...
Күлмәк-ыштаннар белән
Чукмарбашлар сөзелде...
Маймыч тота язганда
Ыштан бавы өзелде...

Әйе, бүген арылды...
Су читендә чупылдап,
Бөтен өс-баш каралды...
Кичәге күк, бүген дә
Бик соң гына таралдык...
Бүген, әйе, арылды...
Өйгә кайтып җиткәнче
Җитмеш тапкыр абындым...
Туксан тапкыр төшердем
Юынганда сабынны...

Хәлем юк һич, юк хәлем —
Арылды шул нык кына...
Калса калгандыр хәлем
Кашык тотарлык кына...
Берәр миски ботканы
Кабып йотарлык кына...
Үземнең урыныма
Барып ятарлык кына...
Хыр... Хыр...

## АВГУСТКА КЕРЕП БАРАБЫЗ...

Сау бул, июль —
Җиләкле юл!
Саумы, август —
Алмалы дус!

Сез менә безне күрегез,
Сез менә безгә карагыз! —
Кояш белән җитәкләшеп,
Августка кереп барабыз...

Баллы алма, ал баланнар
Янып тора көмеш чыктан.

Яшел алан, чәчәк тотып,
Каршыларга йөгереп чыккан!

...Августка кереп барабыз
Җир җылысын тоеп кына,
Ярсып чапкан яшел яллы
Җәй-толпарны тыеп кына...

## БӨТЕРЧЕК ҖЫРЛАР

### БИШЕК ҖЫРЫ

*(Татар халык көе, Разыя Еникеева эшкәртүендә)*

Әлли-бәлли, бәбкәсе,
Кая киткән әнкәсе?
Каенлыкка, җиләккә,
Айсылуга бүләккә.

Әлли-бәлли, бәбкәсе,
Кая киткән әткәсе?
Тимерчегә, чиләккә,
Айсылуга бүләккә.

Әлли-бәлли, бәбкәсе,
Кая киткән әбкәсе?
Тегүчегә, күлмәккә,
Айсылуга бүләккә.

Әлли-бәлли, бәбкәсе,
Кая киткән бабасы?
Чүлмәкчегә, чүлмәккә,
Айсылуга бүләккә.

Әлли-бәлли, бәбкәсе,
Кая киткән Айсылу?
Бер кая да китмәгән —
Йоклап киткән Айсылу...

### ЧУМА ҮРДӘК, ЧУМА КАЗ

*(Татар халык көе, Разыя Еникеева эшкәртүендә)*

Чума үрдәк, чума каз,
Агым суны ярата шул, ярата.
Чупырдашып алар суда
Дулкыннарны тарата шул, тарата.

Чума үрдәк, чума каз,
Алар шулай коена шул, коена.
Күк йөзендә алсу кояш —
Аннан нурлар коела шул, коела.

Чума үрдәк, чума каз,
Канатларын кагына шул, кагына.
Йөзеп китте каз-үрдәкләр

Суның аргы ягына шул, ягына.

Чума үрдәк, чума каз,
Йөзә-чума уйныйлар шул, уйныйлар.
Су чәчрәтә каз-үрдәкләр,
Уйнап һич тә туймыйлар шул, туймыйлар.

## ЗӨҺРӘ КЫЗ

*(Фәннүр Галимов көе)*

Төнбоеклы төнге күлдә
Сары көймә —
Ай йөзә...
Ул көймәдә Зөһрә гүзәл —
Бигрәк нурлы, һай, йөзе!

Иңсәсендә көянтәсе,
Көянтәдә — чиләкләр.
Зөһрә кызның күңелендә
Нинди уйлар, теләкләр?

Төн. Күл. Көймә.
Тынып калган
Көндезге шау, чыр-чулар...
Зөһрә гүзәл, суга карап,
Салмак кына җыр суза:

— Ай-көймәмдә төн дә
йөзәм —
Серләрен күл ачмасмы?
Йөрәктәге сагышларны
Төнге сулар басмасмы?..

## КЕРПЕ ШАТЛЫГЫ

*(Разыя Еникеева көе)*

Бүген дә иртән уянды Керпе.
Һәм юынгычка су салды Керпе.
Бик әйбәт итеп юынганнан соң,
Алмагачлыкка юл алды Керпе.

Алмагачларда — хисапсыз алма:
Яшеле дә бар, бик күп алы да...
Уйлана Керпе, аптырап тора:
— Бу алмаларны ничек алырга? —

Шулвакыт, кинәт, яман сызгырып,

Алмагачлыкта көчле җил исте...
Алмалар җиргә коелган чакта
Керпе башына бер алма төште.

Җил-давыл тынды, балкыды кояш.
Керпе, шатланып, җыйды алмалар:
Тырысы тулды, аркасында да
Алма сыярлык урын калмады.

## ҖИЛӘКЛӘР

*(Разыя Еникеева көе)*

Аланнарда җиләк бар,
Кулларымда чиләк бар.
Җыйдым, җыйдым
җиләкләр —
Бик тиз тулды чиләкләр.

Аланнарда җиләк күп,
Минем бүтән чиләк юк.
Нишлим икән?
Берегез
Берәр киңәш бирегез.

Аланнарда җиләк бар,
Кирәкми лә чиләкләр...
Таптым инде җаен мин —
Авызыма җыямын!

## КӨЧЕГЕМ

*(Зиннур Гыйбадулла көе)*

Көчек алды әтием,
Исем дә куштык: Тиен.
— Һау-һау-һау! — дип
Йөгереп килә,
Койрыкларын болгый-
болгый...
Әй көчегем,
Яратам сине!
Тәти аның йөзләре,
Янып тора күзләре...
— Һау-һау-һау! — дип
Йөгереп килә,
Кочагыма сикереп
менә...

Әй көчегем,
Яратам сине!

Тиктормас ул, шаян ул,
Шуклык алган каян ул?
— Һау-һау-һау! — дип
Йөгереп килә,
Песи белән уйный бергә.
Әй көчегем,
Яратам сине!

## КҮБӘЛӘК

*(Разыя Еникеева көе)*

Болыннарда күп алар,
Чәчәкләргә куналар...
Үзләрен һич шәйләп
булмый —
Чәчәк төсле шул алар!

Күбәләкләр — шаяннар...
Чәчәкләр дә наяннар:
Күрми калам, күбәләкне
Яшерәләр кай ара?..

Күбәләгем-күбәләк,
Уйныйк, әйдә, бергәләп! —
Качма, качма, курыкма син —
Очкалап та йөргәлә!

## ЯФРАК БӘЙРӘМЕ

*(Разыя Еникеева көе)*

Яңгыр түгел, кар да түгел,
Яфраклар ява җиргә.
Көз турында
җырлыйм әле —
Кушыл син яңа җырга.

Кушымта:

Сары, сары, сап-сары
Агачның яфраклары.
Җил исә, ява яфрак —
Көзнең матур чаклары.

Оча яфрак, уйный

яфрак,
Һаваларда әйләнеп.
Бүген, бүген, бүген, бүген
Яфракларның бәйрәме!

Кушымта:

Сары, сары, сап-сары
Агачның яфраклары.
Җил исә, ява яфрак —
Күзнең матур чаклары.

## ТАУДА

*(Разыя Еникеева көе)*

Күңелле безнең тауда —
Киттем чана шуарга...
Күр, чанада җилдерәм —
Узышамын җил белән!

Чү! Нәрсә бу? Ни булды? —
Йөземә кар сибелде...
Ятам тауда чарасыз —
Ятам карда чанасыз.

## ШИГЪРИ ӘКИЯТЛӘР

### АКМАМЫК ҺӘМ УЛБАЙАДАШ

**I**

Әле мин булмаганда,
Әле син булмаганда,
Озынколак куяннар
Качышлы уйнаганнар.
Әбәкле уйнаганнар,
Чәбәкле уйнаганнар...
Уйнап һич туймаганнар!

Әтәчтән дә иртәрәк
Йокыдан торган алар.
Шуңадырмы барсы да
Бик матур булган алар!
Бик батыр булган алар!
Матурлар арасында,
Батырлар арасында
Булган икән бер куян —
Акмамык дигән куян —
Матурның да матуры,
Батырның да батыры!

...Бервакыт шул Акмамык
Шундый батырлык
кылган:
Йоклап яткан бүренең
Борын төбеннән шылган!

Шуннан шул, бу бер
чакны,
Курыкмыйча бер тамчы,
Дәү үләннәрне ерып
Чапканда тырык-тырык,
Хәтта үз күләгәсен
Калдырган адаштырып!

Менә шундый булган
ул!
Ул шул — батыр булган
шул!
Беркөн, гадәттәгечә,
Иртән, сәгать уннарда,

Җыелганнар куяннар
Качыш-качыш уйнарга.

Берсе эзләүче булган,
Ә калганнар качканнар —
Йә куаклык артына,
Йә үләнгә посканнар.
Акмамык та тиз генә
Элдерткән бер тарафка.
Ул шул — батыр куян
шул...
Еракка китеп качкан...

**II**

Яшәгән шул заманда —
Әле мин булмаганда,
Әле син тумаганда —
Бер малай — Улбайадаш.
Исеме сәер, име?!
Ник Марат түгел инде?
Ник Азат түгел инде?
Ничек шәп булыр иде,
Исеме булса — Идел!
Яисә Илдар, йә Вилдар...
Яисә Айдар, Гыйлемдар!
Ә?! Әйе шул, ул чакта
Исемнәр шулай булган —
Ул чактагы кешеләргә
Әйтергә кулай булган.
Һәрхәлдә, шулай
булган...

Исем турында җитәр —
Күпкәрәк китте бугай,
Мин бит әкиятемнән
Читкәрәк киттем бугай...
Менә шул Улбайадаш
Бик куркак малай
булган.
Шундый-шундый заманда
да
Ничек ул алай булган?!
Мәчедән дә курыккан,
Курыккан чебидән дә.
Күбәләктән курыккан,
Курыккан чебеннән дә!

«Кит инде, шундый
малай

Булмас!» — дисездер инде.
Сезнең кебек башта
шулай
Уйлаган идем мин дә.
Беркөнне Улбайадаш
Чыккан икән урамга.
Бер черкине күргән дә:
«Үләм, тешли!» — дигән
дә,
Йөгергән ул урманга.

Аның шулай чапканын
Бөҗәкләр күргәләгән.
Килүгә, малай биек
Агачка үрмәләгән...

**III**

Батыр куян Акмамык
Чабып килеп бар тыннан,
Нәкъ менә шул агачның
Поскан икән артына.
Килеп поскан посуын,
Тик үкенгән соңыннан...
Үкенүдән ни файда,
Ул чакта шул соң булган!
Куян килеп посканын
Күзәтеп торган малай,
Куркуданмы, нидәндер,
Егылып төшкән... малай!..

Акмамык, коты очып:
— Юлбасар! — дип
кычкырган.
Исен-акылын җыеп,
Шундук моннан
ычкынган...

Батыр куян артыннан
Чапкан башка куяннар;
Шактый ара узгачтын,
Җиңел сулап, алгач тын:
— Котылдык! — дип
куйганнар...

Ә... безнең Улбайадаш
Аптырап торган икән:
— Белмәгәнмен, миннән дә
Куркаклар булган икән...

Ул шулай аптыраган,
Шуннан ул батырайган.
Батырланганга микән —
Ул шундый матурайган!
Урмандагы бу хәлне
Җилләр сөйләгән көлеп,
Улбайадаш авылга
Кайтып җитмәстән элек.

Шуннан бирле дөньяда
Куркак икән куяннар.
Малайлар батыр икән.
Малайлар матур икән.
Менә шул.

## КӘҖӘ БЕЛӘН САРЫК

*(Мәгълүм әкияткә дәвам)*

«Кәҗә-Сарык әкияте» сиңа таныш;
Шуңа да мин кабат сөйләп тормыйм аны.
Хәтереңә төшерәмен тик ахырын,
Игътибарлы булып тыңла син, бахырым:

«...Иртә белән иртүк торып таң аткач ук,
Кулларында бүре башы салган капчык,
Кәҗә, Сарык урман буйлап сәфәр итте,—
Нәрсә языйм? Хикәям дә шунда бетте».

Сизәсеңме, әйтелмәгән һич ни анык:
Сәфәр иткән... Кая киткән Кәҗә, Сарык?
Син белмисең, ул да белми, ә мин беләм
Һәм шул хакта хәзер сиңа сөйләп бирәм...

...Кәҗә, Сарык урман буйлап сәфәр итте:
Китте болар, китте болар, китте, китте...
Бара торгач, бер көн үтте, бер төн үтте,—
Менә болар бер базарга барып җитте.

Җәнлек-җанвар, кош-корт белән базар тулган,
Кычкыралар әле уңнан, әле сулдан.

— Сатам,— диләр,— чит илский салам! — диләр...
— Чит илский булгач, әйдә, алам! — диләр...

— Гөмбә сатам! Җиләк сатам! Алма! — диләр...
— Минекен ал! Син аныкын алма! — диләр...

— Бәлеш сатам, бәлеш! — дип тә кычкыралар...
Аһ итәләр, уфылдыйлар, төчкерәләр...

Тамаша күк: бөтен базар шау-гөр килә —
Берәү җырлый, берәү бии, берәү көлә!..

Гаҗәпләнеп, исләр китеп, хәйран калып,
Байтак вакыт карап торды Кәҗә, Сарык.

Шулчак әйтте Кәҗә иптәш: «Дустым, Сарык!
Әйдә, без дә бүре башын сатып карыйк!
Сата алсак, акчабыз да булыр иде...»
Гадәтенчә, Сарык иптәш шүрли инде.

Әйтә Сарык: «Юк, юк, сатмыйк! Куркам, иптәш...»
Әйтеп карый: «Вакыт узар юкка!» — дип тә...

Ахыр чиктә Сарык иптәш ризалашты.
Һәм капчыктан алды болар бүре башы.

Бар базарга яңгырады Кәҗә таушы:
— Йә, кем ала? Без сатабыз бүре башы!..

Кинәт шулчак базар халкы калды тынып:
Карый алар бу тарафка, онытылып.

Бүре башын күргәч, барсы аһлар итте:
Берничәсе шундук артка авып китте.

Күзен шардай итеп ачкан өнсез халык:
Шулай шактый торды алар телсез калып.

Шунда берсе: «Качыгыз!» — дип сөрән салды...
«Ә» дигәнче бөтен базар бушап калды.

Калды ризык, калды кием — өем-өем:
Күлмәк-ыштан, кәчтүм-чалбар... Ал да киен!..
Кәҗә белән Сарык иптәш аптыраشта:
«Ничек килде мондый бәхет безнең башка?»

Мәгълүм инде, болар бик нык сөенделәр,
Икесе дә өр-яңадан киенделәр.

Кәҗә иптәш ак эшләпә киеп алды,
Шатлыгыннан тыпыр-тыпыр биеп алды.

Таман булды Сарыкның да эшләпәсе...
Яраттылар эшләпәне... Нишләтәсең!..

Ачтылар да капчык аузын, шуннан болар
Бар нәрсәне ипләп кенә тутырдылар.

Аннан өйгә таба юлны алды болар
(Бүре башын җиргә күмеп калдырдылар).

Кайта Кәҗә, кайта Сарык өйгә таба —
Икәве дә җырлый-җырлый атлый-чаба.

Атлау-чабу җиңел түгел — капчык авыр...
Менә бер мәл пәйда булды таныш авыл.

Арып-талып кайтып җитте болар икәү,—
Каршы алды Хуҗа белән Хуҗабикә.

Сөенеште инде болар һәммәсе дә:
Куанышты хәтта Акбай һәм мәче дә!

Ошбу өйдә өч көн, өч төн бәйрәм булды:
Ашау — бәлеш, эчкәннәре әйрән булды.

Ул табында мин дә ризык авыз иттем,
Бүген бардым, кичә иртән кайтып җиттем.

## АУЧЫ БАРЫЙ

Киләчәкне үткәндә,
Үткәннәргә җиткәндә,
Кышын авыр арбага
Яшь таракан җиккәндә,
Сукыр тычкан, әлсерәп,
Бозда иген иккәндә
Яши иде бер малай —
Буе булыр колгадай!
Яши иде, бар иде,
Исеме Барый иде.
Байтак агач тураклап,
Төзлеген карый-карый,
Мылтык ясады шәпләп
Менә шул Колга Барый.
Бер мылтыкка исәпсез
Агачлар кереп китте...
Тәки Барый мылтыгын
Алты көпшәле итте!
Көпшәләр «шәп» —
һәрбере
Кәкере дә бөкере...
Бер көпшә уңга карый,
Ә берсе сулга карый,
Икесе өскә карый,
Калганы аска карый.
Җеп булгангамы бавы —
Мылтыгы шактый авыр:
Көчкә күтәрде Барый,—
Гайрәт бар, әле ярый!

Бүрттерелгән борчаклар
Кесәгә салды Барый.
Кирәге чыгар, диеп
Тары да алды Барый.
Ау өчен ниләр кирәк —
Барын да салды Барый.
Көннәр суык торганга,
Төренде ул юрганга.
Сырган чалбар кигәндә
Сыгылдылар идәннәр.
Башына элде бүрек —
Чыпчыклар көлде күреп.
Аякка киде ката —
Атлаган саен бата.
Сыңар бияләй киде,
Ансы да тишек иде.
Сынса да сынар икән —
Чаңгы да сыңар икән.
Төш вакыты узганда
Китте Барый урманга:
Сыңар чаңгысын сөйрәп,
Авыз эченнән көйләп.
Урман юлы — көрт тә
көрт.
Барый бара керт тә керт.
Шулай сыңар чаңгыда
Атлап-шуган чагында,
Күр, кашына-кашына,
Аю чыкты каршына!
Кыш буе йоклар чакта,
Йокысын бүсәр чакта
Урманда нишләп йөри —
Ни калган Аюзатка?
Барый мылтык төзәде,
Дер-дер килде тезләре.
Ап-ак булды йөзләре,
Шакмак булды күзләре.
Аю, шәрран акырып,
Төртеп екты Барыйны.
Аучы хәтле аучыны
Шулай егу ярыймы?
Аю китте кашынып,
Барыйга карый-карый...
Юрганына чорналып,
Торалмый ятты Барый.
Көч-хәл белән торгачтын,
Әз-мәз сулыш алгачтын,
Барый киде бүреген

Һәм кинәт ул дерт итте —
Күреп алды бүрене!
Мылтык күргәч,
куркудан,
Бүре качты уң якка.
Бүре күргәч, шүрләүдән,
Барый качты сул якка...
Шактый кар ерды Барый,
Адашып йөрде Барый:
Сыңар гына булса да
Чаңгы бар, әле ярый.
Шулай йөргән чагында
Юлыкты ул төлкегә:
Барый тайды тиз генә,
Калганчы, дип, көлкегә.
Күргән иде боланны —
Барый хәтле Барыйның
Уттай кызды колагы!
Күргәч ялгыз пошины,
Тары атмакчы булды —
Кесә генә буш иде.
Аю еккан чагында,
Төшеп калган тарысы,
Борчагы да — барысы.
Шулай итеп, мылтыгы
Тары да аталмады,
Борчак та аталмады...
Табыш белән аучыбыз
Өенә кайталмады.
...Җанып-пешеп,
әлсерәп,
Мылтык һәм чаңгы
сөйрәп,
Сөйрәп калын юрганын,
Барый өйгә юл алды.
Арган-талган хәлендә,
Шулай кайткан мәлендә
Күреп алды куян ул —
Фил кадәрле куянны!
Безнең аучыбыз Барый
Шундый-шундый
куанды!..
...Һәм йокыдан уянды.

## КЫРЛАЙ ЮЛЫ ТАП-ТАКЫР...

Ямьле яз иде микән,

Әллә җәй иде микән...
Син — теркелдәп, мин —
җәяү
Кырлайга киттек икәү.

Ул вакытта син — абый,
Мин сабый идем бугай.
Син аякка — чабата,
Мин ката кидем бугай...

Көн аяз, якты иде,
Болыт та шактый иде.

Кояш кыздыра иде,
Җилләр сызгыра иде.
Малай-шалайлар ләмдә
Тузан туздыра иде.

Яңгыр сибәли иде —
Җиргә тигәли иде.
Әлсерәгән агачлар
Башын игәли иде.

Син атлыйсың, мин
чабам —
Ут кебек кызды табан.

Кырлай юлы тап-такыр,
Күрсә — һәркем
шаккатыр:
Көзге кебек шоп-шома —
Җәяү бару шәп шуңа!

Син шыңшыйсың, мин
җырлыйм —
Мин бик оста җырларга.
Атлый-атлый
йоклыйсың —
Син дә оста гырларга.

Син карыйсың басуга,
Мин карыймын
кырларга...
Шулай бара торгачтын,
Килеп җиттек Кырлайга!

Сине күргәч, мәчеләр
Тотындылар мырларга.
Мине күргәч, тавыклар
Тотындылар җырларга...

Дөрес икән: Кырлайда
Тавыклар да җырлыйлар.
Дөрес икән: әтәчләр —
Һәммәсе дә кәпәчтән.
Дөрес икән: чебиләр
Чели генә чемлиләр!..

Монда гаҗәп тамаша:
Биеп йөри алаша!

Капкадагы ярыктан
Такмак сөйли сарыклар.

Үгезләр дә тик тормый —
Мөгез белән җир тырмый.
Мәче мәтәлчек ата,
Бер тычкан чинап ята.

Бер үрдәк балык тоткан,
Эт аны кабып йоткан.
Казлар суда чупырдый,
Атлар комда тупырдый.

Яңа туган колыннар
Чәчәк җыя болында...
Кыскасы, гаҗәп инде,
Үзе бер мәзәк инде!

Шуннан ары киттек без —
Су буенда йөрдек без.
Шунда йөргән чагында...
Су анасын күрдек без!

Ул шундый матур иде,
Ул шундый гүзәл иде...
Күзләрен дә күрдек без —
Зәп-зәңгәр күзләр иде.

Су анасы басмада
Чәчләрен тарый иде.
Тарагы — алтын тарак! —
Урласаң ярый иде.

Күзәттек без шым гына
Агачлар арасыннан:
Таракны чәлдерергә
Җыенган малай сыман...

Ләкин без урламадык —
Без андый малай түгел.

Кызыксак та тимибез —
Без сантый малай түгел.

Алтын тарак ялт итте,
Алтын тарак йолт итте.
Суда көмеш балыклар
Чуп итте дә чулт итте.

Чәчен тарап бетергәч,
Су анасы, тиз генә,
Алан-йолан каранды
Һәм чумды су төбенә.

Ис җыялмый тордык без,
Күзне-күзгә карашып:
Минем авыз йомылган,
Синең авыз — шар ачык.

Синең авыз йомылгач,
Су буеннан кузгалдык.
Син — мышкылдап,
мин — җырлап,
Карурманга юл алдык.

Барабыз такыр юлдан —
Каршыга килә урман.

«Керим әле урманга...» —
Дип җырлыйм мин шәп
итеп...
Кинәт синең башыңа
Керпе төште шап итеп!

Юк ла, керпе түгел лә,
Нарат күркәсе икән...
«Керпе һөҗүм итте!»—
дип,
Юкка куркасың икән...

Үгез кебек үкереп,
Син ятасың чирәмдә.
Ә мин, сине юатып,
Әйләнәмен тирәңдә.

Сине шактый юаткач,
Җылавыңнан туктаткач,
Ары китеп бардык без,
Бара-бара ардык без.

Бара-бара арганда,
Ара-ара барганда,

Туктарга уйладык без,
Юлыгып бер аланга.

Аланның уртасында
Учак ягылган иде.
Пыскып янган учакка
Казан асылган иде.

Өсте ачык казаннан
Аш исе килеп китте.
Аш түгел, ботка икән —
Ашыйсы килеп китте.

Тәмле ботка исенә
Түзеп-чыдап буламы? —
Кашыклап һәм чүмечләп
Ялт иттердек без аны.

Состык кына ботканы —
Эчләребез бүлтәйде...
Шулчак искә төшердек
Хөббениса түтәйне.
Ул да ботканы шулай
Тәмле пешерә иде:
Казанны кырган чакта,
Төбен төшерә идек...

Ай-яй каты ашадык —
Сыптырдык та урдык без:
Кузгалалмый урыннан
Байтак басып тордык без...

Иң гаҗәбе бу түгел...
Шул булды иң гаҗәбе:
Күреп алдык бер читтә
Йоклап яткан Кәҗәне!

Сарыкны да күрдек без —
Төш күреп ята иде.
Төш күрә-күрә-күрә,
Төчкереп ята иде.

Мес-мес-мес-мес киләләр —
Тәмләп йокы бүсәләр.
Нишләрләр микән инде
Буш казанны күрсәләр?

«Ботка кая киткән?»—
дип
Бик аптырарлар инде.
Буш казанга бик озак

Карап торырлар инде.

Торсалар тора инде,
Күрсәләр күрә инде,
Без ботка ашаганны
Белсәләр белә инде...

Боткалары ашалган,
Кашык-чүмеч яланган.
Болар безне күргәнче
Тайыйк мәллә аланнан?!

Ләкин алай итмәдек —
Без андый малай түгел.
Рәхмәт әйтми китмибез —
Без сантый малай түгел.

Җиргә яфраклар тезеп,
Яздык без мондый
сүзләр:
«Боткагызны ашадык.
Бик тәмле! Рәхмәт сезгә!»

...Кәҗә, Сарык аланда
Мес-мес йоклап калганда,
Без юлны дәвам иттек —
Тагын арырак киттек.

Бара-бара барганда,
Очрады бер зур бүре.
Чатыр чапты да китте,
Куркудан безне күреп!

Шулай бара-барганда
Каршыга чыкты аю.
Безгә тел күрсәтте дә
Лап та лоп чапты аю.

Шулай бара-барганда
Бер төлкегә юлыктык.
Төлкегә түгел инде —
Бер көлкегә юлыктык.

Төлке әле — кашына,
Әле уа колагын...
Әле бии, әле җырлый —
Клоун тек клоун!

Сул якка карый-карый,
Төлке китте кашынып,
Уң якка карый-карый,

Без дә киттек ашыгып.

Шулай бара-барганда
Юлыктык без диюгә:
Ут булды да юк булды —
Без «Һәйт, Дию!» — диюгә.

Шулай бара-барганда
Юлыктык без куянга:
Кишер кимерә иде,
Үзе кикерә иде,
Үзе чәйни, төчкерә,
Үзе төкерә иде...

Шулай бара-барганда,
Туктап, бер тын алганда,
Артына карый-карый,
Килеп чыкты бер абый.

Үзе култык астына
Дәү бер агач кыстырган.
Үзе: «Ай-яй! Кулым!»—
дип,
Шәрран ярып кычкыра.

Без шунда ук төшендек,
Аңладык аның хәлен:
Ярыкка бармакларын
Кыстырган бит Шүрәле!

Белдек агай исемен —
Былтыр исемле икән,
Малае да бар икән —
Шылтыр исемле икән.

Без чөй эзләп тапканчы
Абзый көчкә чыдады:
Агачына чөй кагып,
Бармакларын чыгардык.

Агачны атып бәреп,
Артына карый-карый,
Ах-вах килеп, сызланып,
Авылга чапты абый!..

Шулай бара-барганда
Солдат кебек төз генә,
Очрадык без берзаман
Шүрәленең үзенә!

Янып тора күзләре,

Янып тора мөгезе;
Агач кебек сураеп,
Басып тора берүзе.

— Курыкмагыз сез
миннән,
Усал түгел лә мин! — ди.
Кытыклыйсым килсә дә,
Түзәм бүгенгә мин,— ди.
Аннан соң мин
һичкайчан
Балаларга тимим,— ди,—
Бары тик бәхет-шатлык
Мин аларга телим! — ди.

Шулай диеп Шүрәле
Җилкәдән сөеп алды.
Җитмәсә, әле сине
Өскә дә чөеп алды.

Көләч икән Шүрәле,
Шаян икән Шүрәле...
Балан кәнфите бирде —
Юмарт икән — күр әле!

Рәхмәт әйттек без аңа,
«Тагын килербез!»—
дидек.
«Сиңа бәлеш, пәрәмәч
Алып килербез!»— дидек.
Без кайтырга кузгалдык —
Өйгә таба юл алдык.
Шүрәле моңсу гына
Арттан кул болгап калды.

Бер — атладык, бер —
чаптык,
Юлда тузан туздырып.
Өйгә кайтып кердек без,
Борын белән сызгырып.

Арып кайткан абыйны
Утырттым да тезгә мин,
Кырлайда күргәннәрне
Сөйләп бирдем сезгә мин.

## УБЫРЛЫ СЕБЕРКЕСЕ

**I**

Моннан күп еллар элек,

Бик күп тә түгел алай,—
Яшәгән, ди, дөньяда
Җамавыз атлы малай.
Кемгә охшап тугандыр —
Ансын әйтүе кыен:
Көн дә уйлап тапкан ул
Начардан-начар уен.
Үзеннән кечеләрне
Җәберләгән, елаткан,
Чәчен тарткан кызларның,
Кошларга ташлар аткан...
— Миндәй малай башка
юк! —
Дигән ул, корсак кашып,—
Эзләсеннәр әле,— дип,
Йөргән урманда качып.
— Улым, кайда син?! —
диеп,
Әтисе дә эзләгән,
Елый-елый, шешенеп,
Әнисе дә эзләгән.
Күршеләр дә түзмәгән—
Чыкканнар, ди, эзләргә...

**II**

Ә Җамавыз...
Җамавыз,
Кырмыска ояларын
Пыран-заран китереп,
Йөргән һаман урманда —
Йөргән зыян китереп.
Ни хикмәттер, аңарга
Очрамаган төлкеләр,
Арысланнар, бүреләр...
Хәтта куян, керпеләр
Күренмәгән юри дә.
Кем белгән, бәлки, алар
Киткәннәрдер базарга
Яисә урман циркына —
Берәр кәмит карарга.
Бәлкем, булгандыр алар
Җыелышта-мазарда...

**III**

...Урманда азып-тузып,
Шулай йөргән чагында,
Килеп чыга Җамавыз

Зур бер имән янына.
Ул имәннең зурлыгын
Сөйләп бирерлек түгел,
Җирдәге чикләвеген
Һич күтәрерлек түгел...
Чү! Туктале, нәрсә бу? —
Ябалдашка төбәлә
Җамавызның карашы.
Ә анда, селкенгәләп,
Ялт-йолт килә бер
кашык...
Моңа хәтле күргәне
Булмаса да алтынны,
Җамавыз аваз сала:
— Алтын кашык! Таптым
мин!
Шулай ди дә Җамавыз
Башмагын салып ташлый
Һәм, мәче күк, тиз генә
Өскә үрмәли башлый.
Менеп җиткәч, кашыкны
Кысып тота учына.
Кинәт — шарт! — ботак
сынып,
Ул түбәнгә ычкына...

**IV**

Аңга килгәч, ни күрсен —
Җилләр искән кашыктан.
Дәшәлми тора малай,
Әйтерсең ул таш йоткан.
Шулчак — ни бу?—
кәүсәдә
Пәйда була зур тишек.
Күзгә күренә, дисәң...
Тишек түгел, зур ишек!
Ишек күргәч, онтыла
Алтын кашык кайгысы.
Дер-дер килә Җамавыз,
Уйлап куя: «Әллә соң
Эчкә узып карыйсы?»

**V**

Уйлап куя да малай,
Кулына таяк алып,
Атлый-атлый сак кына,
Бусаганы узуга,
Нәрсәгәдер абына.

Һәм шулвакыт түрбашта
Гөлт итеп ут кабына!
Сискәнеп куя малай,
Шикләнеп куя малай.
Башта берни күрмәгәч,
Күзләрен уа малай.
Аннан карый як-якка:
Ярыйсы бүлмә икән.
Әти-әнидән качып
Яшәргә була икән.
Берүзең монда, тәмләп,
Ашарга була икән...

**VI**

Тәмләп ашау дигәннән,
Малайның бик тә, бик тә
Ашыйсы килә башлый
Сөт белән кара икмәк.
Монда әле, эзләсәң,
Бардыр прәнник-
кәнфит тә?!
...Җамавыз, кыюланып,
Иреннәрен ялманып,
Таягын куя читкә
Һәм тотына эзләргә
Хыялланып-хисләнеп...
Күреп ала шулвакыт
Бер кечкенә өстәлне.
Өстәлдә — кәгазь, каләм.
Кәгазьдә — язу. Серле...
Тезелгәннәр хәрефләр —
Кәкере дә бөкере.
Җамавызның язуны
Бик тә укыйсы килә:
Азаплана, булмый һич —
Хәрефләре селкенә.
Азаплана Җамавыз,
Ятып ала — хәл җыя.
Һәм, ниһаять, бер сүзне
Сүтә малай: в-а-с-ы-я-т-ь.
Һәм Җамавыз, тагын да
Кызыксынуы артып,
Дымсу-юеш идәнгә
Күлмәген салып атып,
Әллә бер сәгать укый,
Өч сәгать укый әллә?!

**VII**

...Ә анда — васыятьтә
Язылган мондый хәлләр:
«Әйтеп куям алдан ук —
Бу язуда ялган юк.
Васыятемне укучы
Сөртсен башта уң учын,
Йөртсен аннан шул учын
Шушы кәгазь өстендә —
Дуамал гайрәт иңәр
Шул кешегә өч көндә.

Язуымны иң элек,
Синдәй наданнан көлеп,
Убырлылар телендә
Язмак булган идем дә,
Уемнан кире кайттым —
Синең телдә язуны
Кулайрактыр дип таптым.
Минем исем гади, шәп!
Ишеткәнең бардыр,
шәт?! —
Дөньяны дер селкетеп,
Кешеләрне өркетеп
Яшәдем мин — Убырлы,
Яшьнәдем мин —
Убырлы.
Туздырасын — туздырып,
Җимерәсен — җимереп,
Умырасын — умырып
Яшәдем мин — Убырлы,
Кушаматым — Умырлый!

Шактый эшләр
майтардым,
Җирне, күкне актардым,
Аерылмас юлдашым
Себеркекәем белән!
Нинди эш майтарганны,
Тагын ни актарганны
Мин үзем генә беләм.
Хәзер менә арылды,
Бетәштем — картаелды.
Дөньяда инде миңа
Бик күңелсез, барсы ят...
Шуңа күрә, үлгәнче,
Кара гүргә кергәнче,
Языйм, дидем, васыять...
Булган бар мөлкәтемә —
Сарай һәм келәтемә

«Кызыл әтәч»
җибәрдем —
Калды шушы имәнем!
Мирас итеп, имәндә
Калдырамын бары тик
Һавада йөри торган
Затлы, җиңел пар итек,
Төпсез капчык һәм
инде —
Кадерле себеркемне!
Ә-ә... әйтергә онытылган,
Ялт-йолт эленеп торган
Теге алтын кашыкны
Эзләмә — юкка чыкты,
Парга әйләнде кашык!..
Йә, әйдә, кузгал, ашык!
Укы да мондый әфсен:
«Сәбе-сәбен-сәнәфсен —
Әбе-сәбе-сәнмәсен!» —
Себер, туздыр һәммәсен!

Мин яздым барсын әйтеп,
Менә шул — васыятем!
Кул куямын — Убырлы.
Кушаматым —
Умырлый».

**VIII**

Ниһаять, васыятьне
Җамавыз укып чыкты...
...Баш астына салды да
Төпсез кара капчыкны,
Йоклап та китте шундук,
Бик тәмләп ашаганын
Күреп татлы төшендә...

**IX**

...Дуамал гайрәт тоеп,
Өч көннән соң уянды.
— Миндәй батыр юк! —
диеп,
Малай шундый
куанды,—
Җип-җиңел итекләрне
Киеп алды тиз генә.
Баш түшәмгә тигәнен
Сизми калды үзе дә.

Себерке шәп күренә —
Малай шуңа үрелә.
Аннан кат-кат, бик озак
Әйләндергәләп карый:
— Менә моны, ичмасам,
Себерке дисәң ярый!
Бармак белән төртергә
Төймәләре бар — икәү.
Уйлый малай таң калып:
«Менә шуңа атланып
Җир читенә бар икән!»

**X**

Шуннан төпсез
капчыкны
Иңсәсенә аса да,
Себеркегә атланып,
Бер төймәгә баса да,
Буксовать итә-итә
Пытырдап очып китә!

Әллә очкын чәчерәп
Төштеме идәненә —
Ут кабып калды өйгә,
Убырлы имәненә! —
Биш минуттан шул
җирдә
Уйнады җилләр генә...

**XI**

...Биеккә шактый менгәч,
Себерке сабы очы
Болытларга төртелгәч,
Җамавызның бармагы
Икенче бер төймәне
Эзләп тапты карманып.
Өч-дүрт тапкыр
төчкергәч,
Кара төтенен өреп,
Сүнде дер-дер калтырап
Себеркенең моторы.

Күктә тынлык урнашкач,
Һавага аяк баскач,
Җамавыз, батыраеп,
Тотынды болытларны
Себереп тутырырга —

Төбе юк капчыгына...

**XII**

Болытларның барсын да
Капчыгына тутырып,
Малай түбән ыргылды
Себеркегә утырып.
Җиргә төшеп җитүгә —
Юлыкты ул көтүгә:
Сыерын һәм кәҗәсен,
Сарык, бәрән — һәммәсен
«Ә» дигәнче юк итте,
Аннан авылга китте.

Юлда ул бик талчыккан,
Талчыгудан ачыккан,
Әтисенә очрады,
Әнисенә очрады.
Күрмәмешкә салышып,
Белмәмешкә салышып,
Як-якка каранды да
Һәм, үзе дә сизмичә,
Себерде аларны да!
Авылны да себерде —
Калдырмады беркемне!

**XIII**

Аннан китте далага,
Аннан китте калага —
Җимерәсен — җимерде,
Туздырасын — туздырды,
Себерәсен — себерде...

Малайның явызлыгы
Убырлыны уздырды!

Җир өстендә бер көндә
Һичбер нәрсә калмады —
Барысын да Җамавызның
Себеркесе ялмады.

**XIV**

Җирне шәп-шәрә иткәч,
Себеркегә эш беткәч,
Малай башын күтәрде —
Күк йөзенә текәлде.
Бу вакыт төнлә иде.
Аяз күктә җемелдәп

Йолдызлар көлә иде...
Җирдә ниләр булганын
Алар шул күрмәделәр,
Малай ни уйлаганын
Алар шул белмәделәр.
Җамавыз шактый озак
Күктән күзен алмады.
Йолдызларның көлүен
Ул үзенчә аңлады.
Мыскыллау дип аңлады.
Шуңа бик нәфрәт белән
Аларга таба очты...
Һәм себерде... Себерде
Ул айны да берочтан!

**XV**

...Иртә белән, таң аткач,
Җамавыз күреп алды
Үзенә туры карап
Йөзеп килгән кояшны.
— Әле син
калдыңмыни?! —
Дип кычкырды
Җамавыз.
Һәм себерке, тиз генә,
Кояшны да ялмады.
Кинәт бөтен дөньяны
Караңгылык каплады...
Җамавыз куркуыннан
Себеркене капшады.
Аннан, учына кысып,
Тотты капчык авызын.
Шырпы да юк, ичмасам,
Карар иде кабызып.
Кыймылдарга да куркып,
Озак утырды шулай
Кап-караңгы бушлыкта
Җамавыз атлы малай.
Төрледән-төрле уйлар
Башына килде аның...
Шунда гына Җамавыз
Аңлады ялгышканын,
Бик тә нык ялгышканын!

**XVI**

Малайның үкенүдән
Тулып ташты күңеле,—
Хатаны төзәтергә

Бәлки, бик соң түгелдер?!
Моның өчен яңадан
Тормышны башлау кирәк.
Иң элек себеркене
Туздырып ташлау кирәк.

Шул ният белән малай
Үрелде себеркегә,
Һәм, ялгышып, төймәнең
Орынды ул берсенә.
Әйтерсең шуны гына
Көтеп торган себерке:
Очты да китте шундук
Малайга төтен бөркеп.
Очып китте — югалды.
Колак төбендә бары
Мотор тавышы калды.
Юатты үзен малай,
Үч алалмый калудан
Йөрәге бик әрнегәч:
— Туктарсың әле, нибуч,
Күк читенә бәрелгәч!

**XVII**

Аннан капчык авызын
Чишеп барсын бушатты —
Кояш яктысы булып
Йөзенә чыкты шатлык!
Гүя дөнья яңадан
Барлыкка килдемени?
Малайга тәүге тапкыр
Канатлар иңдемени?
Кара әле, бу дөнья,
Баксаң, шундый шәп икән!
Беленмәгән кадере
Тәртипсез яшәп кенә...

**XVIII**

Өенә кайту белән,
Иң элек әнисеннән,
Аннан соң әтисеннән,
Ә аннан күршеләрдән
Һәм барлык кешеләрдән
Малай гафу үтенгән.
Кешеләр бит яхшылар,
Малайны кичергәннәр.
— Ачыккансыңдыр,—
диеп.

Биреп арыш ипие,
Тәмле сөт эчергәннәр
Һәм малайга Яхшыр дип
Яңа исем биргәннәр.

Яхшыр, үткән көннәрнең
Истәлеге булсын дип,
Һавада йөри торган
Җип-җиңел итекләрен
Куйган, ди, чөйгә элеп.
Ул итекләр һаман да
Тора, ди, элгән килеш.

## ӘКИЯТЧЕ МАЛАЙ

Әкиятләр укый торгач,
Тәки шомардым, малай:
Ошбу әкиятне үзем
Уйлап чыгардым, малай.
Борын-борын заманнарда
Түгел, бүген заманда
Яшәгән, ди, Кәҗә, Сарык...
Яшиләр, ди, һаман да.
Сарык бик акыллы икән,
Кәҗә аңгыра икән.
Сарык ак сакаллы икән,
Кәҗә саңгырау икән.
Берчак урманда йөргәндә
Аю башы тапканнар.
Аю башы: «Сәлам!» дигәч,
Болар куркып чапканнар...
Бераз чапкач, хәл-тын алгач,
Сарык: «Ми-ки-ки!»—дигән.
Кәҗә мескен ишетмәгәч:
— Ул баш синеке! — дигән...
Шуның белән шул: Кырлайга
Болар кайтып киткәннәр.
Вилсәпидләре ватылып,
Көчкә кайтып җиткәннәр...
Тагын борын заманнарда,
Авыз-колак чакларда.
Яшәгән Былтыр, Шүрәле
Сезнең-безнең якларда.
Шүрәле урманчы икән,
Былтыр — чүкеч остасы.
Бер мәлне болар урманда
Очрашканнар, кыскасы.
Бер ботакның булган икән

Нечкә генә ярыгы...
— Кети-кети уйныйк! — дигән
Шулчак урман сарыгы.
Былтыр-оста шүрләп калган,
Дер-дер килгән, кыскасы.
— Гафу ит, Шүрәле абзый,—
Дигән чүкеч остасы.
Ярыкка үз бармакларын
Былтыр кыстырган шулчак.
— Шүрәле быел кысты! — дип,
Былтыр кычкырган шулчак.
Менә шул... Әкиятемне
Тагын укып алыгыз.
Тукай абый язган белән
Аермасын табыгыз.

## КИРЛЕ-МЫРЛЫ КИҢӘШЛӘР

### ИРТӘН УЯНАСЫҢ КИЛМӘСӘ...

Иртән әниең сине: «Балам, тор инде»,— дип йокыдан уяткач, урыныңнан кузгалма. «Яслегә барасым килми!» — диген. Әле генә ягымлы эндәшкән әниеңнең түземлеге төкәнгәнгә дә игътибар итмә. «Минем йокым килә! Бармыйм булгач, бармыйм!» — диген. Чын-чынлап җылап алсаң да ярый. Киреләнүеңне дәвам иттер. Син урыныңнан кузгалмасаң, әниең эшкә бара алмый. Ул эшкә бармагач, аңа акча бирмиләр. Әниеңнең акчасы булмагач, ул сиңа тәмле ризыклар, уенчыклар ала алмый. Син, уяныр-уянмас, киреләнеп урыныңда ятасың, әниең көне буе өйдә — шундый рәхәт сиңа! Шулай бит!

Әллә киресенчәме?

### ҖЫЛЫЙСЫҢ КИЛСӘ...

Әгәр әниең: «Эшкә соңга калам инде!»— дия-дия, ашыга-ашыга сине киендерергә азаплана икән, киенмәскә тырыш. «Бу оекбашны кимим! Күлмәкнең бусы ошамый!»— диген. Тыпырчына-тыпырчына җыларга тырыш. Берәр җиреңә «чәп» иттереп алсалар, отыры кычкырыбрак җыласаң да ярый. Шәрран ярып акырганыңны ишеткән күрше-күләннәр сиңа бик сокланырлар: «Карале, безнең күршедә нинди җылак бала үсә икән! Бигрәк матур итеп җылый инде!» — диярләр.

Җылыйсың килми башласа, көчәнмә. Көчеңне сакла. Әле синең киреләнә-киреләнә җылыйсыларың көне буена шактый булачак. Шулай бит!

Әллә киресенчәме?

### БАТЫР БУЛСАҢ...

Әгәр малай икәнсең, син кыю-батыр булырга тиеш, шулай бит?!

Шуңа күрә, әтиең йә әниең сине балалар бакчасына илтеп куюга, иң элек кызларның чәчләрен тарткала, чеметкәлә, урамга уйнарга чыккач, карга төртеп ек. Үзеңнән кечкенәрәк, юаш малайларны да, әгәр көчең җитсә, кар өстенә мәтәлдерергә тырыш. Кызлар чәрелдәп елый башласалар, авызыңны җырып тор, эчеңне тотып, тәгәри-тәгәри көл. Шул чакта сиңа би-и-ик күңелле булыр.

Әллә киресенчәме?

### МАТУР БУЛСАҢ...

Әгәр кыз бала икәнсең, син гүзәл-чибәр булырга тиеш, шулай бит?!

Шуңа күрә гел көзге янында булырга тырыш. Бизән-ясан, кашларыңны, иреннәреңне буя. Үзеңнең матур күлмәкләрең туйдыргач, әниеңнең яисә апаңның күлмәкләрен киеп, көзге каршында сәгатьләр буе бөтерел. Әниең: «Кызым-матурым, чынаяк-калакларны гына юып куйсана»,— дисә, син нәфис, ягымлы тавышың белән төксе генә итеп: «Вакытым юк!» —

диген. Әбиең дә берәр йомыш кушса, «Тинтерәтмәле, әби!» — дип, аңа матур итеп елмаеп ал. Шул чакта сиңа би-и-ик күңелле булыр.

Әллә киресенчәме?

## СҮЗ ТЫҢЛЫЙСЫҢ КИЛМӘСӘ...

Син мавыгып рәсем ясыйсың. Шулчак әбиең сиңа ягымлы елмаеп эндәшә:

— Бәбкәем (улым, кызым), күзлегемне генә табып бирсәнә. Кая куйганымны хәтерләмим генә бит.

Син тыңлама:

— Әйем лә,— диген. Рәсем ясавың белән мәшгуль бул.

Әбиең — синең яраткан әбиең — уфылдый-уфылдый күзлеген эзләр. Эзләсен. Бервакыт үзеңнең әби (бабай) буласың хакында да уйлама, үзеңнең шулай әйбер-мазар эзләп азаплануыңны да күз алдына китерергә тырышма...

Синең инде рәсем ясыйсың килми, ләкин шундый рәхәт, күңелле!

Әллә киресенчәме?

## ТАБИГАТЬНЕ ЯРАТСАҢ...

Әгәр малай яисә кыз бала икәнсең, син табигатьне, җан ияләрен яратырга тиешсең, шулай бит?!

Шуңа күрә, шомыртлар, сиреньнәр чәчәк аткан чакта, чәчәкләрне ботагы-ботагы белән өзеп ал, рәхәтләнеп хуш исләрен иснә, хозурлан. Чәчәкләрнең кирәге калмагач, кая телисең — шунда ташлап калдыр.

Маэмайлар, мәчеләр белән уйнаган вакытта аларның койрыкларыннан тарткаларга, ара-тирә төрткәләп-типкәләп алырга онытма. Кошларга вак ташлар ыргытканда, аларга тигезергә тырыш. Бака-балыкларга чуерташлар атканда да синең төз ата белүең үзеңнән тора. Синең осталыгыңны бүтәннәр дә күреп торса, бигрәк тә шәп. Эт-мәчеләрнең куркынып, өтәләнеп чабуларын, җәрәхәтләнгән кошларның очарга азаплануларын күреп тору сиңа шундый рәхәтлек бирер. Шул чакта сиңа би-и-ик күңелле булыр.

Әллә киресенчәме?

## КИТАП БҮЛӘК ИТСӘЛӘР...

Сиңа бик матур китап бүләк иттеләр.

Син аны кулыңа битараф кына ал да битләрен аннан-моннан гына актаргалап, караштыргалап чык. Аннан соң китап битләренә төсле карандашларың белән теләсә нинди сурәтләр яса. Сурәтләрең янына: «Моны мин ясадым»,— дип язып куйсаң да ярый. Рәсем ясап туйгач, китап битләрен йомарлап, ерткалап ташласаң, тагын да әйбәтрәк булыр.

Дөрес, бераздан соң әлеге китаптагы матур-матур рәсемнәрне (үзең ясаганны түгел, әлбәттә!) кабат карыйсың килер... Ләкин син бик борчылма. Теләсә нинди сурәтләр белән чуарланып, йомарланып, ерткаланып беткән китапны актаруы күңеллерәк тә әле ул. Шулай бит?

Әллә киресенчәме?

## КЛОУН БУЛСАҢ...

Әнә яныңнан култык таягына таянган бер бабай үтеп бара. Аның бер аягы юк. Ул аны сугышта өздергән.

Син дус-ишләреңә әлеге бабай кебек аксап-титаклап йөреп күрсәт.

Әнә-әнә бер апа, нәрсәгәдер абынып, юл тузанына барып төште, кулындагы әйберләре чәчелде.

Син, берүк, аның янына йөгереп барып, әйберләрен җыеша башлама. Читтән генә карап тор, шул апа кебек аяк-кулларыңны болгап егылган булып кылан. Үзең, эчеңне тотып, хихылдый-хихылдый көл.

Дус-ишләреңнең көлмәвенә, сиңа сәерсенеп карап торуларына да игътибар итмә. Әле фәлән абый булып, әле төгән апа булып кылан...

Сиңа шундый рәхәт, күңелле!

Әллә киресенчәме?

## АТАКЛЫ ӘЛӘКЧЕ БУЛЫЙМ ДИСӘҢ...

Сиңа әләкче булырга киңәш итәм.

Сине, үзең кебек үк кыланып, тел чыгарып, кәҗә бәтие шикелле сикергәләп үчекләүче булса, аны шундук бакчадагы тәрбияче апаңа яки әти-әниеңә әләклә: колакларын кызыл чөгендер төсенә кергәнче борсыннар әле тегенең...

Берәр бала чынаягын яисә тәлинкәсен ялгыш төшереп ватса да әләкләргә ашык: «Ятып калганчы, атып кал», ди татар халык мәкале.

Әгәр башка балалар, синең оста әләкче икәнеңне белеп, синең белән уйнамыйбыз дисәләр дә, тиз генә әләкләргә йөгер. Дөрес, әләкләвеңә карап, алар барыбер синең белән теләп, шатланып уйнарга ашыкмаслар. Ләкин син моңа бик игътибар итмә. Иң мөһиме: вакытында әләкләвең хак булсын...

Кемнең ни кылганын гел күзәтеп кенә йөр. «Атаклы әләкче» дигән исем-ат теләсә кемгә эләкми ул!

Берзаман яныңда дус-ишләрең, синең белән уйнарга теләк белдерүчеләр бөтенләй калмас. Шул чакта сиңа бик рәхәт, күңелле булыр.

Әллә киресенчәме?

## КЕШЕГӘ ЧОКЫР КАЗЫСАҢ...

Яз. Кояш ешрак елмая. Сукмакларда карлар көпшәкләнә...

Сиңа киңәш: кулыңа көрәк ал да сукмакка дәү абый-апаларның, әби-бабайларның аяклары сыярлык итеп кечкенә чокыр казы.

Казыдыңмы? Бик әйбәт. Күрәсеңме, син казыган чокырга су тула башлады. Хәзер болай ит: су өстенә юка гына итеп кар сип — чокыр барлыгы сизелмәслек булсын!

Көрәгеңне яшереп куйдыңмы? Яхшы. Бар, чокырдан читкәрәк кит тә кемнең дә булса килгәнен көтеп тор. Сукмак буйлап йөренгәлә. Хәзер бик кызык булачак. Күңелең булганчы көләчәксең.

Һай! Тыкрыктан бозау чаклы эт килеп чыкты бит. Кач тизрәк!

Син уңга-сулга карамыйча сукмактан элдерәсең... Һәм... бултыйх!

Менә хикмәт: үзең казыган чокырга үзең төштең! Син чокырдан аягыңны ала алмыйча азапланасың. Итегеңнең эче тулы су... Күзләреңдә шатлык яшьләре...

Сиңа шундый рәхәт, күңелле...

Әллә киресенчәме?

## САРАН БУЛСАҢ...

Синең арка терәвечле бик матур чанаң бар. Рәсиләнеке юк. Синең чаңгың бар. Азатныкы юк. Синең ботинкалы тимераякларың бар. Айдарныкы юк...

— Чанаңны биреп тор әле,— дип сорый синнән Рәсилә.

— Үземә кирәк,— диген син. Бирмә.

— Чаңгыңда бер шуып килим әле,— дип сорый синнән Азат.

— Үзем шуам бит. Күрмисеңмени?— диген син. Бирмә!

— Тимераякларың белән бер әйләнеп килим әле,— дип сорый синнән Айдар.

— Әйләнми генә тор! — диген син...

Рәсиләгә әнисе матур-матур рәсемле әкият китабы алган. Синең андый китабың юк. Азатта диафильмнар күп. Синдә юк. Айдар әнә бик тәмләп кәнфит суыра. Синең дә кәнфит суырасың килә-ә-ә...

Син, күзеңне мөлдерәтеп: «Берне генә...»— дисең.

— Үзең бирдеңме соң безгә? — диләр Айдар, Азат һәм Рәсилә.

Син дәшмисең. Сиңа шундый рәхәт, күңелле!

Әллә киресенчәме?

## УЙНЫЙСЫҢ КИЛСӘ...

Син уенчыкларыңны чәчеп ташлап, аларның әле берсен, әле икенчесен алып уйный идең. Шулчак әниең:

— Кызым, уенчыкларыңны җыештырып куй. Телевизордан хәзер мультфильмнар була,— диде.

Син уенчыкларыңны җыештырма. Әниеңә:

— Мин әле яңадан уйныйм! — диген. Әгәр уеннан туйган булсаң, уенчыкларыңны караватастына тибеп җибәр йә кая туры килә — шунда әштер-өштер эткәләп куйгандай ит тә мультфильмнар карарга утыр...

...Иртәгесен, уйныйсың килгәч, уенчыкларыңны үзең эзләмә. Әниең белән әтиең эзләп интексен аларны. Эзләмәсәләр, аларга бик тиз тәэсир итә торган бердәнбер алымыңны кулла: буыла-буыла, тәгәри-тәгәри җыла.

Әтиең һәм әниең, мүкәләп, мышкылдый-мышкылдый уенчыгыңны эзлиләр...

Сиңа шундый рәхәт, күңелле!

Әллә киресенчәме?

## ХИКМӘТЛЕ ХИКӘЯТЛӘР

### ӘБИЕМ, ӘНИЕМ ҺӘМ МИН

Мин беләм, кайчандыр әбием дә, әнием дә минем яшьтә булган. Алар да, минем кебек, нәни көянтә-чиләкләр асып, чишмәдән тәмле су алып кайткан, елга буена казлар куган, бәбкәләр саклаган. Алар да минем сыман качышлы, әбәкле уйнаган, кәнфит кәгазьләре һәм чынаяк ватыклары җыйнаган, курчакларын «әлли-бәлли-бәү» иттергән. Алар да, минем шикелле, бәйрәм-тамашаларда шигырь-такмаклар сөйләгән, җырлар җырлаган, биегән...

Әйе, мин беләм, кайчандыр минем мөлаем әбием дә әнием яшендә булган. Ул да шатлык-куаныч булып дөньяга килгән нарасыен — минем әниемне иркәләгән, назлаган, сөйгән, кочкан. Мине әнием яраткан шикелле. Мин әниемне яраткан кебек.

Әйе, мине әнием бик ярата. Әбием дә бик ярата. Ә мин аларның икесен дә бик-бик яратам. Әлбәттә, мин әтием белән бабаемны да бик яратам. Алар да мине ярата. Без һәммәбез бер-беребезне яратабыз. Ярата алу, ярата белү — нинди зур шатлык ул, әйеме? Ә кайбер кешеләр ник бер-берләрен яратмыйлар икән? Гәзитләрдә язалар бит, телевизордан да көн саен күрсәтәләр, радиодан да сөйлиләр... Мин бит бөтенесен дә аңлыйм. Күреп торам, белеп торам... Тату, дус булуга ни җитә! Бөтен кешеләрнең дә бер-берләрен яратуларын телим мин. Безнең шикелле яратуларын. Мин әти-әниемне, әби-бабаемны яраткан кебек. Ә алар — әни, әти, әби, бабай — мине яраткан шикелле. Ярат син. Башкалар да яратсын. Яраткач рәхәт икәнен үзең дә аңларсың әле менә.

Мин, үскәч, яхшы күңелле кеше булачакмын. Әбием: «Яхшы күңелле кеше — бәхетле кеше ул!»— ди. Ә минем бик-бик әйбәт буласым килә. Әбием шикелле. Әнием шикелле. Син дә, үскәч, яхшы күңелле кеше бул, яме! Мин беләм, синең әбиең дә, синең әниең дә — бик әйбәтләр. Әбиләр, әниләр әйбәт булалар алар. Һәрвакыт.

Мин беләм, кайчандыр мин әнием яшендә, әбием яшендә булачакмын. Әбием әйтмешли: «Берүк, шулай була күрсен!»

Чулпыларын чың-чыңлатып,
Әбием суга барган.
Күлмәкләренә уралып,
Җилфер-җил уйнаклаган...

Шул чулпыларны чыңлатып,
Әни дә суга барган.
Мөлдерәмә чиләкләрдән
Гөлләргә сулар тамган...

Минем дә суга барышым,
Кояш елмая күктә.
Чулпылар — шул, көянтәм — шул,
Күлмәгем генә бүтән...

### ҖИЛӘКТӘН КАЙТКАНДА

Кызыл Төбәк болынынннан кайтып киләбез әле. Җиләк җыеп. Әбекәй әйткәндәй, шөкер, юлыбыз уңды. Роза апаның чиләге дә, минеке дә кып-кызыл җиләкләр белән тулды. Роза апаның чиләге минекенә караганда зуррак инде анысы, дөрес. Зур булмыйча, ул бит миннән үзе дә әллә ничә яшькә зуррак. Аның яшендә булсам, мин тагы да олы чиләк алган булыр идем әле. Алмыйча! Ни әйтсәң дә, мин бит малай кеше.

Роза апа ул — минем бертуган апам түгел. Хәтта чыбык очы туган да түгел. Без аның белән дуслар гына. Аның әнисе Гөлшат апа белән минем әни бергә эшли. Кибеттә эшлиләр. Гөлшат апа — башлык булып, әни аның ярдәмчесе булып эшли.

Асаба әрәмәсен уздык инде. Авылыбыз һаман күренми. Ара ерак шул — ничек күренсен инде. Аннан соң безнең авыл чокыргарак та урнашкан. Тау башындарак, әнә теге Каенлык тирәсендәрәк булса, күренгән дә булыр иде. Аннан соң без бәләкәй дә бит әле. Буйлар да бәләкәй. Каланча чаклы булсын иде безнең буйлар — ул чагында күрер идек авылны...

Көн әйбәт бүген. Кояшлы. Эссе дә. Иртә белән, без җиләккә барган чакта, көн тагын да матур иде әле. Ап-аяз иде. Хәзер генә ул болытлар күренә башлады. Безнең бозау шикелле, кап-каралар барысы да. Әллә яңгыр яумакчы була инде?

Сандалиларыбыз такыр юлны чыкылдата.

— Мурзин әрәмәсенә җитсәк, авылга җырак калмый инде, иеме, Роза апа?

— Әйе, үскәнем. Аннан соң Каенлык та, аннары — безнең авыл...

Икебез дә алҗыганбыз бугай. Сөйләшәсе килмәгәнгә әйтәм. Җиләккә барган чакта, җиләк җыйганда күбрәк сөйләштек шул. Тел алҗыганчы. Аннары, үтереп ашыйсы да килә. Ашау турында гына уйлаганда ничек сөйләшәсең инде? Менә кайтып кына җитик әле өйгә, кайткач тәмләп җиләк белән чәй эчәрбез. Без кайтуга коймак та пешереп куйганнардыр әле.

Роза апа белән барам, дигәч, әни каршы килмәде тагы. Барыгыз, бар, тик адаша гына күрмәгез, диде. Җиләк күп җыеп апкайтсагыз, балта осталарына да чәйне шуның белән эчерербез, диде. Иртәгә балта осталары килә безгә. Өй бурасы бурарга. Бу өй тузды инде, искерде. Яңа өйдә яшисе килә.

Яңгыр явар, мөгаен. Безнең авыл көтүе шикелле укмашып, арттан бер өер кара болыт килә.

Сандалиларыбыз отыры катырак һәм ешрак чыкылдый башлады.

Чү! Минем битемә тамчы тамды түгелме соң? Әйе шул, тамчы. Их, Мурзин әрәмәсенә дә җитә алмадык. Берәр җирдә ышыкланып торган булыр идек.

Яңгыр сибәләргә үк тотынды. Ул арада күк күк-рәп алды. Хәзер инде мин Роза апага елышыбрак атлыйм.

Кинәт чытыррт итеп яшен яшьнәде. Кемдер чәчләремнән авырттырып өскә тарткандай булды.

Машина кычкырткан тавыш ишетеп, читкә тайпылдык. Ак «Жигули» машинасы безнең яннан выжылдап узып китте.

— Бу бит... бу бит... Әнвәр абый иде. Нигә утыртмады инде ул безне, Роза апа? Янында кешесе дә җугые бит...

Мин елый башладым. Роза апа мине юатырга тырыша:

— Җә инде, җылама инде, үскәнем. Җылама инде...

Тагын күк күкрәде, тагын яшен яшьнәде, тагын минем чәчләрем өскә тартылды...

Мин отыры еларга тотындым:

— Нигә утыртмады инде Әнвәр абый?.. Буш иде бит...

Роза апа да миңа кушылды— икәүләшеп елыйбыз.

— Әй, шәбәргән чыпчыклар! Яңгыр яуганда нишләп йөрисез?

Елаудан кинәт туктап, икебез дә артка борылып карадык. Вилсәпиденә атланган исәр Рафаил абый икән.

— Утырыгыз тизрәк. Апкайтам!

Рульгә чиләкнең тоткасын кидердем дә рамга утырдым, Роза апа вилсәпиднең арткы утыргычына җайлашты.

Кузгалып китеп байтак ара узгач, күзләрем чиләгемә төште. Һәм мин чырыйлап кычкырып җибәрдем:

— Җиләкләрем!

Чиләгем кыйшаеп, җиләкләремнең яртысыннан күбесе коелып беткән иде...

Мин елый-елый, Роза апа мине юата-юата, без тагын җәяү атладык.

Өйгә ничек кайтканымны, караватка ничек ятканымны хәтерләмим. Иртән балта шакылдаган тавышка уянып киттем. Бөтен тәнем лычма су, үзем уттай янам. Авырлык белән генә күтәрелеп тордым да тышка — кояшлы урамга карадым.

Ә анда... Ә анда, авызын ерып, җиләк кебек кызыл чырайлы Әнвәр абый бүрәнә юнып маташа иде.

## БЕЗНЕҢ ОЧТА

Ниләр генә юк безнең очта!

Беркөнне иренмичә санадым. Урам якка караган гаражлар — җидәү, урам якка карамаганнары — тугыз. Рәсим абыйлардан башлыйм. Аның сары «Жигули»е бар. Әхмәт абыйда — «Нива» белән «Урал». Габдерәүф абыйның яшел «Жигули»е, «Иж-Юпитер»ы һәм ишегалдында су колонкасы бар. Нияз абый олы йорт салды. Верандаларына гына да ярты авыл сыярлык. Кичә генә яңа машина алып кайтты — «Нива». Шикәр шикелле, сөт шикелле ап-ак!..

Аннан соң — безнең өй. Әлегә машина юк-югын. Матай бар. «Восход». Әти әйтә, язган булса, быел язга яңа маркалы машина алам, ди. Нинди маркадыр — әйтә алмыйм. Алгач, һичшиксез әйтермен. Тә-әк. Әхнәф абыйның ике матае бар. Машина да алмакчы, дип сөйлиләр. Алыр да. Берне түгел, икене алырга мужыт ул. Аннан соң... Хәмит абый...

Уф-ф!

Телем арганчы шулай машина-матай санар идеммени инде мин. Санамас идем, әлбәттә. Әгәр дә безнең очта минем белән бергә рәхәтләнеп уйнарга бер малай булса. Һич югында, чәчкәби генә берәр кызый да ярар иде...

## НА-А, БАХБАЙ!

— На-а, бахбай! На-а-а...

Иңемдә канатлармыни — очам гына!

Томырылам, ук шикелле.

Җил, ялкын телләре ясап, чәчләремне уйнаклата.

Сәдәфләре ычкынган күлмәгем җилфер-җилфер килә.

Рәхәт!

Шундый рәхәт!

— На-а, бахбай! На-а-а...

Мәтәлеп төшүдән куркып, аяк астындагы юлга карамаска тырышам. Карашым алга, бары алга төбәлгән...

— На-а, бахбай! На-а-а...

Юл читендәге үләннәр, чәчәкләр — һәммәсе миңа сокланып карыйлар төсле. Кем белә, бәлки, көнләшәләрдер дә әле. Көнләшсәләр көнләшерләр инде, бернишләр хәл юк. Аларның, минем шикелле, малай булып тумаганнарына мин гаепле түгел...

— Әhә-hә-hә-ә-әй! На-а, бахбай! На-а-а...

Тузаннар туздырып, капка төбебезгә кайтып туктадым. Көнбагыш чүбен әле сулга, әле уңга «тфү»ләп утырган кунак малае Ринат (күршеләргә кайткан) эскәмиядән торды да, күзләрен ялтыратып, минем янга килде.

— Дай, а, я тоже чуть-чуть юреп килем!

— Мә. Жәл түгел. Бар, җилдереп кил әйдә бер!

Кунак малае, минем зәңгәр велосипедка җәhәт кенә менеп атланды да кузгалып китте.

Ат шундый килешер иде аңа. Миңа да!

## ҮСКӘЧ

Үскәч мин колхоз рәисе булырмын, ахры. Бу хыялым турында моңарчы беркемгә дә әйткәнем юк иде. Сезгә генә әйтүем. Әгәр дә мин чынлап та колхоз рәисе булсам, иң беренче эш итеп нәрсә эшләр идем, беләсезме? Юлга асфальт җәйдерер идең, диярсез. Урамнарга агач утырттырыр идең, диярсез. Тагын әлләниләр, диярсез. Юк, мин әле боларга тотынганчы, иң элек үзем теләгән эшне чынга ашырыр идем...

Әгәр дә киләчәктә колхоз рәисе булсам, бүгенге колхоз рәисе Рифкать абыйга өй салдырып бирер идем. Гатифә әбинеке төсләне. Яңгыр тишкәләп бетергән такта түбәле итеп, нигезен бер якка янтайган итеп, кечкенә генә базына су җыела торган итеп...

Ә Гатифә әбигә — ике улын һәм ирен сугышта югалткан Гатифә әбигә —Рифкать абыйның бүгенге өе шикелле итеп салдырыр идем. Болын кадәрле өй!

## БӘХТИЯРГӘ ЭТ КИРӘКМЕ?

Беркөнне Бәхтияр мәктәптән әсәренеп кайтты.

— Әти! Әтием! — дип эндәште ул кәнәфидә гәзит-журналлар караштырып утырган әтисенә.— Сашалар эт алган! Бульдог! Без дә алыйк әле. Бульдог булмаса да ярый...

Әти кеше, гәзит-журналларын бер читкә куйды да, Бәхтиярне күтәреп алып тез башына утыртты. Аннан, ягымлы елмаеп, җайлап кына сүз катты:

— Улым, син татар малаемы? — диде.

— Әйе, мин — татар малае,— диде Бәхтияр.

— Син мөселманмы?— дип янә сорау бирде әтисе.

— Әйе, мин — мөселман. Безнең өйдә барыбыз да мөселманнар,— диде Бәхтияр.— Айдарлар да, Алсулар да — мөселманнар...

— Шулай булгач, хәзер инде син мине игътибар белән тыңла, улым,— диде әтисе.— Мөхәммәт пәйгамбәр мөселманнарга, өйдә ихтыяҗ булмаса, эт тотуны тыйган. Эт ярдәменә аеруча мохтаҗ кешеләргә генә, мәсәлән өендә бер ялгызы яшәгән дөм сукырларга гына, эт асрау рөхсәт ителә. Махсус өйрәтелгән андый этләр кибетләргә, шифаханәләргә, даруханәләргә барганда-кайтканда, юл аша чыкканда сукыр кешеләргә бик зур ярдәм итәләр. Ә без, Аллага шөкер, сау-сәламәтләр. Шулай бит, улым?!

— Әйе, әтием,— диде Бәхтияр.

— Мөселман өендә эт — шапшаклык чыганагы,— дип сүзен дәвам итте әтисе.— Чөнки эт орынган һәр нәрсә, мәсәлән, савыт-сабалар пычрана. Этләрдән кешеләр эчәк суалчаннары йоктырырга мөмкиннәр. Мөхәммәт пәйгамбәр: «Әгәр эт савыт-сабага кагылса, аны җиде мәртәбә юыгыз һәм шулардан берсен — ком белән»,— дигән. Этләрнең тагы кунакка килгән кешеләргә, йомыш-фәлән белән кергән күршеләргә тиктомалдан өрүләре, аларны куркытулары ихтимал. Этләр бәйдә яисә борынчыклы булсалар-булмасалар да, үткән-сүткән кешеләргә бик еш кыенлыклар тудыралар. Аңладыңмы инде, улым?

— Аңладым, әтием,— диде Бәхтияр.

— Аннан соң, улым, безнең этебез бар бит инде. Авылда, бабаңнар ишегалдында. Каралты-кураны, йортны явыз ниятле кешеләрдән саклаучы Муйнак турында әйтүем,— диде әтисе.— Җәй көне кунакка кайткач, Муйнак белән рәхәтләнеп уйнарсыз. Су буйларында йөрерсез, болыннарда күбәләкләр куарсыз, урманга җиләк җыярга барырсыз...

Шулай диде дә әтисе, Бәхтиярнең аркасыннан сөеп алды. Бәхтияр исә, Муйнакның болында күбәләкләр куып йөргәнен күз алдына китереп, елмаеп куйды.

## ЯРАТАМ

Өйдәгеләр миңа: «Син китапларны су урынына эчәсең!»— диләр. Алай су урынына эчкән юк-югын, әмма укыйм. Яратам укырга. Китап булса, телевизор да кирәкми миңа. Аш ашаулар онытыла. Әни җә әби йомыш кушса, аны бик тиз генә үтим дә, диванга кырын ятып, тотынам укырга, тотынам укырга!..

«Рөстәм маҗаралары»н унҗиде мәртәбә укып чыктым инде. «Караборынның дусты»н да унҗиде тапкыр укыдым бугай, әгәр ялгышмасам...

Менә бүген дә китапханәдән шул ике китапны алдым әле. Теткәләнеп-таушалып беткәннәр инде, җанкайлар. Укый-укый ятлап бетердем инде мин аларны. Телисез икән, өтерләренә кадәр әйтеп, эчтәлеген сөйләп бирәм хәзер.

Әйе, китаплар укырга бик маһир инде мин. Яратам. Тагын татарча әллә нинди яңа китаплар укыр идем әле. Рәхәтләнеп. Юк бит, юк китапханәдә бүтән китаплар. «Рөстәм маҗаралары» белән «Караборынның дусты» гына бар...

## ГАЕТ БӘЙРӘМЕ

Бу бәйрәм, Ураза тәмам булганнан соң, өч көн дәвам итә. Ул Ураза һәм Фитыр бәйрәме дип тә йөртелә. Бәйрәмнең беренче көнендә мөселманнар, мәчеткә җыелып, гает намазын укыйлар. Намазга кадәр фәкыйрьләргә фитыр садакасы бирелә.

Җылы, йомшак ятакларында изрәп, мес-мес йоклап яткан игезәк оныклары Айдар белән Хәйдәрне Галим бабай бүген бик иртә уятты.

— Балалар, уяныгыз! Бәйрәм көнне озак йокламыйлар,— диде ул, оныкларының башларыннан сыйпый-сыйпый.

«Бәйрәм» сүзен ишетүгә, Айдар белән Хәйдәр урыннарыннан бер вакытта сикереп торды. Күз төпләрен угалап торган малайларга карап:

— Хәерле иртә, балалар! Ураза бәйрәмебез мөбарәк булсын! — диде Галим бабай. Балалар, бабалары әйткәнчәрәк әйтергә тырышып:

— Хәерле иртә, бабакай. Бәйрәмебез бергә-бергә күңелле узсын! — диделәр.

— Кысталган булсагыз, әүвәл йомышларыгызны йомышлап алыгыз. Аннары ваннада алмаш-тилмәш бик һәйбәтләп юынып чыгарсыз,— диде Галим бабай.— Гает намазына пакьләнеп бару мәслихәт.

— Аннары соң мәчеткә барабыз, иеме, бабакай?— диде Айдар, күзләрен челт-челт йомгалап.

— Юк, башта Гает коймагы ашыйбыз әле... Шулай бит бабай?— дип, Хәйдәр сораулы карашын бабасына юнәлтте.

— Ашыкма, балам,— диде аңа бабасы.— Гает коймагы белән мәчеттән кайткач сыйланырбыз. Әнә әбиегез, коймагым тәмле генә була күрсен инде берүк, дия-дия, күптәннән хәстәрләнеп йөри...

Малайлар бер-бер артлы юынып чыктылар да, чиста, пөхтә киемнәрен киделәр.

— Бу матур түбәтәйләрне сезнең башларыгызга үлчәп теккәннәр диярсең, бигрәкләр дә килешә инде үзегезгә,— дип, Галим бабай оныкларының аркаларыннан сөеп-сөеп алды.

— Бабакай, мин әзер. Киттекме инде мәчеткә?— диде Айдар бераздан.

— Китмичә тор әле. Минем ашыйсым килә,— диде Хәйдәр. Шулай диде дә бабасына карады:

— Капкалап алырга ярыйдыр бит, бабакай?!

— Әбиегез прәнник-кәнфитләрне, җиләк-җимешләрне өстәлгә әзерләп куйган инде әнә. Аларны өстәл өсте матур булып торсынга гына куймагандыр, шәт.

Аларның шулай сөйләшүләрен ишетеп торган Гайшә әби:

— Әйдәгез, утырышыгыз,— дип елмаеп, өстәл янына дәште. Аннары: «Бәйрәмебез мөбарәк булсын!»— дип тә өстәде.

— Бергә булсын, әби! — диештеләр балалар.

Галим бабай да, Айдар белән Хәйдәр дә, бисмилла әйтеп, хөрмә, йөземише җимешләрне, төрле тәм-томнарны җиңелчә генә авыз итеп алдылар да, «Аллаһү әкбәр!» дип, урыннарыннан кузгалдылар. Кузгалыр алдыннан Гайшә әбигә дә рәхмәт әйтергә онытмадылар...

Мәчет ерак түгел иде. Шуңа күрә Гает намазына җәяүләп кенә барырга булдылар. Юлда аларга үзләре шикелле пөхтә киенеп мәчеткә баручы өлкәннәр вә балалар очрады. Алар бер-берсе белән:

— Әссәламегаләйкүм!

— Вәгаләйкүмәссәлам! — диеп исәнләштеләр.

— Бәйрәм мөбарәк булсын!

— Бәйрәм белән! — диешеп, бер-берсен котладылар.

Мәчеткә якынлашканда, Айдар да, Хәйдәр дә койма буенда чүгәләп утырган яисә тезелешеп басып торган сәләмә киемле әби-бабайларга игътибар иттеләр. Араларында аяксыз яки кулсыз кешеләр дә бар иде.

— Болар — ачлы-туклы яшәп көн итүче фәкыйрьләр, ярдәмгә мохтаҗ Ходай бәндәләре,— диде бабалары, малайларның сораулы карашын тоеп.— Әйдәгез әле, фитыр садакасы биреп сөендерик әле үзләрен...

Галим бабай шулай диде дә, кесәсеннән акча янчыгы чыгарып, хәер өләшә башлады.

Бераздан мәчет янына җыелган барча халык Гает намазын тыңларга әзерләнеп тын калды.

Намаз укыганда өлкәннәр үзләрен ни рәвешле тотсалар, Айдар белән Хәйдәр дә, бүтән балалар да үзләрен шулай тотарга тырыштылар. Хәзрәтнең Гает намазын укыганнан соң сөйләгән вәгазен дә Айдар белән Хәйдәр бик бирелеп тыңлады...

Кайтканда да алар җәяү кайтырга булдылар. Балалар, кайта-кайтышлый, берсен-берсе бүлдерә-бүлдерә, бәйрәмнән алган тәэсирләрен бабалары белән уртаклаштылар. Йөзләрендә шатлык нурлары уйнаган оныкларының шулай дәртләнеп, очынып-очынып, үзара гәпләшеп кайтулары Галим бабайның күңеленә, җан-тәненә җиңелчә бер рәхәтлек вә ләззәт бирә иде...

# ӘКӘМӘТ ӘКИЯТЛӘР

## МИН ЧӘЧТЕМ КИШЕРНЕ!

Теге әкиятне укып чыктым бит мин, малай. Чөгендер турындагы. Чәчкән кешесен ачыклагач, бик әйбәтләп сөйләрмен, дигән идемме? Дигән идем. Белдем, ачыкладым. Дөрес, ул әкияттә шалкан турында сүз бара. «Шалканны бабай чәчә»,— диелгән анда. Алай түгел. Язучы кеше бутаган. Ялганлаган. Шулкадәр ялганлыйм дигәч тә инде...

Бик беләсегез килсә, мин чәчтем аны! Шалканны түгел, әлбәттә. Чөгендерне дә түгел. Кишер чәчтем мин. Былтыр! Ул вакытта бабай, гомумән, өйдә түгел иде: әллә күрше авылдагы бер танышы янына киткән иде — хәтердә калмаган инде. Минем хәтле өч малай бөркәнерлек зур тун кигәне, кеткелдәп көлә-көлә, ат чанасына утырганы хәтердә калган калуын...

Кыскасы, мин чәчтем кишерне. Иренмәдем, тырыштым. Кишер чәчәр алдыннан түтәлне биш мәртәбә казыдым, тырмаладым — туфракны мамык иттем. Ул су сибүләрем! Беләгем өзелеп төшә дип торам. Ике кулына ике чиләк тотып, суны колонкадан әле энем ташый, мин сибәм — чәйнек чаклы ләйкә белән. Әле мин сибәм, энем ташып тора. Әйтәм бит, көнгә кырык бер чиләк суны кишергә сибә-сибә, кулларымның хәтта агач кашык тотарлык та хәле калмый иде...

Әкияттә генә ул шалкан бик тиз үсә. Үзе үстергән кеше генә белә аның ничек үскәнен. Әкиятне язган кешене әйтер идем инде, шулкадәр ялганлыйм дигәч тә... Бигрәк инде...

Ел буе карап үстердем мин ул кишерне. Әкияттәге шалкан кебек дәү булмады, әлбәттә. Чынлыкта алай булмый ул. Тукмактан аз гына юанрак, зуррак булды. Әле тагын үсәргә хуты бар иде. Шуңа күрә кишерне кабат үз чокырына күмеп куйдым...

Беркөнне диванга чумып кына мультик карап ята идем, тыштан әби әсәренеп керде.

— Улыкаем,— ди,— бабаң белән икәү теге кишерне йолыкмакчы идек тә, безнең генә көч җитәрлек түгел икән! Булышмассың микән, бәбкәм?

Мин, әлбәттә, шундук сикереп тордым. Берәр эш-мазар кушсалар, ялындырып маташмыйм инде мин...

Чыксам... телсез калдым. Әби белгәннәрен укый башлады. «Әстәгым фирулла...»— ди. Әллә ниләр әйтерсең. Соң, мин чәчкән теге кишер, багана юанлыгы булып, кисәк кенә үскән дә безнең авыл өстеннән генә күрше авылга таба агып баручы бер болытка килеп төртелгән.

— Менә кишер бу, ичмасам! — дип, бакчаны яңгыратып кычкырдым мин.— Бабай кая соң әле, бабай?! Күрсен иде менә мин үстергән кишерне!

Башымны горур тотып, әбигә борылып карыйм. Карасам, йөзе ап-ак әбинең! Авызын көч-хәл белән генә кыймылдатып:

— Бабаң... кишер сабагына...ябышкан бит... Әнәтерәк! — диде ул.

Күк йөзенә текәләм. Бәй! Кит аннан! Тизрәк! Егылып төшкәнче коткарырга кирәк бабайны!

Тиз генә баскыч алып килдем дә, кишергә сөяп, югары үрмәләдем. Сабантуйларда ел саен багана башына менеп әтәч алып төшүнең файдасы тиде: «ә» дигәнче бабай янында идем инде. Бабайның бер сүз әйтерлек хәле калмаган. Уң кулы белән кишер сабагын чытырдатып кыскан, сул кулы белән болытның калкыбрак торган бер читенә тотынган...

— Бабакаем,— мин әйтәм,— хәзер, көтеп тор инде бераз гына! Кранда эшләүче Габдерәшит абзыйны алып киләм!..

...Бабайга өч көннән соң гына хәл керде. Теге кишерне моторлы пычкы белән ярты көн турагач, берничә бүкәнен сыгып караган идек — ике чиләк суы чыкты. Шуны эчкәч кенә адәм рәтенә керде минем бабай. Өч ел буе ашадык кишерне. Кинәндек тә соң! Күрше-күләнгә дә бераз авыз иттердек...

Ату, язганнар анда... әкияттә... Шалкан, имеш! Бабай чәчкән, имеш! Тычкан килгәч кенә тартып чыгарганнар, имеш, шалканны!..

Язалар да инде. Ялганлыйм, дигәч тә...

Җенем сөйми ялганчыларны!

## ШҮРӘЛЕ АБЗЫЙ ШҮРЛӘДЕ

Яңа елның борын төбенә килеп терәлгән чагы иде. Мәктәп директоры Галләмов абый үз кабинетына чакырып алды мине.

— Әйдәле, күрсәт бер егетлегеңне,— диде Галләмов абый,— мәктәпкә бик шәп бер чыршы алып кайт әле урманнан!

Минем ялындырып маташмаганны беләсездер инде, шундук ризалаштым.

— Хәзер үк алып кайтыйммы, Галләмов абый?— дидем мин.— Әллә бераздан соңмы, Галләмов абый?

— Үз ихтыярыңда, дустым,— диде Галләмов абый.— Әмма иртәгә мәктәптә булса, яхшы булыр иде.

— Күңелегез тыныч булсын, Галләмов абый,— дидем мин.— Кушылган эшне җиренә җиткереп, намус белән башкарып чыгармын, Галләмов абый! Миңа карата булган ышанычыгызны акларммын, Галләмов абый,— дип тә өстәдем.

Әйе, әйе, бернинди каушаусыз, бернинди тотлыгусыз шулай дип әйтеп әйттем.

Галләмов абый минем көчле кулны кысты, баһадирларныкы шикелле җилкәмнән үз итеп сөеп, миңа хәерле юл теләде.

— Иптәшкә берәр малайны да ал үзеңә,— диде Галләмов абый.

— Бездәйләргә килешеп бетмәс юеш танауларны ияртеп йөрү! — дип җиффәрдем мин эре генә.

Киттем, ат чанасы кадәр зур чана тартып. Әле сукмак буйлап элдертәм, әле бил тиңентен көрт ерып барам. Бер утыз-утыз ике минут чамасы вакыт үткәндер үтсә — килеп җиттем урманга. Шундук бик матур бер чыршыга юлыктым. Андый чыршыны сезнең төштә дә күргәнегез юктыр әле. Чанадан балтаны ал...ыйм дисәм,— балта юк. Онытылган. Алырга оныткнмын...

Йөрим шулай чыршы тирәли әйләнеп. «Ничекләр генә апкайтырга соң моны?»— дип баш ватам үзем. Шулчак күрәм: каршыдагы куак артыннан бер ал... ал... басты калкып чыкты. Иреннәрем кыймылдаганын сизәм, ә үзем тамчы да курыкмыйм. Кил, мин әйтәм, якынрак кил, алай-болай тияргә уйласаң... Хәер, мин сине балтасыз да бөтереп сала алам инде...

Кинәт танып алдым тегене — шүрәле бит бу!

— Ай-яй, суык,— диде бу килә-килешкә,— әллә соң бераз «кети-кети» уйнап алабызмы? Сиңа әйтәм, адәми зат?

Миндә куркуның әсәре дә юк, аяклар гына бераз дер-дер килә.

— Шүрәле абзыкаем,— мин әйтәм,— бүген көн, ай-яй, суык шул. «Кети-кети» уйнап кына җылынып булыр микән?

Шүрәле абзый килбәтсез озын бармакларын уйнаткалап алды.

— Зыян юк, җылынырмын,— диде ул төксе генә.

— Әллә, Шүрәле абзыкаем,— дидем мин моңа,— авылга кайтып җылы кием алып килимме үзеңә? Өйдә бабайның иске толыбы бар иде...

— Кирәкмәс, адәми зат,— диде Шүрәле абзый.— Сезнең халыкка ышаныч та шулкадәр генә... Моннан күп еллар Былтыр дигән бер адәми зат уң кулымның бармакларын харап итте. Агач ярыгына кыстырып... Төзәлүен төзәлде бармаклар. Әмма хәзер элеккеге дәрт белән «кети-кети» уйнап булмый...

Шүрәле абзый зарланган арада башыма бер хәйләкәр уй килде.

— Шүрәле абзыкаем,— мин әйтәм,— әйтергә дә уңайсыз инде: Былтыр дигән ул адәми зат минем бабайның әтисе булган бит...

Шүрәле абзый шүрләде. Йөзе кардай ап-ак булды. Минем аяклар дерелдәүдән туктады.

— Соң, кем, агай-эне, нишләп баштук әйтмәдең аны,— диде Шүрәле абзый, елмаеп.— Бераз төсмерләп алган идем алуын — Былтыр чалымнары бар шул үзеңдә...

Мин билләремә таянып сөйләшә башладым.

— Безнең фотоальбомда Былтыр бабайның рәсеме дә саклана әле,— дидем мин эре генә.— Узганелбикә әби белән бергә төшкән булганнар.

Бу сүзләрдән соң шүрәле бөтенләй эреде. Тирләп чыкты.

— Былтыр абзый бик яхшы адәм иде. Киң күңелле иде. Син дә шуңа охшагансың. Йә, нинди ярдәм кирәк? Әйт, хәзер үк эшлим,— диде шүрәле.

— Һем-м,— дидем мин, уйланган кыяфәт чыгарып.— Алай эшләргә бик ашкынып та торгач... Менә бу чыршыны йолкып чанага сал, алайса...

— Бик шатланып, абзыкаем,— диде шүрәле һәм каударланып чыршыны йолкый да башлады, «ә» дигәнче чанага илтеп тә салды.

— Булды, абзыкаем, тагын ни эшләргә боерасыз? — диде шүрәле нәүмиз генә.

«Гайрәт тә бар икән бу урман сарыгында!»— дип уйлап алдым мин.

— Хәзергә бүтән эш юк әле сиңа. Эш булуга, әйтермен. Чао!

Мин, чананы тартып, кайтырга кузгалдым.

— Чао, абзыкаем, чао! — дип сикеренгәләде шүрәле.— Абзыкаем, саубуллашканда исемегезне әйтеп калдырмассыз микән?

— Исемдәмени хикмәт! — дип кычкырдым мин.

— Әйе шул, абзыкаем, Исемдәменихикмәт! — дип сөйләнеп калды теге... ялагай.

Җенем сөйми ялагайларны!

## ЗӨҺРӘ КЫЗ — БЕЗНЕҢ АВЫЛДАН

Зөһрә кызны минем бабай күргән бит, малай. Безнең авыл кызы икән ич ул! Ант әгәр!

Бабайның әле миннән бер-ике яшькә кечерәк чагы булган. Шулай бервакыт капка төбендәге арка терәгечле эскәмиядә баллы сагыз чәйнәп утыра икән бабай. Чәйни икән, чәйни икән... Тәме беткәч, сагызны черт иттереп кенә җиргә төкерә икән дә таушалып, агарып каткан джинсы чалбарының тез турысындагы кесәсеннән янә баллы сагыз алып авызына каба икән. Шулчак күрә бабай: колонкадан су алырга дип, көянтә-чиләкләрен асып, югары очтан Зөһрә кыз төшеп килә! Ай-яй, чибәр булган ул Зөһрә кыз! Аны күргәч, сагыз чәйнәүләрем онытыла иде, дип сөйләгәнен яхшы хәтерлим әле мин бабайның. Менә Зөһрә кыз колонкага килеп җитә. Көянтәсен кое бурасына сөяп куя да чүмеч белән чишмәдән су тутыра башлый. Үзе нindiдер моңсу җыру җырлый икән...

Шунда Зөһрә кызның моңланып җырлавын Ай ишетеп алган. Ишетеп алган да Зөһрә кызга ялвара икән.

— Зөһрә кыз, мин сине үземә тартып алам, балда-майда йөзәрсең, әгәр тансы-мансы, шейк-мейк биисең килсә, ике япунский магнитофоным да бар, берсе төсле күрсәтә,— дигән.

Зөһрә кыз риза булмаган. Соң, япунский магнитофонга кызыгырга җүләр дип белдегезме әллә сез безнең авыл кызын? Шуннан Ай әйткән:

— Мин сиңа илле сигез луноходымның алтмыш икесен бирәм, мин сине үз яныма тартып алам барыбер! — дигән.

Зөһрә кыз моның көмеш кашык кебек ялтыравык күзләренә карап-карап торган да болай дигән:

— И Ай абзыкаем, миңа бернәрсә дә кирәкми. Өстем-башым бөтен, тамагым тук. Тик менә өченче көн математикадан ялгыш «икеле» алган идем, әгәр кулыңнан алай эш килсә, син шуны «бишле»гә әйләндер.

— Минем өчен бернигә дә тормый ул «икеле»не «бишле»гә әйләндерү! — дип мактана икән Ай.

Зөһрә кыз шуннан соң гына ризалашкан. Көянтә-чиләген иңенә аскан да Айга менеп киткән. Бу тамашаны күзәтеп торган бабай исә, үзе дә сизмәстән, сагызын ялгыш йотып җибәргән. Әле ярый чалбарының арткы кесәсендә тагын бер сагыз булган.

Менә шул. Кара, әйтергә онытып торам икән. Теге, өченче көн математикадан алган «икеле»не тәки «бишле»гә әйләндермәде бит Ай. Сүзендә тормады. Бик каты укып, үземә төзәтергә туры килә инде, болай булгач...

Җенем сөйми үз сүзендә тора алмаганнарны!

## БАХ-БАХ! ГӨРС-ГӨРС!..

Мин уйладым-уйладым да Зөһрә кызны алып төшәргә булдым. Икеләнеп тору юк, Айга менәм дә әйтәм:

— Җитте, Ай дус, мин Зөһрә кызны алып китәргә килдем! — дим.

Әгәр дә Ай карышып маташса:

— Бирмим, фәлән-төгән, фәсмәтән,— дип боргаланып маташса, үзенә үпкәләсен.

Ике уйлап тору юк, маңгаена имән бармагым белән бер генә чиертермен — ике җирдән эскерт кадәрле күгәргән шеш бүлтәеп чыгар. Инде алай да риза булмаса, чәченнән тартырмын. Аны гына булдырам мин. Алай да барып чыкмаса, иптәшкә үзем кебек берәр таныш малайны алып менәрмен. Бер таныш боксчы малай бар минем. Үз башы чаклы кара күн перчаткасы белән бер-ике мәртәбә «бах-бах! гөрс-гөрс!» иттерүе булыр, Зөһрә кызның безнең өйдә коймак белән тәмләп чәй эчеп утыруы булыр...

Мускулларымны капшап карыйм. Тал кебек кап-каты. Штангачыларныкы шикелле. Мондый мускул белән мин Айны берүзем дә җиңә алам инде алуын. Шулай да бер иптәш булса, ышанычлырак. Әгәр иптәш дигәнең куркак булып чыкса? Иң кыен чакта мине ташлап качса? Минем башымда Зөһрә кызны алып төшү уе калыр микән соң?

Шул шул.

Җенем сөйми куркакларны!

## ХЫЯЛЫЙ АКБАЙ

Яшәгән, ди, Акбай исемле бер маэмай.

Ул күк йөзенә текәлеп хыялланырга яраткан.

— Их, самолёт кебек оча алсаң иде! — дип, татлы хыялга бирелгән ул бер көнне.— Болытлардан да өстә очасың... Очасың... Аста бәп-бәләкәй өйләр, кешеләр, этләр, мәчеләр...

Шулай дип хыялланган вакытта гына аның башына куркыныч уй килгән: «Әгәр ялгыш мәтәлеп төшсәм... Һай!..»

— Юк, самолёт булмыйм! Мин... Мин матай булам!..— дигән ул бераздан.— Юлдан тузаннар туздырып сыптырасың гына! Җил сызгыра... Юл читендә каз бәбкәләре куркышып кала... Шәп!

Шулчак аның башына янә шомлы уй килгән: «Әгәр коймага-мазарга бәрелсәм... Һай!..»

— Иң яхшысы — моторлы көймә булу! Суда койма да, агачлар да юк... Дулкыннар чәчрәтеп алга очасың! Балыклар ян-якка сикерешә... Җил сызгыра... Искиткеч!

Шул вакытта ул тагын борчылып куйган: «Әгәр суга батсам?»

— Трамвай булсаң иде менә! — дигән ул, күпмедер вакыттан соң.— Рельслар буйлап келтер-келтер чабасың да чабасың...

«Чабуын чабарсың да... Әгәр рельстан ялгыш читкә чыксаң?! Һай!»— дип куркып куйган ул янә.

— Әллә маэмай булырга микән?— дип уйлаган ул бераздан.— Әйе шул, маэмай булырга кирәк... Туктале, бәй, мин үзем маэмай лабаса!..

Кыскасы, маэмай маэмай булып калган. Ә хыяллануыннан туктамаган.

— Үсеп җиткәч мин генерал булам! — дип хыяллана ди ул хәзерге вакытта. Тик менә ничек әйтергә микән инде ул маэмай Акбайга: этләр бит үскәч тә генерал булмыйлар.

Әллә булалар микән?

## МАКТАНЧЫК МЫРЫЙНУР

Мырыйнур шәһәрдән кайтты. Аны күргәч, авыл мәчеләре барысы да «ах» итте. Үзе ябыккан — чыра кебек инде менә. Өстендәге күлмәге-чалбары, ертылып, теткәләнеп беткән. Җитмәсә нечкә муенына нәзек чылбыр белән калай тычкан таккан булган.

— Мырыйнур, ничек соң, шәһәрдә шәп яшәдеңме?— дип сорады аннан Мыраугали исемле тук чырайлы мәче.

— Әйе, шулхәтле шәп яшәдем! Искиткеч! — дип җавап кайтарды Мырыйнур һәм баш бармагын югары тырпайтты.

— Ашау ничек соң калада?— дип сүз катты Мыяубикә.— Ризыклар һаман да талонга гынамы?

— Ашау — байларча! Көн саен балык: тозлысы, кипкәне, шулпада пешкәне... — дип санап китте Мырыйнур.

— Ә тычканнар? Тычканнар бармы шәһәрдә?— диде Мыраугали, төкерекләрен көчкә йотып.

— Көн саен ашадым аларны: каклаганнарын, кыздырылганнарын...

— Шәһәрдә дә яшәргә була икән, алайса?! — диде Мыяубикә.

— Әлбәттә, әлбәттә! — диде Мырыйнур.— Әле ничек кенә яшәп була! Көн саен сөт эчтем: сыерныкын, кәҗәнекен, күгәрченнекен... Каймакларны әйтәсе дә юк!

Авыл мәчеләре телләрен чыгарып, иреннәрен ялманып алдылар.

— Шәһәр шәһәр инде! Хәерче авыл түгел,— диде Мырыйнур.

Авыл мәчеләренең берсенең дә шәһәрдә булганнары юк иде шул. Шуңа күрә алар бердәм көрсенеп куйдылар.

— Шәһәр — оҗмах ул! — диде Мырыйнур, үзен шаккатып, авызларын зур ачып тыңлаучыларга күңеле тагын да булып.

Шулвакыт Мияугөл исемле мәче каяндыр зур тәлинкәгә салып сөт алып килде. Авыл мәчеләре дәррәү сөт эчәргә керештеләр.

Мырыйнурның авызыннан сулар килде.

— Дөресен генә әйткәндә,— диде ул,— минем күптән җүнләп ашаган-эчкән юк инде!..

Авыл мәчеләре тәмләп сөт чөмерү белән мәшгуль иделәр, алар Мырыйнурның ошбу сүзләрен ишетмәделәр.

## ТӘГӘРМӘЧЛЕ ЧАНА

Әтинең тавышы янә кабатланды:

— Тәбрис, дим!

— Әү, әти!

— Карале, улым, мин сиңа нәрсә алдым!

Әти дүрт тәгәрмәчле... чанага төртеп күрсәтте.

— Тәгәрмәчле чана булмый бит, әти,— дидем мин.— Каян таптың син моны?

Әтинең авызы ерык.

— Була икән шул, улым, була икән,— ди.— Менә кара, руле дә бар аның...

— Әтием,— мин әйтәм,— бер шуып карыйм әле моның белән?

Әти, елмаеп, баш кага: бар, янәсе, теләсәң — шу, теләсәң — тәгәрмәчләрен тәгәрәт...

Бүрекне батырып кидем дә чанага җайлап утырдым. Мин утырганны гына көткән диярсең, чана выжылдап шуып та китте. Ул арада каяндыр буран чыкты. Күзләрне ачып та булмый. Карлар биткә сылана. Җил борын очын чеметеп-чеметеп ала. Чананың, самолёт шикелле, җирдән аерылганын тойдым. Куллар туңа башлады. Җитмәсә тәгәрмәчле чанам каядыр «гөрс» итеп бәрелде...

Күземне ачуга, исем китте: каршымда мамык шикелле йомшак бер дәү алма тора. Сап-сары. Кояш шикелле. Чанам шуңа килеп сыланган икән. Ватылмаган ватылуын. Алдагы ике тәгәрмәч «сигезле»гә әйләнгән. Бары шул гына. Җайлап кына җиргә төшеп басуым булды, теге сап-сары алманың артка таба шуып китүе булды. Шулай бер ун метрлар чамасы шугач, туктады бу. Бераздан соң, алма түбәсендә люк сыман бер нәрсә ачылды да аннан... аннан... әллә нинди сәер кешеләр чыга башлады. Берәү... икәү... өчәү... Алты! Мин, багана шикелле, бер урында үрә катып басып торам. Шуннан болар миңа якынлаша башладылар. Килеп җиттеләр дә, миңа игътибар да итмичә, чананы җентекләп карый башладылар.

— Фырфырфу! — диде сәер кешеләрнең берсе, «сигезле» ясалган бер тәгәрмәчкә уң аягы белән типкәләп. Шунда гына мин аларның кыяфәтләрен шәйләп алдым. Барысының да башлары зур, чәчләре сап-сары һәм бөдрә. Иң гаҗәпләндергәне бу түгел икән әле. Иң гаҗәпләндергәне шул: барысының да колаклары башның сул ягында. Икесе дә. Аслы-өсле.

«Фырфырфу» дигәне чананың арткы тәгәрмәчләренә дә типкәләп алды. Үз эшләренә күз йөртеп чыкты да:

— Выжжын-выжжын фис! — диде.

Тегеләр, ризалык белдергәндәй, башларын селкеп алдылар.

— Чамырпуф! — диештеләр.

«Фырфырфу» минем каршыма килеп басты. Әле киез каталарга, әле бүреккә карады. Шуннан соң болай диде ул:

— Шыбыраем-шыбыраем, көшкөшкөш?!

— Сезнекен пер сүз тә пелмәс! — дидем мин, аларчарак әйтергә тырышып.

— Зыян юк, аның каравы без беләбез сезнеңчә,— диде «Фырфырфу».— Син үзеңнең кая килеп эләккәнеңне беләсеңме? Юктыр шул. Белмисеңдер. Бу — Кушколак планетасы!

Минем эчкә суык йөгерде. Менә сиңа мә! Ничек кайтам инде мин Җиргә?! Бу бит минем бер генә дә ишеткән-белгән планета түгел. Ай, Венера, Марс булса — бер хәл иде. «Кушколак» ди бит...

— Борчылма,— диде «Фырфырфу», минем уйларымны сизенгәндәй.— Үзеңне тәртипле генә тотсаң, Җиргә, бәлкем, кайтып та килерсең әле.

Башкалар янә башларын селкеп алдылар.

— Минем исем — Чипчип, синеке ничек?— диде «Фырфырфу».

— Тәбрис,— дидем мин.— Фамилияне дә әйтимме?

— Анысын әйтмәсәң дә була. Безнең беребезнең дә фамилияләр юк. Исемеңне Тәдрик дидең мәле?

— Юк. Тәб-рис!

— Кычкырма! Нигә ул хәтле кычкырасың? Без пышылдап әйткән сүзне йөз километрдан ишетәбез. Карале, нишләп яланаяк басып торасың син?

— Ничек яланаяк булыйм ди! Киез катаны күрмисең мәллә? — дип аякларга караган идем — чынлап та яланаяк икәнмен. Соң, әле генә бар иде бит. Кызык! Әйтәм аны, аяклар туңа башлады...

Шулвакыт мин уянып киттем.

Юрган идәнгә шуып төшкән икән...

## ЯШЕЛ КУЫК

Уенчыклар кибетеннән куык сатып алдым. Ямь-яшелне. Кибеттән чыгуга ук, тирән итеп суладым да куыкны кабартырга тотындым. Әй өрәм, әй өрәм... Яңакларым бер бүлтәя, бер кысыла. Ниһаять, җитте — куыгым зур карбыз кадәр булды. Кәтүк җебе белән авызын бәйләргә генә уйлаган идем, Яшел куык чәрелдәргә кереште:

— Тагын өр, тагын өр! Минем үсәсем килә! Әнә теге болыт хәтле буласым килә! — диде ул. Һәм, күк йөзендә ак корабны хәтерләтеп, салмак кына йөзеп барган болытка төртеп күрсәтте.

Мин карышып маташтым:

— Өрмим! — дидем.

— Өрәсең!

— Эт түгел лә мин өрергә!

— Өрәсең, дим!

— Өрмим дигәч, өрмим инде!

— Өрми генә кара! — дип янады миңа Яшел куык.

Ә мин өрергә уйламадым да. Янап кына, боерып кына эш чыкмасын аңлады, ахры, Яшел куык — җилдә бәргәләнә-бәргәләнә елый башлады. Елаганнарын күрсәм, түзә алмыйм инде мин — күзләремнән яшь тамчылары атылып чыга. Шуңа күрә тиз генә күз яшьләрен сөртеп алдым да риза булдым.

— Ярый, алайса, өч мәртәбә өрәм. Бүтән ялварып та, ялынып та торма — файдасы булмас,— дидем.

Шулай дип әйтүем булды, Яшел куык шатлыгыннан сикергәләргә тотынды:

— Урра! Болыт кадәрле булам!

Янә тирән итеп сулыш алдым да авыз эчемдәге тыным беткәнче өрдем — Яшел куык озыная төште, кыяфәте сыек яшелгә әйләнде.

— Булды— бер! — дидем мин.

Тагын өрдем — Яшел куык юанайды.

— Булды — ике! — дидем мин.

Тагын өрдем.

— Булды...

Шарррт!

Яшел куык юкка чыкты.

# СӘЯХӘТЧЕ ФИМ-ФОМ, УКЫМЫШЛЫ КӘҖӘ ЯКИ АЛАРНЫҢ АЛДАРСТАН ИЛЕНДӘ КҮРГӘННӘРЕ

Яшәгән, ди, Фим-Фом исемле бер сәяхәтче. Аның аерылмас юлдашы — Мики-Кики исемле укымышлы кәҗәсе булган. Ул кәҗәнең Фим-Фомга ошамый торган бик начар бер гадәте булган: сөйләшкән вакытта да, китап укыган чакта да, берәр тамаша караганда да өзлексез кәбестә чәйни икән. Үзе кәбестә чәйни икән, үзе авыз эченнән генә: «Микики-ки-микики, иң шәп сакал миники...»— дип җырлый икән. Фим-Фом, аны кәбестә чәйнәвеннән берничек тә биздерә алмагач, кулын гына селтәгән, ди.

Сәяхәтче Фим-Фом тумышы белән Чынсөйләрстан дигән илдән булган. Мики-Кики белән ул Кәбестән мәмләкәтенә сәяхәт кылган вакытта таныша. Һәм, шул танышкан көннән башлап, алар аерылмас юлдашлар булып киткәннәр, ди...

Алдарстан иленә сәяхәт — Фим-Фом белән Мики-Кикинең бергә ясаган тугызынчы сәяхәте. Моңа кадәр алар Корымстан иленә, Шау-шу каласына, Бериснимдәтөчкерәм төбәгенә, Сарыл тавына, Очкылык авылына һәм башка шундый сәер исемле илләргә сәяхәт иттеләр.

Алдарстанда аларга иң беренче очраган кеше чыбыркысыз Көтүче булды. Хәер, чыбыркысы гына түгел, көтүе дә юк иде бугай аның. Фим-Фом аннан: «Көтүең кая соң синең, туган?»— дип сорарга кыенсынды. «Юк-бар сорау биреп, кешене рәнҗетүем бар»,— дип уйлады ул. Мики-Кики кәбестә чәйнәү белән мәшгуль иде. Шуңа күрә ул бу хакта берни дә уйламады. Аның уе башкада иде: «Көтүченең тәмле кәбестәсе юк микән? Сорасам, бирер микән?»

Чыбыркысыз Көтүче сүзгә бик юмарт булып чыкты. Ул иң элек Алдарстанда булган соңгы вакыйганы бәян итте.

— Борчакшыттырам авылының Түбән очында яши торган тел бистәсе Хөрмиянең әнисенең бертуган апасына чыбык очы кардәш тиешле Гатаулла карт белән бер үк мәдрәсәдә укыган Сәлмән карт улының төпчек малае Фикус олтарайга кило ярым сөтле конфет откан. Шул конфетларны суырып бетергәч, Борчакшыттырам авылының Түбән очында яши торган тел бистәсе Хөрмиянең әнисенең бертуган апасына чыбык очы кардәш тиешле Гатаулла карт белән бер үк мәдрәсәдә укыган Сәлмән карт улының төпчек малае Фикус ни күрсен: моның авызындагы үз тешләре урынына агач тешләр үсеп чыккан! Үсеп тә чыккан ул агач тешләр һәм, яз җиткәнне көтеп тә тормыйча, яфрак ярырга да тотынган. Атна-ун көн дә үтмәгән, һәр тештән кило ярым сөтле конфет җыеп алганнар. Хәзер шул Борчакшыттырам авылының...

Чыбыркысыз Көтүче тәмләп, тәфсилләп сөйли калды, сәяхәтче Фим-Фом белән укымышлы Мики-Кики сәфәрне ары дәвам иттерделәр. Озак бардылар алар, җиде көн, җиде төн бардылар. Һәм, ниһаять, Авызданкошочырам дигән бер калага килеп җиттеләр. Әлеге калада алар мондый бер тамашага тап булдылар. Бик зур мәйданга халык җыелган. Берәүләр кызып-кызып нидер сөйлиләр, икенче берәүләр «Алдыйсың!» дип, өченче берәүләр «Дөресен сөйлисең!» дип кычкыра. «Алдыйсың!» дип тә, «Дөресен сөйлисең!» дип тә ачыргаланып кычкырган бер малайдан сорады Фим-Фом: «Әйтмәссең микән, энекәш, нинди тамаша бу?»

Малай сәерсенеп кенә карады да:

— «Дөресен сөйләүчеләр ярышы» бу, абзыкай,— диде һәм янә «Алдыйсың!», «Дөресен сөйлисең!»— дип кычкырырга тотынды.

Фим-Фом белән Мики-Кики дөресен сөйләүчеләрнең сүзләренә колак салдылар.

Кемдер бер агайның сүзләренә каршы:

— Дөресен сөйләп ялганлыйсың! — дип кычкырды.

— Минем кызым төшендә албасты күргән,— дип сөйли башлады икенче бер кеше.— Кызым әйтә: «Ул җен, этием, гел сиңа охшаган иде»,— ди... Минем сакалга ишарәләве инде кызымның...

— Алдаладың, ярыштан төшеп каласың! — дип кычкырды баягы адәм.— Синең сакалың юк бит!

Теге агайның, чыннан да, сакалы юк иде.

«Мин чыгып сөйләсәм, бөтенесеннән дә уздырачакмын инде»,— дип уйлады Фим-Фом. Мики-Кики берни дә уйламады, ул әлеге дә баягы, шул кәбестәсен чәйнәү белән мәшгуль иде. Шулчак аның карашы каршындагы язуга төште. Анда «Чынсөйләрстан иленнән килгәннәр бу ярышта катнаша алмый!» дип язылган иде. Мики-Кики Фим-Фомның кабыргасына тоягы белән төртеп алды.

— Аңлашылды,— диде Фим-Фом.— Киттек, Мики-Кики!

Болар юлларын янә дәвам иттерделәр. Шулай бара торгач, Фим-Фом белән Мики-Кики алдына зур бер елга пәйда булды. Елга аша салават күпере салынган иде. Шул күпергә кердек дигәндә генә, аларның каршында бер карт калыкты.

— Ашыкмагыз әле, илгизәрләр,— диде карт.— Бу салават күпере — гади күпер түгел. Тылсымлы күпер. Моның аша бары тик саф күңелләләр генә чыга ала. Шәт, сез шундыйлардыр инде. Шикләнмим. Әгәр сез теге ярга чыгарга бик телисез икән, миңа берәр ялган сөйләгез. Шундый итеп алдагыз, мин ышанырлык булсын!

— Бабай, алдап торырга безнең вакытыбыз юк иде шул,— диде Фим-Фом.— Биш минуттан телевизордан Шүрәле турында мультфильм була. Безнең шуңа ашыгуыбыз иде.

Мики-Кики, кәбестә чәйни-чәйни, «әйе» дигән мәгънә белдереп, башын селкеде.

Бабай эче катып көлде.

— Мине болай итеп үк алдаганнары юк иде әле! — дия-дия көлде.— Шүрәле дисеңме?! Мультфильм дисеңме? Хи-хи-хи...

Бераздан ул көлүдән туктады:

— Алдаша беләсең икән, энем,— диде.— Барыгыз, юлыгызга — ак җәймә!

Фим-Фом белән Мики-Кики салават күпере аша аргы ярга чыгып киттеләр.

Ә ул көнне телевизорда чынлап та мультфильм булды. Шүрәле турында.

## БИШ БАРМАК

Диңгездә кояш, күк йөзендә балыклар йөзгән бер заманда яшәгән, ди, Башбармак, Имәнбармак, Уртабармак, Исемсезбармак һәм Чәнтибармак исемле биш агай-эне. Зәмһәрир суыклар вакытында алар бияләй эчендә гомер иткәннәр. Ә кояшлы, җылы җәй көннәрендә аларның торыр урыннары булмаган. Дөрес, күп вакытларын алар чалбарларның кысан кесәләрендә үткәргәннәр. Кич җиткәч, телевизордан «Әлли-бәлли-бәү» дигән язу күренгәннән соң булган барлык тапшыруларны карап бетергәч кенә йокларга ятканнар бармаклар. Йокы-мазар тәтемәгән чакларда алар кояшта кызынганнар, су коенганнар, әбәкле һәм качышлы уйнаганнар.

Һәр бармакның үзенә генә хас шөгыле булган. Мәсәлән, Башбармак еш кына шапырынырга, мактанырга яраткан. Муенын турайтып, башын тырпайтып, сипкелсез борынын югары чөеп, башка бармакларга кырын гына карап:

— Мин — Башбармак! Мин — Шәпбармак! — дип көнгә кимендә өч-дүрт мәртәбә әйтмәсә, ашаган ризыгы тамагыннан үтмәгән, йокысы йокы булмаган.

Имәнбармак, гадәттә, башкалардан көләргә яраткан. Кемгәдер төртеп күрсәтеп:

— Әй! Сезгә әйтәм! Карагыз әле тегеңә, карагыз! Уф, үләм! Ха-ха-ха... Хи-хи-хи...— дип, һавада сикерә-сикерә шаркылдый икән. Көлеп туйгач, кое казырга, әй, түгел лә, борын казырга тотына икән.

Уртабармакның эше ансат булган. Ул башкалар ни кыланса, шулар булып кыланган. Бармаклар үзара сугышканда, кайсы як җиңсә, шул якка авышкан.

Исемсезбармак калын-калын китаплар актарып үзенә исем эзләүдән башканы белмәгән. Тау-тау китапларны күздән кичерсә дә, күңеленә хуш килердәен тапмаган.

Инде Чәнтибармакка килсәк...

Кул кашыкка йә чынаякка үрелгәндә, Чәнтибармак кыска һәм нечкә муенын булдыра алганча сузып, башкалардан аерылырга теләгәндәй, читкә каерыла икән. Бөтен белгән сүзе бер дистәдән артмаган.

Аның бик еш кабатлый торган «Чүп! Пүчтәк! Хи! Миңа димәгәе!» сүзләреннән һәркем туеп беткән.

Күргәнегезчә, бармакларның бишесенең дә кимчелекле яклары күп булган. Әмма көннәрдән беркөнне бармаклар кинәт кенә уңай якка үзгәреп киткәннәр. Ничек дисезме? Бик тиз дисезме? Сере бик гади аның. Сәлим атлы бер малай, мәктәптән кайтып барганда, күрше кызы Алсуга: «Мин моннан соң, Алсу, бик әйбәт малай булачакмын, менә күр дә тор!» дип сүз биргән. Һәм Алсуның китап-дәфтәрләр тулы сумкасын кулына алган. Шулвакыт, безнең әлеге бармаклар, үзләре дә сизмәстән, бердәм рәвештә сумка тоткасын җайлап кына кысып тотканнар да салмак кына атлаган Сәлим атлы малай белән бергә киткәннәр.

## МИКИ-КИ-КИ!

Беркөнне Кәҗә-Кәҗәләй радиодан ишетте: ниндидер бер кәҗә туксан сигез телдә сөйләшә белә икән. Шушы хәбәрдән соң Кәҗә-Кәҗәләйнең төн йокылары качты. Силос тәме килеп торган кәбестәне чәйни алмый азапланды, чәйнәгәнен йота алмый интекте. Соңгы араларда шактый мантый башлаган Кәҗә-Кәҗәләй күзгә күренеп ябыкты — акшарлы мичкә сөяп куелган кисәү таягына әйләнде дә калды. Эшләр болай мөшкелләнсә, Хуҗа Насретдин ишәге кебек җан тәслим кылуың да бар. Шулай да Кәҗә-Кәҗәләй соңгы чиккә җиттем инде дигәндә генә үзен кулга алып өлгерде. «Мин кемнән ким?! Нишләп әле мин дә башка кәҗәләр телен өйрәнмим? Мин булдыра алмыйм мәллә аны?»— дип уйлады ул.

Кәҗә-Кәҗәләй, җиң сызганып, чит телләр өйрәнергә кереште. Иң элек ул җирән сакаллы кәҗәләр телен үзләштерде. «Бу телне мин чәйнәп кенә йоттым»,— дип мактанганнан соң, Кәҗә-Кәҗәләй мыштым кәҗәләр телен өйрәнә башлады. Телнең бусы өйрәнү өчен бераз авыррак булып чыкты. Кәҗә-Кәҗәләй «микокукио» сүзен әйтә алмый интекте. Бу сүзне аңа, һичшиксез, өйрәнергә кирәк иде. Чөнки бу сүз исәнләшүне аңлаткан сүз иде. «Микокукио» — безнеңчә «Сәлам, аңгыра сакал» дигән сүз.

Шуннан соң Кәҗә-Кәҗәләй сөзгәк тау кәҗәләре телен, иркен кыр кәҗәләре телен һәм тагын бик күп, бик күп кәҗәләрнең телен өйрәнде.

Хәзер Кәҗә-Кәҗәләй бик тырышып үз телендә сөйләшергә өйрәнә, дөресрәге, азаплана. Шактый интегә торгач, бер сүзне әйтергә өйрәнде: ул сүз «ми-ки-ки» иде.

## МӘЧЕ МАЛАЕ ШУКБАЙ

### Беренче танышу

Ямьле җәй көне иде. Мәче малае Шукбай каладан авылга, әбисенә кунакка кайтты. Оныгын күргәч, әбисе шундый сөенде инде, шундый сөенде! «Йомшагым минем, наяным минем»,— дия-дия, Шукбайга җылы сөт эчерде, тәмле коймаклар ашатты. Шукбай, ашап туйгач, нәни мыекларын сыпырып, иреннәрен ялаштырды да әбисенә рәхмәт әйтеп, урамга, мәче малайлары белән танышырга чыгып китте. Үзе белән фотоаппаратын да алды.

Мәче малайлары Шукбайның кайтканын күптән ишеткән булганнар икән. Алар, түземсезләнеп, Шукбайны капка төбендә көтеп торалар иде.

— Кунак малае, исемең ничек синең! — дип сорады Майлай исемле мәче малае.

— Мырауҗан улы Шукбай! — дип чатнатып җавап бирде Шукбай. Ул шулай чатнатып җавап бирергә мәчеләр бакчасында өйрәнгән иде.

— Озакка кайттыңмы? — Бу сорауны Сармай исемле мәче малае бирде.

— Бер атнадан артык торып булмас! — диде Шукбай һәм өлкән мәчеләр шикелле тамак кырып куйды.— Әти белән Кара диңгез буена ял итәргә барасыбыз бар.

— Фотоаппаратың да бар икән,— диде Майлай.— Әйдә, безне карточкага төшер әле!

— Карточкага төшерә алмый ул,— диде Сармай.— Тасмасы юк бит аның... Хи-хи-хи!.. Безгә мактаныр өчен генә алып чыккан бит ул фотоаппаратын...

— Ник булмасын, бар! — диде Шукбай.— Әйдә, һәммәгезне сурәткә төшерәм. Бер... ике... өч!..

Эскәмиягә утырып та, капка төбендәге бүрәнәләргә ятып та, чирәмгә ятып та сурәткә төштеләр мәче малайлары.

— Карточкаларны кайчан ясыйсың соң?— диде Майлай бераздан.

— Калага кайткач ясыйм мин аларны. Монда минем карточка ясый торган әйберләрем юк,— диде Шукбай.— Ясагач, барыгызга да җибәрермен!

— Миңа икешәрне ясарсың, яме! — диде Сармай.

— Ярар.

## Икенче танышу

...Чолан белән танышып йөргәндә, Шукбай кемнеңдер карашын тойды. Артына борылып караган иде, агач кисмәк артына поскан нәни генә бер җан иясен күреп алды.

— Син кем?— дип сорады Шукбай дер-дер килеп торган әлеге җан иясеннән.

Җан иясе кисмәк артына тагын да елыша төште дә:

— Мин... мин... мин... Чәпчи булам... Тычкан малае...— диде.

Шукбайның тере тычканны беренче мәртәбә күрүе иде. Моңарчы тычканнарны ул телевизордан гына күреп белә иде. Аннан соң «Батыр тычкан маҗаралары» дигән бик матур рәсемле китапта күргән иде бугай аларны. Һе, менә нинди була икән ул тычкан, тере тычкан!

— Ә син кемнән куркасың болай? Әллә миннәнме? — диде Шукбай.

— Ә... ә...йе, с...сс...сссин-нән! — дип чыелдады Чәпчи.

— Мин шулай бик куркынычмыни?

— Ю-ю-ю-ук... әй... кур... кур...кыныч!

— Курыкма. Минем беркемгә дә тигән юк,— диде Шукбай.

Чәпчи тынычланды.

— Менә, кара, Чәпчи, минем күзләр ялганчы мәче баласыныкына охшаганмы?

— Охшавын охшамаган да...

Шулчак әллә каян гына Чәпчинең әнисе килеп чыкты да, тычкан малаен эләктереп, юкка да чыкты. Шукбайга Чәпчинең «Әйбәт малай ул, әнием!» дигән сүзләре ишетелеп калды.

«Кызык,— дип уйлады Шукбай,— тычканнар нигә миннән куркалар икән? Әбиемнән сорыйсы булыр...»

## Шукбай балык тота

«Иртәгә китәм инде» дигән көнне мәче малайлары Шукбайны балык каптырырга Ялтырап Ят елгасына алып киттеләр. «Безнең елгада әллә нинди зур балыклар бар!»— диде Майлай. Сармай да мактанасы итте: «Бервакыт мин иң зур эт кадәрле шыртлака каптырдым, беләсең килсә!»— диде. «Балык шулпасыннан авыз итәргә авылның барлык мәчесе җыелган иде!» — дип тә өстәмәкче иде дә, Майлайның усал карашын тоеп, «Качып кына котылды»,— дию белән канәгатьләнде.

Көн кояшлы иде. Әмма шуңа да карамастан, мәче малайлары бер генә балык та каптыра алмады. Кая ул Сармай тота язган эт кадәрле балык каптыру, тычкан тәпие хәтле маймыч та эләктерә алмадылар алар. Күңелсезләнеп кайтып китәргә генә җыенганда, Шукбай әйтә куйды:

— Соңгы тапкыр каптырып карыйм әле,— диде һәм, кармакка җим саплап, суга ташлады.

Бераздан калкавыч селкенгәндәй итте.

— Чиртә бит, чиртә бит,— дип сикергәләргә тотынды Сармай.— Тартып чыгар инде тизрәк, тартып чыгар кармакны! Качырасың бит балыкны!

— Ашыкма, Шукбай, ашыкма,— диде Майлай.— Мин әйткәч алырсың... Хәзер... Әйдә, тарт!

Тартуын тартты Шукбай, әмма кармак су төбендә өзелеп калган иде.

— Үзем күрдем! — дип бии-бии сөйләргә тотынды Сармай.— Шу-у-ундый зур балык иде. Теге... мин тота язган балык кадәр иде. Әллә шул балык булды микән?! Әйтәм бит, бик көчле, хәйләкәр балык иде ул!

— Балык түгел иде ул, Сармай, шыттырма! Тамыр иде! — диде Майлай.

Шукбай дәшмәде.

## Хат

Шукбай калага китте. Әбисе: «Тагын кайт, бәбкәем!» — дип, яулык чите белән күз яшьләрен сөртеп, елап калды. «Кайтырмын, әбием!»— диде Шукбай. «Калага кайту белән хат язармын!»— дип тә өстәде...

Менә бүген Шукбайдан хат килде. Әбисенә бер кочак сәлам җибәргән. Майлай белән Сармайга да кү-ү-үп итеп сәлам әйтергә кушкан. Чоландагы Чәпчине дә онытмаган. Аңа, хатка салып, кипкән бодай бөртекләре җибәргән.

Майлай белән Сармайны иң сөендергәне — фотокарточкалар булды. Шундый матур төшкәннәр сурәткә. Үзем күрдем. Майлай белән Сармай миңа да бүләк иттеләр ул сурәтне. Артына мәче телендә «Истәлеккә — бездән» дип язылган иде. Менә шул.

# КИКРИКҖАН БЕЛӘН БҮРТӘЙ МАҖАРАЛАРЫ

Бүген-бүген заманда яши иде Кикрикҗан дигән әтәч малае белән Бүртәй исемле үрдәк малае.

Көннәрдән беркөнне ишегалды буйлап сәяхәт кылып йөргәндә Кикрикҗан Бүртәйгә болай диде:

— Бүртәй, беләсеңме, дөньяда кем батыр? Мин батыр! Беләсеңме, кем кыю? Мин кыю!

— Шулай, Кикрикҗан, шулай! — диде үрдәк малае Бүртәй.— Синнән дә батыр, синнән дә кыю бүтән беркем дә юк!

Бүртәй Кикрикҗанның мактанчык икәнен белә иде, ләкин ул: «Кикрикҗан, мактанма инде»,— дияргә базмады. «Әйдә, мактансын. Мактану аңа килешә»,— дип уйлады ул...

Кикрикҗан, ишегалды буйлап байтак вакыт һаваланып йөргәч, үзен күзәтеп торган Бүртәй янына килде дә болай диде:

— Әйдә, Бүртәй, урманга барабыз!

— Ни калган анда безгә? — диде Бүртәй.

Кикрикҗан кукраебрак басты:

— Төлке тотарга барабыз! — диде.

— Төлке үзебезне тотмасмы соң?— диде Бүртәй, курку катыш шикләнеп.

— Мин барында курыкма! — диде Кикрикҗан.— Теләсәм, бүре дә тота алам мин!

Бүртәйгә:

— Син батыр шул, Кикрикҗан...— диюдән башка чара калмады...

Киттеләр болар урманга, киттеләр болар, бара торгач, бер инешкә барып җиттеләр болар. Басма аша аръякка чыкмакчылар иде болар — басма җимерек булып чыкты. Нишләргә?

— Теге якка чыгуның җаен таптым! — диде Кикрикҗан.

— Йә, әйт тизрәк! — диде түземе төкәнгән Бүртәй.

— Башта мин сикереп чыгам, аннан син...

Шулай диде дә Кикрикҗан сикерде. Сикерүен сикерде, ләкин инешнең нәкъ уртасына чупылдап килеп төште.

Кикрикҗан суда чәбәләнә:

— Ки-ке-рик... а-а-а... а-а...

Камыш арасында бакалар хихылдап утыра:

— Ха-ха-ха... хи-хи-хи...

Көмеш балыклар судан очып чыгалар да янә суга чумалар...

Бүртәй кинәт Кикрикҗанның йөзә белмәгәнен исенә төшерде дә, суга кереп, Кикрикҗанга таба ашыга-ашыга йөзеп китте.

Тәмам хәлсезләнгән Кикрикҗанны ничек кирәк алай аркасына утыртты да Бүртәй, аргы ярга таба ашыкты.

Бакаларга кызык: алар һаман хихылдый. Балыклар да судан очып чыгалар да суга чумалар...

Ярга чыгып баскач, Кикрикҗанга хәл керде:

— Җил каршы исмәсә, сикереп чыга идем инде мин! — диде.

Бүртәй, аның сүзен куәтләгәндәй:

— Инеш тә киңәеп киткәндәй булды шул,— диде.

Алар янә киттеләр, бара торгач, урманга да барып җиттеләр.

Кинәт Бүртәй, нәрсәдәндер куркып, баруыннан туктады.

— Анда... алда... Нидер бар! — дип кычкырып җибәрде ул.

Кикрикҗан да куркудан дерт итеп куйды. Әмма куркуын сиздермәскә тырышты.

— Мин барында курыкма, Бү... Бү... Бүртәй! — диде ул.

Ауган агач артыннан энәле туп тәгәрәп чыкты.

Кикрикҗан арткарак чигенде дә:

— Мондый тупны... беренче күрүем...— диде.

— Минем дә...— диде Бүртәй.

Кикрикҗанга кинәт кыюлык иңгәндәй булды.

— Тибеп җибәр шуңа, Бүртәй! Юл өстендә тормасын!

— Син үзең шәп тибәсең бит, Кикрикҗан,— диде Бүртәй.

Кикрикҗан әлеге тупка тибеп тә җибәрде, «Һай, тәпием!»— дип уфылдый да башлады.

Туп дигәннәре кинәт ниндидер җанварга әйләнде.

— Ке... ке... кее... кем син? — диде Кикрикҗан.

— Минме? Мин — керпе малае Энәкәй! — дип чатнатып җавап кайтарды әлеге җанвар.

— Керпе малае Энәкәй?! Без бит сине туп дип уйладык. Гафу ит инде безне, Энәкәй! — диде Бүртәй.

Кикрикҗан авырткан тәпиен нәни канатлары белән сыйпаштырып алды да Энәкәйгә сүз катты:

— Нишләп йөрисең монда, Энәкәй?— диде.

— Урман базарына бара идем. Алма алырга!

— Ә без, Кикрикҗан белән икәү, төлке тотарга барабыз! — дип мактанасы итте Бүртәй.

— Төлке үзегезне тотмагае! — диде керпе малае Энәкәй.— Карагыз аны, сак йөрегез!

— Мин барында курыкмагыз,— диде Кикрикҗан.

Әтәч малае Кикрикҗан белән үрдәк малае Бүртәй, керпе малае Энәкәй белән саубуллаштылар да юлларын дәвам иттерделәр.

Шактый баргач, шактый арыгач, алар бер матур аланга килеп җиттеләр. Шулчак ни күзләре белән күрсеннәр — алан уртасында бер савытка тәмле-тәмле ризыклар өеп куелган.

Кикрикҗан түшен угалап алды да:

— Шәп булды әле бу! Ашыйсы да килгән иде... — диде.

— Минем дә карын ачкан иде,— диде Бүртәй.

Кинәт җир убылгандай булды. Кикрикҗан белән Бүртәй тирән бушлыкка очтылар...

— Бе-бе... Без кайда? — диде Кикрикҗан, исенә килгәч.

— Бе-бе... белмим,— диде Бүртәй.

Югарыдан ниндидер тавыш ишетелде. Бераздан тавыш хуҗасы үзе дә күренде.

— Эләктегезме, тәмлекәйләрем минем? Хи-хи-хи! — диде ул.

— Си... си... син кем?— диде Кикрикҗан, дер-дер калтырап.

Кикрикҗанның әлеге җанварны беренче мәртәбә күрүе иде.

— Минме? Ха-ха-ха... Минме? Хи-хи-хи... Мин Төлке Төләнтәй булырмын!

Кикрикҗан, суыктан туңгандай, бөрешеп, куырылып куйды. Бүртәй аны-моны сиздермәде.

— Син хәзер нишләмәкче буласың инде, Төләнтәй дус?— диде ул, хәйләкәр Төлкенең күзләренә туры карап.

Төлке Төләнтәй эчен тотып көләргә тотынды:

— Төләнтәй дус, диме?! Ха-ха-ха... Сорап торган була тагы! Хи-хи-хи... Уф, үләм!

Бүртәй Кикрикҗанның колагына пышылдады:

— Бер-бер хәйлә уйлап табарга кирәк...

Төлке Төләнтәй көлүеннән туктады да:

— Сине, Кызыл Кикрик, хәзер ашыйм,— диде.

— Башта безне чокырдан чыгар, Төләнтәй,— диде Бүртәй. Аның башына бер хәйлә килгән иде.

— Ә сине, Бакылдык, кичкә кыздырып ашармын!

— Ашасаң ашарсың, Төләнтәй. Тик безне бу чокырдан чыгара гына күр. Юкса без монда тончыгып үләбез...— диде Бүртәй.

Төлке аларга ботаклы озын таяк сузды:

— Менегез әйдә, тәмлекәйләрем! Җәһәтрәк булыгыз!

Кикрикҗан белән Бүртәй, ниһаять, өскә менеп җиттеләр. Төлке Төләнтәй иреннәрен ялмап алды.

— Ашасаң ашарсың инде, Төләнтәй,— диде янә Бүртәй.— Тик безгә, Кикрикҗан белән икебезгә, соңгы тапкыр биеп калырга рөхсәт ит!

— Биеп калыгыз, тәмлекәйләрем. Тик тизрәк булыгыз!

Кикрикҗан белән Бүртәй бер урында талпына-талпына биегәндәй иттеләр. Бүртәй кинәт иелде, аның аркасына Кикрикҗан утырды һәм алар һавага күтәрелделәр...

Төлке исенә килгәндә алар шактый биектә иде инде.

— Ашың тәмле булсын! — дип кычкырды Кикрикҗан.

Арлы-бирле бәргәләнгән Төләнтәй аларга йодрыгын селкеп калды.

— Авылга кайтабыз, Кикрикҗан! — диде Бүртәй.

Кикрикҗан аның тавышын ишеттеме-юкмы, белгән юк, әмма ул Бүртәйгә болай диде:

— Төлкене шәп алдадык, име, Бүртәй?

Бу вакытта алар авылга якынлашып киләләр иде инде.

## ЧЫК, КОШЧЫК ҺӘМ КОЯШЧЫК

Иртән күзләремне ачарга да өлгермәдем, колагыма әбиемнең ягымлы тавышы ишетелде:

— Улым, тор, чык төшкән,— диде ул.— Бар, тышка чык!

Чынлап та чык төшкән икән! Ямь-яшел үлән йөзләрендә, чәчәкләр таҗында җем-җем итеп чык бөртекләре яна. Мин шундый искиткеч гүзәллеккә сокланып торганда, миннән ерак түгел генә җемелдәп янган эре чык тамчысы янына бер кошчык төшеп кунды.

Кошчык әлеге матур чыкны йотарга тели иде бугай. Ул нәни томшыгы белән чыкка таба иелде.

Менә хәзер чыкны йота инде... Чык әрәм була инде, дип уйларга өлгермәдем, кошчык башын күтәрде.

— Әй малай,— дип эндәште ул, минем тарафка борылып.— Кил әле монда. Кояшчык күрсәтәм.

Мин, кошчыкның сөйләшә белүенә хәйран калып, авызымны ачып тора бирдем.

— Кил, кил,— диде кошчык.— Курыкма. Нәниләргә тимим мин.

«Һи, мактанчык,— дидем мин эчемнән генә.— Нәниләргә тимим, имеш. Булса булыр минем йодрык кадәре... Сөйләшүен генә күр!»

Шулай да кошчык янына килдем. Һәм эре генә:

— Күрсәт, әйдә, кояшчыгыңны! — дидем.

— Күрмисең мәллә син?! — дип гаҗәпләнгән булды кошчык.— Менә бит!

Күз карашымны битараф кына әле чыкка, әле чыктагы кояшчыкка төшердем. Һәм шундый матур яктылыкны күреп, телсез-өнсез калдым. Энә очы кадәр генә яктылык! Үзе йөзеп йөри! Төрле төскә керә! Мату-у-ур!

Минем дә, кошчыкның да шатлыгы дөньяга чәчрәп чыкты: кошчык үзләренчә биергә, мин кул чәбәкләргә тотындым...

Күпмедер вакыт узгач, килеп, әлеге чыкка-кояшчыкка карадым һәм... Менә сиңа мә! Кояшчык та, чык та юк иде.

Ул гына да түгел, башка чыклар да эзсез юкка чыкканнар иде.

— Чык менгән! — диде күңелсезләнеп калган кошчык.

— Ничек инде... менгән? Кайчан? Нигә? — дип, үзем дә сизмәстән бер-бер артлы сораулар тездем.

— Менгән инде. Кояш алган. Без күрмичә калдык менә,— диде кошчык.

— Их! — дип көрсенеп куйдым мин.

— Ярый, күңелеңне бик төшермә әле син,— диде бераздан соң кошчык.— Иртәгә иртәрәк чык. Бергәләп кояшчыкка карап сокланырбыз.

Мин, ризалык билгесе итеп, башымны кактым һәм: «Иртәгә чык төшсә ярар иде, иртәгә кояш чыкса ярар иде»,— дия-дия өйгә таба атладым.

## КӘҖӘ УГЫЛЫ КӘҖӘМИ

Борын-борын заманда түгел, безнең-безнең көннәрдә, сезнең-сезнең көннәрдә, минем-синең заманда яшәгән, ди, яшәгән кәҗә угылы Кәҗәми.

Бик матур гына яшәп, гомер итеп яткан көннәрнең берсендә кәҗә угылы Кәҗәми абзар-курадагыларга, ягъни мәсәлән, бәрәннәргә, бозауга әйтеп ташламасынмы:

— Минем сезнең белән яшисем килми. Мин башка җиргә китәм! — дип.

Бәрәннәр дә, бозау да бу хәбәрне ишетеп аптыраган, әлбәттә.

— Син нәрсә, кәҗә угылы Кәҗәми, җүләрләндеңме әллә? — дигәннәр алар кәҗә угылы Кәҗәмигә.— Безнең белән бер абзар-курада яшәмичә кем белән яшисең тагы?

— Бәәлдәмәгез әле, мөгерәмәгез әле! Үзем белермен мин кем белән яшәргә! — дигән дә кәҗә угылы Кәҗәми, абзар-курадан чыгып киткән.

Иң әүвәл ул бакалар янына барган. Барган да, судан башларын чыгарып чурылдашкан бака малайларына әйткән:

— Мин сезнең белән яшим! — дигән.

— Безнеңчә җырлый беләсеңме соң? Әгәр белсәң, яши бир, әйдә,— дип чурылдашкан бака малайлары.

— Беләм, беләм! — дигән кәҗә угылы Кәҗәми.— Мә-кә-кә-кә-кәк! Мә-кә-кә-кә-кәк!..

Бака малайлары эчләрен тотып көләргә тотынганнар:

— Бака-ка-ха-ха-ха... Бака-ки-хи-хи!.. Син безнеңчә җырлый белмисең бит!

Шуннан соң кәҗә угылы Кәҗәми каргалар янына килгән. Килгән дә агач ботагына кунган килеш каркылдашкан карга балаларына болай дигән:

— Мин сезнең белән яшим. Мин каргача җырлый беләм!

— Йәле, йәле, җырлап күрсәт әле безгә! Тыңлап карыйк әле без кәҗә малаеның җырлаганын,— диешкән карга балалары.

— Ми-кә-кә-кәрр!.. Ми-кә-кә-кәрр! — дип көчәнә-көчәнә җырларга тырышкан кәҗә угылы Кәҗәми.

— Кар-рр!.. Кар-рр! Ка-ка-ха-харрр!! — дип каргылдаша-каргылдаша көлешкән карга балалары.— Юк, кәҗә угылы Кәҗәми дус, син безнеңчә җырлый белмисең...

Шуннан соң кәҗә угылы Кәҗәми этләр янына киткән. Бара торгач, килеп җиткән бу болар янына.

— Ни йомыш?— дигән этләр, кәҗә угылы Кәҗәмине күргәч.

— Мин... Мин... Минем сезнең белән яшисем килә... Мин этләр кебек җырлый беләм! — дигән кәҗә угылы Кәҗәми.

— Йәле, җырлап күрсәт әле! — дигән аңа этләр.

— Ми-ки-ки-ки-кәү! Кәү! Ми-ки-ки-ки-кәү-кәү!..— дип, өреп түгел лә инде, җырлап маташкан кәҗә угылы Кәҗәми.

— Һау-һау-һи-һи-һи!.. Һау-һау-һау-һи-һи-һи!..— дип, бот чабып көлгән этләр.— Син безнеңчә җырлый белмисең бит, кәҗә угылы Кәҗәми дус!

Шуннан соң кәҗә угылы Кәҗәми дуңгызлар янына килгән. Килгән дә әйткән:

— Мин сезнең белән яшим! — дигән.— Мин дуңгызча бик шәп җырлый беләм! Тыңлап карагыз әле.

Шулай дигән дә кәҗә угылы Кәҗәми, пычрак күлләвеккә — дуңгызлар чупырдап яткан суга кереп тә утырган.

— Ми-ки-ки-мы-кы-рык!.. Ми-ки-мы-мыр-мыр-ык!— дигән ул.

— Мыррыйк! Мыррыйк! Мыррыйк-хи-хи! — дип көлгән дуңгызлар.— Син безнеңчә җырлый да, безнең шикелле пычракта ауный да белмисең бит. Кит моннан, дуңгыз көлдереп йөрмә!

Шулай дип чинашканнар да дуңгызлар, пычрак күлләвектә рәхәтләнеп пычтырдауларын дәвам иткәннәр.

Кәҗә угылы Кәҗәмигә туган өенә — абзар-курага кайтудан башка чара калмаган.

— Ми-ки-ки-ки... ми-ки-ки-ки... кай-кай-кайттым! — дигән ул абзар-курада тәмләп кенә ризык чемченеп, ял итеп яткан бәрәннәргә, бозауга.— Минем сезнең белән яшисем килә!

Шул көннән бирле ул үзенең әүвәлге дуслары белән гомер итә, ди.

## ЮРИСҮРИЧҮП

Борын-борын заманда яшәгән, ди, бер җан иясе.

Кошларга да, җәнлек-җанварларга да, су хайваннарына да охшамаган булган ул. Җирдә дә йөрмәгән, суда да йөзмәгән, күктә дә очмаган. Елан кебек тә шуышмаган, ятмаган да, тормаган да, утырмаган да — бары тик яшәгән генә.

Аның хәтта исеме дә булмаган.

Шуңа күрә мин аңа үзем исем куштым.

Юрисүричүп дип. Исеме шәп бит, ә?!

Юрисүричүп... Юрисүричүп...

Әгәр берәрегез кайда да булса, кайчан да булса менә шул Юрисүричүпне очратса, миңа әйтерсез әле, яме?

Кызык бит, нindirәк җан иясе икән ул?

## КӨЗГЕ КЫЙПЫЛЧЫГЫ

Һәркемнең матур буласы килә. Хәер, матур буласы килү бер нәрсә, ә менә матур булырга тырышу?! Анысы инде, дускайларым, икенче нәрсә! Көзге яныннан һич китми торган бер кызыйны беләидем мин. Шул кыз көн бизәнә иде, төн бизәнә иде, исемнәрен мин белеп бетермәгән әллә нинди иннек-кершәннәргә, ислемайларга «коена» иде. Өйдә бер эш тә эшләми. Әнисе ух-вах килә. Тегендә чаба, монда йөгерә... Ә бу? Бу — көзге каршында утыра. Бизәнә. Беркөнне көзгедәге сурәтенә бик текәлеп карап утырды-утырды да бу, яшелле-зәңгәрле тавышлар чыгарып җыру сузып җибәрде:

Мин матур, мин чибәр!
Мин гүзәл, мин сылу!
Минем кебекләр бүтән
Бу дөньяда юктыр ул!
Мин чибәр...

Сабыр гына тыңлап торды-торды да Көзге, үз-үзен тыя алмыйча:

— Син бик ямьсез кыз! — дип әйтеп ташлады моңа.

— ...Мин мату-у-ур...

Кызыкай телсез-өнсез калды. Аның булган матурлыгын шул мизгел эчендә яңгыр юып алдымыни!

— Ә син... ә син...— дип нидер әйтмәкче иде кызыкай...

— Мин — Көзге! — диде аңа Көзге тыныч кына.

— Юк, син Көзге түгел, син — җүләр! — дип чәрелдәде кызый һәм, ярсуына чыдый алмыйча, кулына эләккән ислемай шешәсен Көзгегә ыргытты.

— Көзгегә үпкәләмә! — дип кычкырып өлгерде Көзге һәм, вак-вак кыйпылчыкларга таркалып, чылтырап идәнгә коелды...

Мин — менә шул Көзгенең бер Кыйпылчыгы.

## ТАТЛЫ ӘКИЯТ

Быел язын Балмалай белән Малбабай бакчага кәнфит чәчәргә булдылар. Былтыр ике түтәл ясап, берсенә прәнник, икенчесенә печинҗә чәчкәннәр иде алар. Нишләптер, ни прәнник, ни печинҗә уңмады. Башта бик матур булып шытып та чыкканнар иде, югыйсә. Үсүен дә ярыйсы гына үстеләр. Тик менә прәнникләре, печинҗәләре генә әллә ни мактанырлык булмады. Узган җәй коры килгән иде шул. Ширбәтле яңгыр бик тәтемәде үзләренә. Шуңа күрә прәнникләр әчкелтем, печинҗәләр төчкелтем генә булып өлгерде.

Җитмәсә, бик вак иде һәммәсе...

Ә быел кәнфит уңарга тиеш! Елы да бик туры килеп тора, бу ел — Тәмлавыз гороскобы буенча бал елы бит!..

Чыннан да, уңыш Балмалай белән Малбабай уйлаганнан да шәбрәк булды. Алар үсентеләрдәге хуш исле кәнфитләрне җыя-җыя, яфрак урынына үскән шакмаклы, чуар-чуар кәгазьләрне өзә-өзә, чүмәләдәй өелгән шул чыштырдыйк кәгазьләргә кәнфитләрне берәмләп тә, икешәрләп тә төрә-төрә хәлдән тайдылар хәтта.

Эшләре беткәч, тотындылар болар, минсиңайтим, сыйланырга! Чәй тәлинкәсе кадәр булып ачылган авызларына учлап-учлап кына тутырдылар кәнфитне...

Бермәлне, ниһаять, тамаклары туйды боларның.

— Әллә башка малайларга-кызларга да бераз авыз иттерикме? Күп бит әле монда,— диде Балмалай, кәнфит өеменә күрсәтеп.

— Юк, берне дә бирмибез. Әле иртәгә дә, берсекөнгә дә ашыйсыбыз бар! — дип каршы төште аңа Малбабай.

— Алай саран булырга ярамый инде, Малбабай,— диде Балмалай.— Син бирмәсәң бирмә, мин үземә тиешле өлештән бирәм...

— Ярый, бик кыстагач, мин дә бирәм, алайса...

Шуннан соң алар Татлыстандагы һәммә малайга, һәммә кызга кәнфит өләшеп чыктылар.

— Безнең турыда әкият язганың өчен,— дип, миңа да бер кәнфит бирделәр.

Шундый-шундый-шундый-шундый-шундый тәмле иде ул кәнфит!

Тәме әле дә тел очымда тора.

## БАЛЫКЧЫЛАР

Иң батыр, иң матур мәче малае Мыр-Мырга өч яшь тулган көн иде.

Акбай, Шүрәле һәм Кәҗә белән Сарык бергә җыйналыштылар да, Мыр-Мырга ни бүләк итәргә икән дип, бик озак уйлаштылар. Уйлый торгач, бер фикергә килделәр болар: балык тотып кайтырга булдылар. Коеда коенырга уйладылар...

Киттеләр бермәлне тезелешеп: алдан Шүрәле, аның артыннан Акбай бара, алардан калышмаска тырышып, Кәҗә белән Сарык теркелди. Килеп җиттеләр болар бер кое янына, салдылар суга кармакларны. Берәм-берәм балык тоттылар, Акбай кармагына өч маймыч эләкте, Кәҗә бер балык каптырды. Сарык кына нәүмиз калды — ул сыңар балык та эләктерә алмады. Шулай да кәефләре шәп булды үзләренең: Мыр-Мырны сөендерерлек шактый балык тоттылар бит! Тотуын тоттылар, тик Сарык кына аптырашта калды: «Шүрәле, Акбай һәм Кәҗә барлыгы ничә балык тотты соң?»

Әйдәле, дускай, Сарыкка син дә булыш әле.

*(Җавап: Коеда балык тотмыйлар.)*

## ХЫЯЛ

Тәрәзәдән урамга карадым да шаккаттым: агачлар куышлы уйнап йөри! Үзем күрмәсәм, ышанмас идем: Галимә әбинең кәҗәсе, сакалын селкетә-селкетә, прәнник ашый, тәмле су эчә, өстәвенә — сагыз чәйни! Мәзәк дими ни дисең: Сәлим абыйларның Актырнагы белән Марат абыйларның мәчесе Актәпи чөкер-чөкер сөйләшеп тора. Актырнак берәр кызык сүз әйтте бугай, Актәпи башын артка чөеп көлә. Тамаша дисәң дә тамаша: урамдагы эскәмияләр матай-вилсәпидләр кебек чатыр чабып йөриләр! Гаҗәп хәл: болыт малайлары җирдә мәтәлчек ата! Айдар абыйларның ата казы койма башында әтәч кебек кычкыра.

Шулчак әни дәште миңа:

— Улым, хыялланып утырма, дәресләреңне әзерлә,— диде.

— И әни, рәхәтләнеп хыялланырга да ярамый инде,— дидем мин. Һәм, авыр сулап, дәрес әзерләргә керештем.

## КИРЕБЕТКӘН

Мин бер колынны беләм. Кребеткән исемле. Киренең дә киресе инде менә. «Үз киресенә каткан!»— диләр андыйлар турында.

— Бар, дусларың белән болында уйнап кайт! — ди аңа әнисе Гөлбияттәй.

— Фи! Көтү булып йөрергә мин җүләр түгел лә! — дип кенә җиффәрә Киребеткән.

— Бер очтан болында хуш исле, тәмле үләннәр белән сыйланып кайтыр идең,— дип әйтеп тә карый Гөлбияттәй.

— Мин ач түгел әле! — ди Киребеткән.

Башка колыннар шаяра-көлә куышлы уйный. Киребеткән йоклый. Бүтән колыннар күбәләкләр куып йөри. Киребеткән төш күрә. Колыннар су коена. Киребеткән йокыдан уяна.

— Әни! — дип кычкыра ул.— Ашыйсым килә!

Гөлбияттәй эш белән мәшгуль. Ишетми.

— Әни, дип әйтәм! Нәни корсагым ашарга сорый! — ди Киребеткән.

Әнисе ишетә, ниһаять.

— Әнә, табакта солы боткасы бар. Аша шуны,— ди Гөлбияттәй.

— Юк, ашамыйм! Солы боткасы ашарга мин җүләр түгел лә! — ди Киребеткән.

— Алайса, ашама! — ди әнисе.

— Юк, ашыйм! Ашамаска мин җүләр түгел лә! — ди Киребеткән. Шулай ди дә тиз генә табакны ялтыратып куя.

— Әни! Пепси-кола, лимонад, фанта... тагын... газлы су эчәсем килә! — ди Киребеткән.

— Алары нинди су тагы? — дип гаҗәпсенә Гөлбияттәй.

— Фирмир Гапсамат малае шуларны гына эчә! — ди Киребеткән.

— Беренчедән, син фермер малае түгел. Икенчедән, әнә, тагаракта чишмә суы. Эч шуны! — ди Киребеткәнгә әнисе.

— Юк, эчмим! — ди Киребеткән.— Минем уйныйсым килә!

Ул шулай ди дә башка колыннар янына чаба. Ләкин бик тиз әйләнеп кайта.

— Нишләп алар минем белән уйнамыйлар? Нишләп йоклыйлар алар?— ди Киребеткән әнисенә.

— Син киреләнеп йоклаганда алар уйнадылар, хәзер алар киреләнеп йоклыйлардыр инде,— ди Гөлбияттәй.

— Җүләрдер алар,— ди Киребеткән һәм, эченнән генә: «Минем кебек»,— дип уйлап куя.

## ЯҢА ЕЛ ӘКИЯТЕ

Лэйлә белән Бәхтияр Яңа ел бәйрәменә китте. Уенчыклар да аларга иярмәкчеләр иде дә, балалар бертавыштан:

— Уенчыклар белән бәйрәмгә килергә кушмадылар,— диделәр.

Алар китте, уенчыклар нәүмиз булып өйдә калды.

— Дусларым,— диде шулчак Лэйләнең сөекле курчагы Айсылу.— Әйдәгез, Яңа ел бәйрәмен үзебез өйдә уздырабыз!

Уенчыкларның ничек дәррәү сөенгәннәрен күрсәгез иде шул чакта.

Өйдәге бизәлгән чыршы тирәсенә барча уенчыклар җыелды.

Менә бәйрәм башланды.

Кыш бабай булып киенгән Чәнтикойрыйк Куян бүләкләр өләшә, үзен чын-чынлап Кар кызы дип хис иткән Йөнтәс Аю теттереп бии, Айсылуның теле телгә йокмый: әле шигырь сөйли, әле җырлый... Төлке-Төлкисә әтәч булып кычкыра, Сарык битлеге кигән Бүре Бүртәй бәэлдәп йөри, Бәхтиярнең машиналары уенчыкларны алмаш-тилмәш утыртып тыз-быз чаба...

Кыскасы, бәйрәмнең дә бәйрәме иде бу.

Лэйлә белән Бәхтияр Яңа ел бәйрәменнән куанышып кайтып кергәндә, аларның яраткан уенчыклары өйдәге Яңа ел тамашасының дәвамын төшләрендә күрә-күрә мес-мес йоклый иде инде.

## ТЫЧКАННАР ТУЕ

Мин яшәгән өйнең идән астында Чичибанат исемле буй җиткән бик матур, бик сылу тычкан кызы яши. Аның гүзәллеген сүз белән генә сурәтләп булмый. Шундый-шундый сөйкемле инде менә. Җитмәсә, шундый-шундый акыллы, тыйнак үзе.

Беркөнне менә шул Чичибанатның әтисе Чичивәли янына күрше тычканы Чичисамат керде. Чикылдап, чичиләп хәл-әхвәл алышканнан соң, Чичисамат Чичивәлигә болай диде:

— Минем Чичибулат белән синең Чичибанатның кавышу көне килеп җитте, күрше. Туйны бик әйбәтләп, шаулатып уздырырга иде бит инде...

— Уздырырбыз, иншалла,— диде Чичивәли.— Авыл урамын әйләнергә атлар белән чаналар әзердер бит?!

— Менә шуларга эш килеп төртелде бит әле,— диде Чичисамат.— Үзең беләсең, хәзер авылда атлар бармак белән генә санарлык. Аларның барысы да эштә. Нишлибез? Дөрес, минем бер фикер бар барын...

— Йә, йә, нинди фикер ул?— диде Чичивәли.

— Әллә, минәйтәм, Мыргали белән Мырҗанга әйтеп карыйбызмы?

— Безнең мәче белән сезнең мәчегәме?— дип, Чичивәли сорауга каршы сорау бирде.

— Әйе. Аларны чанага җигәбез. Үтенечебезне тәпиләре астына салып таптамаслар әле. Туй бит ул гел булып тормый,— диде Чичисамат.

Чичивәли куркынып кына:

— Мыргали белән Мырҗан безнең барчабызны да тотып ашамасмы соң? — диде.

— Туй көннеме? Син нәрсә, Чичивәли күрше, туйда аларга бездән башка да ризык мул булачак.

— Яхшы. Ә чаналар? Аларны кайдан алабыз?— диде Чичивәли.

— Әнә ич, менә дигән чаналар! — дип, Чичисамат ишек төбендәге ботинкаларга ишарәләде.

— Хуҗаныкы бит ул! — дип әсәренде Чичивәли.— Без алганны белсә, үтерәчәк!

— Курыкма, Чичивәли. Без аны, урам әйләнеп кайтуга ук, урынына кире куячакбыз. Аннан соң синең хуҗаны да, минем хуҗаны да туй мәҗлесенә чакырабыз ич без!

— Шулай дисәң генә...— дип килеште Чичивәли.

— Ә хәзер, әйдә, башта Мыргалидән ризалыгын сорыйк,— диде Чичисамат.

Шуннан соң ике тычкан — Чичивәли белән Чичисамат — урындыкта мес-мес йоклап яткан Мыргали янына килде. Чичисамат аның койрык очыннан җиңелчә генә тартты:

— Мыргали күрше! Мыргали күрше, дим!

Мыргали башта уң күзен, аннары сул күзен иренеп кенә ачты.

— Кемнәр чыелдый анда? Ни бар?— диде ул йокылы тавыш белән.

— Мы... мы... ыргали ту... ту... туган,— диде Чичивәли,— ми... ми... минем кызым Чичибанат белән Чичисаматның улы Чичибулатның бүген туй көне. Си... си... син булышмассың микән безгә?!

— Ничек итеп?— диде Мыргали, күзләрен уа-уа.

— Безнең атыбыз юк. Син ат булсаң иде. Без сиңа чана җигәр идек. Син безнең асылҗаннарыбызны урам әйләндерсәң иде,— диде Чичисамат.

— Туй көнне сезнең белән әвәрә килеп, матавыкланып йөрү миндәй затлы мәчегә килешеп бетми бетүен... Ярый инде, балаларыгыз хакына ризалашмый булмас,— диде Мыргали. Шуннан соң ул:

— Чанагыз бармы соң?— дип сорады.

— Бар, бар, әнә, ишек төбендә,— дип, Чичивәли ботинкаларга төртеп күрсәтте.

— Ярый, алайса, сез дигәндә — мин идәндә,— диде дә Мыргали, идәнгә сикереп төште...

Шулай итеп, тычканнар Мыргалине ботинкага җиктеләр. Мыргали җиккән ботинкага — Чичибанат белән Чичибулат, ә Мырҗан ботинкасына кода-кодагыйлар, кардәш-ырулар җайлап утырдылар да урам әйләнергә киттеләр...

Тычканнарның туй мәҗлесе җиде көн, сигез төн барды. Ризык-нигъмәт мул иде: каткан сырдан алып, кипкән бәлеш төбенә кадәр бар иде.

Туйларында мин дә булдым, кимермәгән ризык, чөмермәгән су калмады — туйдан соң бер атна иреннәрне ялмадым.

## БОРЧАК ШЫТТЫРАМ

Бервакыт, бүген кичке иртәдә, барлы-юклы киемнәремне чишенеп киендем дә, искитмәслек гаҗәп төшләр күрә-күрә, киттем Борчакшыттырам иленә. Барам шулай, барам... Өй эче галәмәт суык — маңгайдан шабыр тир ага, керфек очларыннан бозлар тама. Туңмас өчен күлмәк сәдәпләрен ычкындырып җибәрдем дә юрганны ныграк бөркәндем. Барам шулай, барам... Үзем бик матур итеп гырлыйм, бик яман итеп җырлыйм. Аяк астында кар, авызда тешләр шыгырдый. Үзем барам, үзем юрганга ныграк төренәм. Борын белән куык кабартып очырам да тирә-юньне күзем белән кәртечкәгә төшерәм. Җил сызгыра, кояш кыздыра, ә мин тузан туздырам. Биткә кар сылана, бөтен өс-баш чыланганнан-чылана. Бияләйнең суын сыгып кигән идем — аякларым туңа башлады. Ярый әле, ике кат тишек оекбаш кигән идем. Киез каталар да кигән булсам, катып үләргә дә күп калмый иде. Тамак тук булуга карамастан, ашыйсы килә башлады. Юрганның төпсез кесәләрен кармалый торгач, чикләвек хәтле борчак таптым. Тотындым шуннан соң борчак шыттырырга. Әй шыттырам борчак, әй шыттырам... Шыттырам да шытымын сиңа тоттырам, шыттырам да шытымын сиңа тоттырам...

Уянып китсәм, син — бар, мин — юк. Син әйткәч кенә белдем, мин һаман Борчакшыттырам илендә борчак шыттырам икән. Шыттырам да шытымын сиңа тоттырам икән...

## ШУРУЛЛА БЕЛӘН ШҮРВӘЛИ

Шурулла белән Шүрвәли — шүрәле малайлары. Игезәкләр. Бер-берсенә шулкадәр охшаганнар — берсен икенчесеннән һич аерып булмый. Икесе дә тиктормас, икесе дә шукшаян.

Шурулла — җырларга, ә Шүрвәли биергә бик ярата.

Игезәк сыңары Шурулла, ачыргаланып, яшелле-зәңгәрле тавышлар чыгарып:

Абага чәчәк атканда,
Их, ямьле май айлары!
Яфрак ыштан киеп йөри
Карурман малайлары-ы-ы... —

дип җырлый башлауга, карурманда мәхшәр куба. Аю малае Лаплап колак тишекләренә учлап-учлап тузганак мамыгы тутырырга тотына. Куян кызы Янсылу, тиз генә берәр агач куышы табып, шунда кереп поса. Ваемсыз гына гөмбә җыеп йөргән керпе малае Чәнчәли, җәһәт кенә бөгәрләнеп, сукмак буйлап ерак-еракка тәгәрәп китә. Төлке малае Хәйлүшкә кунакка килгән этәч малае Кикринур, куркуыннан, читәннән егылып төшә, ә Хәйлүш үзе исә, кая кереп качарга белмичә, әрле-бирле чабулап йөри...

Шүрвәли, дуамалланып-ихахайлап:

Тыпыр-тыпыр биегәндә
Ут чыга табанымнан,
Ике казан ботка состым,
Аш үтми тамагымнан...—

дип такмаклый-такмаклый биегәндә җирләр селкенә, агачлар калтырана, ботаклар шартлап коела, аяк астыннан чыккан тузаннар, болыт-болыт булып, күккә күтәрелә...

Карурманда яшәгәнгәдер инде, Шурулла да, Шүрвәли дә алдаша белмиләр. Кая ул алдашу! Аның нәрсә икәнен дә чамаламыйлар...

— Беркөнне бер черки күрдем,— дип алдашмаган була Шурулла.— Чынлап әйтсәм — ышанмассың... Карга чаклы бар иде! Тәпиләре имән кебек юан, канатлары ябалдаштай киң иде!..

— Булыр, булыр. Мин дә беркөнне бер чебен күргән идем. Ярты казан ботканы «әһ» тә итмичә ашап бетерде. Ул ашаганга минем эч әле дә авыртып тора,— дип, Шурулланың сүзен куәтли Шүрвәли...

Әйтәм бит, һич алдаша белмиләр.

«Малайлар — мактанчык халык!»— дигән булалар... Юк, боларда мактануның эзе дә юк.

— Мин кытыкласам, шәп кытыклыйм! — ди Шурулла.

— Ә мин синнән дә шәп кытыклыйм! — ди Шүрвәли, тыйнак кына.

— Мин көрәшсәм, бөтен батырны да җиңәм! — ди Шурулла.

— Ә мин бөтен батырны җиңә алган батырны төртеп егалам! — ди Шүрвәли һәм, көтмәгәндә, Шурулланы төртеп ега да:

— Әйттем бит! — дип әйтеп куя.

— Мин көнгерәдән дә шәп йөгерәм! — ди Шурулла.

— Ә мин синнән дә шәп чабам! — ди Шүрвәли.

— Әйдә, ярышабыз! — ди Шурулла.

— Әйдә! — ди Шүрвәли.

Шуннан болар җан-фәрман чабып киттеләр. Кай тарафка киттеләр — белмим.

Кемнәндер ишеттем: Шурулла белән Шүрвәли туктый алмыйча әле дә булса чабып йөриләр икән.

## БОРЧАК БОТКАСЫ

Беркөнне Шүрәле төпсез капчыктан бер борчак табып алды. Табып алды да ботка пешерергә булды. Табылдык борчак шулхәтле кечкенә иде — урталай ярылган казанга көчкә сыйды. Дөрес, әле бер өлеше сыймый да калды. Анысын Шүрәле, башка вакытта пешерермен әле, дип, уймак хәтле савытка салып куйды.

Сусыз-майсыз ботка буламыни инде, шуңа күрә борчак өстенә өч чиләк су койды Шүрәле. Ак майга урын калмаганлыктан, ул казанга бер зур кисәк туңмай гына эретеп салды.

Бер көн дигәндә, борчак боткасы быгыр-быгыр килә башлады, бер төн дигәндә — пешеп тә чыкты.

«Үзем генә ашасам — җитмәс, кунак чакырсам — бетмәс»,— дип уйлап, Шүрәле ботка ашарга кунаклар чакырды.

Иң әүвәл, чәнти бармак чаклы бал калагын алып, Аю килде. Аннан соң чәнечке чаклы сәнәк тотып Бүре күренде. Бүредән соң үзе кадәр кашык тотып Төлке пәйда булды. Табынга Куян да соңармады — ул дәү чүмеч алып килгән иде.

Менә болар казан тирәли утырыштылар.

Араларында иң өлкәне саналган Аю калак очына гына элеп ботка алган иде — казан бушап калды. Шуннан соң тотындылар болар дәррәү ботка сосарга, тотындылар сосарга...

Бүре, мышкылдый-мышкылдый, урталай ярык казанның бер читен кыра, икенче чите тирәсендә Төлке кайнаша. Ярыкта кысылып калган ботканы, алан-йолан карана-карана, Куян ялмаштыра. Ялмаштыра да төкереген йотып куя, ялмаштыра да төкереген йотып куя...

Ә Шүрәле? Шүрәле нишли?

Ул да тик тормый — ботка исен исни.

Исни дә:

— Их, тәмле дә соң борчак боткасы! — ди.

Шулай ди дә янә исни...

Ул ботканың исен мин дә иснәдем. Әле дә борын очын кытыклап тора.

## КОЕ ҺӘМ БОРЫН

Тәрәзәдән карап торам шулай. Җәмил абый үзләренең бакчасында кое казып маташа. Көрәк белән. Иллә дә җиңел казый инде! Мин дә, эш юкта эш булсын, дип, борынымны казырга тотындым. Имән бармаклар белән. Әле уң кулныкы, әле сулныкы белән. Алмаш-тилмәш. Борын казу — әйбәт гадәт түгел дә түгелен. Ләкин нишлисең — казыйсы килә бит!

Шулай борын тишеген казып азапланганда, бармакка кульъяулык ияреп чыкмасынмы бермәлне! Аптырап киттем башта. Шуннан янә тотындым казынырга. Бу юлысында сөлге тартып чыгардым. Шуннан соң и китте, и китте... Бармаклар алмаш-тилмәш җитез хәрәкәтләнә. Борын тишекләреннән әйберләр бер-бер артлы чыга тора: күлмәк сәдәбе, авторучка, борчак, суыра торган кәнфит, алма төше, сыңар йон бияләй... Бал калагын азаплана-азаплана тартып чыгаруга — уянып киттем. Тәрәзә тупсасына таянып йоклаганмын икән...

Мин уянганда Җәмил абый коега бура төшереп маташа иде инде.

## ЯЗГЫ ӘКИЯТ

Яз иде. Күк йөзендә алсу алма кебек кояш елмайган гүзәл бер көн иде.

Айсылу сеңлесе Ләйләгә:

— Ләйлә, әйдә, урманга чәчәкләр җыярга барабыз,—диде.— Әниебезгә бүләк итәрбез!

Ләйлә шундук риза булды. Алар янында мәче белән маэмай бөтерелә иде.

— Мин дә сезнең белән барыйм әле,— диде мәче.

— Минем дә барасым килә,— диде маэмай.

— Әйдәгез, киттек! — диделәр кызлар.

Бәрәңге бакчасы аша киттеләр болар. Алдан, койрыгын болгый-болгый, маэмай бара, аның артыннан мәче элдерә, алардан калышмаска тырышып, кызлар кызу-кызу атлыйлар. Юлда боларга бер матур тычкан очрады.

— Мине дә ияртегез әле,— диде тычкан.

Ияртteләр, янә киттеләр. Ниһаять, бәрәңге бакчасы артына килеп җиттеләр.

Бакча артында бер зур агач үсә. Аны иң элек тычкан күреп алды. Аннары бүтәннәр дә күрделәр.

— Нинди матур урман! — диде мәче әлеге агач тирәли әйләнә-әйләнә.

— Искиткеч! — дип сокланды маэмай.— Мондый урманда минем беренче мәртәбә булуым әле.

— Чәчәкләр күптер инде монда! — диде Ләйлә, җирдән чәчәк эзли-эзли.

— Кочакка сыйган кадәр күтәрәбез,— диде Айсылу. Һәммәсе агач тирәсеннән чәчәк эзләргә кереште. Әмма ни Айсылу, ни Ләйлә, ни маэмай, ни мәче, ни тычкан бер генә чәчәк тә тапмады.

Шулвакыт агач башыннан бер кош тавышы ишетелде.

— Бер агачлык урман була димени! — диде әлеге кош.— Беләсегез килсә, безнең авыл тирәсендә бернинди урман да юк! Әрәмәлек бар-барын да, ул да ерак! Сезнең әллә берегезнең дә урман күргәне юк идеме моңарчы?

— Юк шул. Без әле кечкенәләр бит. Миңа өч кенә яшь,— диде Айсылу.

— Миңа ике яшь тула,— диде Ләйлә.

— Миңа бер яшь инде,— диде маэмай.

— Миңа да,— диде мәче.

— Мин үземә ничә яшь икәнен белмим. Санарга өйрәнмәдем әле,— дип чикылдады тычкан.

— Аңлашылды,— дип каркылдап алды кош.— Ярый, алайса, мин Җил дустыма әйтим әле, ул хәзер сезгә чәчәк бәйләме китерер.

Кош шулай диюгә, Айсылуның да, Ләйләнең дә кочагында чәчәк бәйләме пәйда булды. Җил маэмай белән мәчене дә, хәтта тычканны да онытмаган. Миңа да бер бөртек чәчәк бирде әле.

## САРЫ ӘКИЯТ

*(Имант Зиедонистан)*

Йомырка сарысын хәтерләткән кояш күк гөмбәзенә эленеп тора. Кояшның сары нурлары буйлап җиргә таба чебиләр төшеп килә. Әлбәттә, ул чебиләрнең һәммәсе дә сап-сары.

Бер сары корт шул чебиләрнең берсе янына очып килде дә умартасына кунакка чакырды.

Сары чеби, күпме генә тырышса да, умарта эченә уза алмады, чөнки умартага керү тишеге бик кечкенә иде шул. «Ярар,— дип уйлады ул.— Әнә, сары күбәләкләр оча, мин дә шулар белән очам хәзер».

Чеби шатлыгыннан сикергәләп алды һәм шулчак үзенең канатлары юклыгын исенә төшерде. «Менә тавык булып җитим әле,— дип хыялга бирелде чеби,— ул чакта мин бик биектә генә очачакмын!»

Ә кояш һаман балкый да балкый. Чит-читләре кетердәп торган сары коймак инде менә! Сары кортлар да очалар да очалар, тузганактан тузганакка куналар. Әнә сары умарталарына

кайттылар. Сары умарталар зур китапханәләргә охшаган иде. Кәрәзләре сары бал белән тулган рамнар китап киштәләрен хәтерләтә. Кәрәз чокырлары, гүя алты почмаклы телевизорлар, тик экран урынына сары бал гына ялтырый.

Сары чәчәкләрдән, тузганаклардан гына торган сары болын офыкка тоташкан. Кояш калкулыклардагы тузганаклар өстенә сибелгән сыман тоела.

Мин тузганак өзеп алдым. Каяндыр җил килеп чыкты һәм мине тузганакка коендырды.

Шулчак минем янга сыер килде. Сап-сары тузганак дип уйлады ул мине, ахрысы, капты да йотты. Күшәп тә тормады. Менә шуңа күрә әкиятне дәвам итәргә бүтән мөмкинлегем юк.

# КЕЧТЕКИ ӘКИЯТЛӘР

## КАНАТЛЫ СЫЕР

Ни өчен сыерның канаты юк? Бу сорауга җавапны син үзең дә таба аласың. Кулларыңа ике каз канаты ал да урам уртасына — кеше күп җыелган җиргә чыгып бас. Шуннан соң кошлар шикелле талпынгандай ит. Бер урында бөтеренгәләп йөреп кара, әйләнгәләп, йөгеренгәләп кил. Кешеләр сиңа гаҗәпсенеп тә, кызганып та карарлар: «И-и мескен, җүләрләнгән икән бу бала!» — диярләр.

Шуны ишеткәннән соң, тояклары арасына каз канатлары кыстырган сыерны үз урыныңа куеп кара: «И-и мескен, җүләрләнгән икән бу сыер...»— диярләр.

Менә бит хикмәт нидә!

## УКЫМЫШЛЫ САРЫК

Ни өчен сарык укый-яза белми? Чөнки аңа укырга да, язарга да ярамый. Әгәр ул укый-яза белсә, ул чагында кешеләр наданнарга, мокытларга: «Һәй, син, аңгыра сарык!» — дия алмаслар иде. Менә бит хикмәт нидә!

## КУРКАК КҮРКӘ

Ни өчен күркә самолёттан курка? Беренчедән, ул аны гигант күркә дип белә. Икенчедән, оча торган күркә икәнен үзе үк күреп тора. Өченчедән, менә шул оча торган гигант күркә, кинәт мәтәлеп, үз өстенә төшмәгәе дип шөбһәләнә. Өстәвенә, ул аның тимер икәнлеген дә кемнәндер ишеткән...

Менә бит хикмәт нидә!

## САГЫЗ ЧӘЙНӘҮЧЕ КӘҖӘ

Ни өчен кәҗә сагыз чәйнәми? Чөнки аның акчасы юк. Әгәр акчасы булса, юлында очраган һәр киоскка тукталып, һәр кибеткә кереп, ул теләсә нинди сагызны, әйтик, «Стиморол», шикәрле-шикәрсез «Дирол», «Бомбимбом» ише букый-сукыйны сатып алып, шуларны өзлексез чәйни-чәйни ашау-эчүдән бөтенләй язар иде. Ул чагында Гайшә әби кәҗәнең шифалы сөтен дә эчә алмас иде, кәҗә мамыгыннан җылы шәл дә бәйли алмас иде. Менә бит хикмәт нидә!

## ТАВЫК САНДУГАЧМЫ?

Ни өчен тавык сандугач кебек сайрый белми? Әгәр ул сайрый белсә, җырчылар болай дип җырлар иде: «Тавыкла-а-ар капкада, канатлары тактада, бәгырькәем, мин онытмам, син оныткан чакта да...» Яки болай дип моңаерлар иде: «Тавык керде күңелгә, җырламый түзиммени?» Яисә болайрак өзгәләнерләр иде: «Син — тавык, мин — каен...»

Менә бит хикмәт нидә!

## КАНАТЛЫ БОЛЫТЛАР

Ни өчен ак болытлар канат җилпеп очмый? Чөнки алар явыз аучылардан куркалар. Әгәр алар канатларын җилпи-җилпи очсалар, әлеге явыз аучылар аларны, дәү аккошлар дип уйлап, атып төшерүләре ихтимал. Кемнең инде күрәләтә ядрә эләктереп һәлак буласы килсен?..

Менә бит хикмәт нидә!

## ТАШЛАР АХМАК ТҮГЕЛ

Ни өчен тау ташлары астан өскә таба тәгәрәми? Моның сәбәбен белү бик җиңел. Син әүвәл артың белән алга таба йөгереп кара. Аннан соң, ашыйсың бик килгәч, өстәл янына артың белән утыр. Аягың белән кашык тот та аш аша. Икенче аягыңның бер бармагы белән борын тишегеңдә казынып алсаң да ярый. Уңаймы? Рәхәтме? Түгелдер шул. Ташларга да өскә таба тәгәрәү рәхәт түгел. Һәм аларның алай тәгәриселәре килми дә...

Менә бит хикмәт нидә!

## ЭСКӘМИЯ — МАТАЙ

Ни өчен капка төбендәге эскәмияләр урамда матайлар кебек тыр-пыр чабып йөрмиләр? Беренчедән, эскәмияләрнең моторы юк, икенчедән, бензин сала торган савытлары юк, өченчедән, төтен чыккыч торбалары юк, дүртенчедән... Әле эскәмия чын матай булсын өчен, руль белән тәгәрмәчләр дә кирәк бугай...

Утыргыч белән генә алай тыр-пыр, шатыр-пытыр чабып булмый шу-у-ул...

Менә бит хикмәт нидә!

## АКБАЙ МЕНГӘН ЧИТӘНГӘ

Ни өчен әтәч эт булып өрми, ә эт әтәч булып кычкырмый?

Әгәр әтәч эт булып өрә белсә, аны шундук эт оясы янына бәйләп куячаклар һәм аңа йортны, каралты-кураны сакларга кушачаклар. Ә инде эт «кикрикүк» дип кычкыра белсә, ул читәнгә яисә койма башына менәргә тиеш була түгелме соң? Ләкин минем үз гомеремдә читәнгә менгән этне күргәнем юк! Ә синең?

Менә бит хикмәт нидә!

## АШАМСАК КАЗ

Ни өчен каз кашык тота белми? Әгәр тота белсә: «Мин тары боткасы яратмыйм!» — дип, синең кебек киреләнеп, үҗәтләнеп маташмас иде, кашыклап кына сосар иде.

Менә бит хикмәт нидә!

## ШАГЫЙРЬ БҮРЕ

Ни өчен бүреләр арасында шагыйрьләр юк? Дөрес, алар да шигырь-мигырь язалар язуын. Мәсәлән, бер Бүре Бүретдин язган шигырь мондый:

Куяннарым, куяннар
Кишер ашап туйганнар.
Мин дә кишер ашармын,
Рәхәтләнеп яшәрмен...

Дөресен әйткәндә, бу — ялган, ясалма шигырь. Чөнки бүреләр кишер ашамый. Димәк, сине, мине ышандырмый торган шигырьләр язып кына шагыйрь булып булмый.

Менә бит хикмәт нидә!

## БАЛЫКЛАР ДА УКЫЙ

Ни өчен балыклар мәктәпкә укырга бармыйлар? Кем әйтте әле бармыйлар дип? Баралар, укыйлар. Чөнки су астында да мәктәп бар. Аларга үз мәктәпләрендә «Су асты географиясе», «Балыкчы кешеме?», «Кармактан саклану чаралары» дигән дәресләр керә. Тик шуны әйтергә кирәк: балыкларның кайбер шуклары, ялкаулары, тәртипсезләре дә дәресләргә йөрми һәм шул сәбәпле балыкчыларның кармакларына килеп каба да... Димәк, укырга кирәк. Укысаң, кармакка эләкмисең!

Менә бит хикмәт нидә!

## СӘГАТЬ КҮКЕСЕ

Ни өчен күкеле сәгатьнең күкесе очмый? Туктале, ничек инде очмый? Кычкыра белә бит. Кычкыра икән, димәк оча да! «Очканын күргән юк»,— дисеңме.

Күргәнең юк, әлбәттә. Ул бит кешеләр йоклаган вакытта гына оча. Мин, мәсәлән, үзем йоклаган чакта күкенең очканын гел күрәм. Дөрес, безнең өйдә күкеле сәгать юк-югын... Шулай да... оча бит!

Менә бит хикмәт нидә!

# МӘЗӘКИЯТЛӘР

## КИПКӘН БАЛЫК... АЧЛЫК ИГЪЛАН ИТӘ

Биш Борчак мәктәбендә, укучыларның һәммәсен таң калдырырлык, моңарчы күз күрмәгән, колак ишетмәгән сәер вакыйга булды: Мөрәдис ачлык игълан итте!

Бер коридорлы мәктәпнең төрле классларында алты Мөрәдис укый, әмма бу хәбәрне ишеткән укучыларның берсе дә яңалыкны ирештерүчедән:

— Кайсы Мөрәдис? — дип сорамады.

Чөнки җитмеш дүрт еллык тарихы булган агач мәктәптә мондый эшне бары тик бер генә Мөрәдис, ул да булса Кипкән Балык кушаматлы Мөрәдис кенә эшләргә мөмкин. Балык тәңкәсе кебек чәпелдәп ябышкан әлеге кушамат Мөрәдискә ике төрле сәбәп аркасында сыланды. Беренче сәбәп — Мөрәдис кипкән балыкны үлепләр ярата. Икенчесе — кыяфәте белән ул үзе дә тач кипкән балыкны хәтерләтә.

Ябык Мөрәдис кабарынган күркәгә охшаган тәмлетамакларга караганда да гаять ашамсак һәм эчемсәк иде. Аның баллы-тозлы, әчкелтем-төчкелтем ризыкларны һәм эчемлекләрне бер үк вакытта ашап-эчүен күргән укучылар:

— Ачлык игълан иткән итүен, тик менә абыйсы Дөлфәт тотып киптергән балыкны ашамыйча ничек түзәр микән ул?

— Бал-май ягылган ипи белән шәлперәйгән тозлы кыярсыз нишләр микән?

— Шомырт бөккәне белән тары ярмасы боткасын ашамыйча, ачыган катык белән ширбәтле су эчмичә нишләргә уйлый икән? — диеп баш ваттылар.

Коридорда чыш-пыш дәвам итте.

— Ә ни өчен ачлык игълан иткән соң Мөрәдис? — диде кайсыдыр.

— Дәрес вакытында да ашарга рөхсәт алмакчы,— диде Мөрәдиснең партадашы Нияз.

— Кайчанга кадәр ач тормакчы микән? — диде кемдер.

Шулчак әллә каян гына Мөрәдис үзе пәйда булды. Ул бәрәңге өчпочмагы тоткан кулы белән җәһәт кенә борын астын ышкып алды да:

— Ә мин ач торуны туктаттым инде,— диде. Бәрәңге өчпочмагы тотмаган кулындагы әче яшел борычны чыртлатып капты һәм, аны тәмләп чәйни-чәйни:

— Ләкин көрәшне туктатмаска исәп! — дип тә өстәде.

Ул арада, озын тәнәфес беткәнен белдереп, кыңгырау чылтырады.

## КЫХМЫРЫЙ, МЫХМЫРЫЙ ҺӘМ ШЫХМЫРЫЙ

Мөрәдис бик сүзчән малай. Биргән соравын беркайчан да җавапсыз калдырмас. Белмәсә дә сөйләр. Күзен дә йоммас. «Сүз эзләп кесәгә кермәс»,— диләр андыйлар турында. Дөрестер...

Әле бүген генә Мөрәдистән:

— Кыхмырый нәрсә ул? — дип сорадым. Юри, әлбәттә. Кая ул аптырау! Керфеге дә селкенмәде. Чатнатып сөйли дә башлады.

— Кыхмырый ул, дускай, бик тәмле ризык,— ди.— Төньяк ярымшарның көньяккарак урнашкан өлешендә кеше ерып чыгалмаслык джунгли бар. Менә шул джунглида чимбия дигән бер кабилә яши. Халкы бик тырыш. Гадел. Галимнәр исәпләп чыгарганнар: ике йөз утыз кеше яши икән бу кабиләдә. Менә шул кабилә халкы көз җитәр-җитмәстән үк

кыхмырый дигән агачның җимешләрен җыеп ала. Җыеп ала да шикәрсез генә вәринҗә кайната. Тәме... Кыхмырыйдан җир җиләге белән балан һәм шомырт кушылган тәм килә. Шул вәринҗәне ашап караган кешеләрнең күбесе телен йота язган. Борын-борыннан килгән гадәт буенча кабилә халкы вәринҗәне ипигә ягып ашый...

— Соң бит, Мөрәдис,— дим мин,— кыхмырый — ул ашый торган нәрсә түгел...

Мөрәдис минем сүзне әллә ишетте, әллә ишетмәде. Сөйләвен дәвам иттерде:

— Алар ипинең өске ягына түгел, киресенчә, аскы ягына ягып ашарга яраталар...

— Соң бит, Мөрәдис...

— Дөрес әйтәсең,— диде Мөрәдис.— Кыхмырый исемле икенче нәрсә дә бар. Ул велосипед белән көймәгә охшаган бер техника шунда. Экваторның сигезенче параллелендә яшәүче җирле халык көзге урып-җыю чорында аны ат урынына бик теләп файдалана...

— Соң бит, Мөрәдис, кыхмырый агач та, велосипедка охшаган көймә дә түгел! — дип кычкырдым мин, тәмам ярсып.— Мин уйлап чыгарган сүз генә бит ул... Син ни шыттырырсың микән дигән идем...

— Дөрес әйтәсең, кыхмырыйдан тыш, мыхмырый дигән аппарат та бар,— диде Мөрәдис тыныч кына.— Ул, син әйткәнчә, борчак шыттыру җайланмасы. Аны көнчыгышның көньяк-көнбатышында яшәүчеләр...

«Каян килде бу минем башыма «кыхмырый» дигән сүз?» — дип тиргәдем үз-үземне. Ләкин тиргәүдән ни файда соң?

...Аңыма килгәндә, Мөрәдис, мыхмырый турында сөйләп бетереп, мыхмырый белән шыхмырыйның оча торган тәлинкәләргә бәйләнеше турында сөйли башлаган иде...

## ЗАМАНА БАЛАЛАРЫ

Балалар бакчасында өч малай бер-берсе белән танышты.

— Минем исемем Марат,— диде сипкелле борынлысы һәм, джинсы чалбары кесәсеннән уң кулын иренеп кенә чыгарды да, яңа танышларының кулларына дустанә сугып алды.

— Айрат мин,— диде сары чәчле малай.

— Ә мин — Булат,— диде өченче малай.

Ул да сагыз чәйни иде.

— Минем әти — бизнесмен! — диде Сипкелле малай, беравык тын торганнан соң.

— Ә минеке — кооператор! — диде Сары чәчле малай.

Өченче малай бу юлы бер сүз дә дәшмәде.

— Пепсидән, кока-коладан, бананнан өзелгән юк,— диде Сипкелле малай. Ул сүзләрен раслагандай кикереп куйды.

— Ә мин унбиш минут саен яңа сагыз чәйним,— диде Сары чәчле малай һәм, авызында әвәләгән сагызын җиргә төкерде дә, кесәсеннән яңасын алды.

Өченче малай бу юлы да дәшмәде.

— Син нигә дәшмисең? — диде Сипкелле малай, аңа сәерсенеп карап.— Әтиең гегемон мәллә?

Өченче малай чит илнеке икәнлеге әллә каян ук күренеп торган курткасы кесәсеннән рогатка суырып алды:

— Минем әти — рэкетчы! Чыгарыгыз сагызларыгызны! — дип кычкырды.

Сипкелле малай белән Сары чәчле малай каушый-каушый гына кесәләреннән сагызларын кармалаштыргалаган вакытта әллә каян гына бер малай пәйда булды.

— Ә минем әти милиционер! Ташла рогаткаңны! — диде ул өченче малайга.

Шулвакыт тәрбияче апаларының:

— Малайлар! Йокы сәгате җитте. Әйдәгез, йокы бүлмәсенә...— дигән тавышы ишетелде.

— Ә бусы минем әни була инде! — диде «рэкетчы» малай. Шуннан соң ул малайларның һәммәсенә горур караш ташлап алды да:

— Сагызларыгызны миңа бирерсез. Йоклаганда чәйнәргә ярамый! — диде.

## ШӨГЫЛЬ

Бишенче класс укучысы Самат Кәримуллин бик башлы малай. Күптән түгел генә ул үзенә кызыклы шөгыль тапты. «Айны Җиргә сөйрәп төшерү өчен ничә трактор кирәк булыр иде?» — дип сорады ул әтисеннән. Әтисе шул мизгел эчендә үк тирләп чыккан борынын сөрткәләде, пеләшләнә башлаган башын кашып алды һәм... Саматны алмагач төбе йомшатырга чыгарып җибәрде. Самат алмагач төбен йомшарткан вакытта исәпләп чыгарды: Айны Җиргә сөйрәп төшерү өчен туксан җиде миллион сиксән өч мең җиде йөз алтмыш өч «ДТ-75» тракторы, ике йөз егерме бер «беттем-беттем» тракторы, алты йөз дә...

Хәзер Саматны икенче сорау борчый: «Күк йөзендәге барлык йолдызларны җыеп тутыру өчен ничә арыш капчыгы, ничә полиэтилен капчык, ничә сумка кирәк икән?»

## СИН — СУПЕРБАЛА?!

Син өйдә. Мәктәптән ачыгып кайткансың, билгеле,— әниең яисә әбиең әзерләгән тәмле, татлы ризыкларны «ә» дигәнче ялт иттереп куйдың.

Хәзер инде сиңа, диванга ятып, хыялга бирелеп, ял итеп алсаң да ярый...

...Әйе, кинолардагы супергеройлар шикелле, син — супербала (супермалай яки суперкыз) ди.

Әгәр теләсәң, әлләниләр, әллә нәрсәләр эшли аласың...

Теләсәң, кибеткә барып, ипи-сөт алып кайта аласың.

Чишмәдән «ә» дигәнче су алып кайта аласың — теләсәң.

Әгәр теләсәң, ишегалдындагы көртне ялт иттереп көрәп куя аласың.

Утын кисә аласың, яруны әйткән дә юк!

Шәрран ярып җылап яткан энеңне, йә сеңлеңне юата аласың — әгәр теләсәң.

Буш вакытыңда маҗаралы-маҗарасыз китаплар укый аласың, бер тәпие былтыр ук какшаган урындыкны төзәтә аласың, идәнне себерә-юа аласың...

Тагын әллә нәрсәләр, әллә ниләр эшли аласың...

Әгәр теләсәң... Теләмисең генә.

Әллә телисең дә, эшлисең дәме?!

## КИРЕ УЙЛАДЫ

Рекс Сәгадәтшин озынлыкка сикерү буенча дөнья рекорды куярга уйлады. Ләкин ул шунда ук бу уеннан кире кайтты. «Чөнки,— диде ул классташларына,— минем әле тагын җиде ел укыйсым бар. Әгәр мин озынлыкка сикерү буенча дөнья рекорды куйсам, мине гел чит илләрдәге ярышларга йөртә башлаячаклар. Шулай булгач, укуга вакытым калмый да калмый инде. Шуңа күрә мин дөнья рекорды куймаска булдым. Минем уем: ничек тә мәктәпне ерып чыгу һәм берәр җирдә су сиптерүче һөнәренә укып кайту!»

## ТРАНЗИСТОР ҮЧ АЛА

— Беләсең килсә, минем транзисторым бар! — диде Хатип һәм баш бармагын тырпайтты.— Во! Бернинди бәтәрәй дә кирәкми. Чәтелдәтеп сөйли!

— Алдыйсыңдыр әле,— диде Сәет.

— Юк, эпекәем менә! Әгәр печтек кенә ялганласам, Сәләхетдин абзыйларның теге сөзгәк сыеры, мөгезенә элеп, ә-ә-нәү тыкрык башына хәтле алып бәрсен!

— Әтиең апкайттымыни? — дип сорады Сәет.

— Юк.

— Абыең?

— Юк. Үзем ясадым,— диде Хатип.— Бүген төне буе шуны тыңлап яттым...

— Кайчан? — диде Сәет, гаҗәпсенеп.

— Бүген... әй лә, ялгыш әйттем, кичә! Шуны тыңлап ята-ята башым катып бетте инде. Дәрес хәзерләүләр дә онытылды, малай.

— Синең бит... Син бит... физиканы дә әйле-шәйле генә беләсең. Ничек итеп... уйлап таптың ул транзисторны? — дип сорады Сәет, әле һаман да ышанып җитмичә.

— Һай, аның нәрсәсен уйлап торасың,— диде Хатип.— Тотасың да ясыйсың. Баш та кирәкми. Физика да.

— Ә-ә... кая соң транзисторың? Өйдә калдырдыңмыни?

— Юк, монда. Кесәдә. Чалбар кесәсендә.

— Кесәдә? — Сәет тагын да гаҗәпләнә төште.

«Шыттыра бу Хатип, борчак сибә»,— дип уйлады ул. Шулай да аны-моны сиздермәскә тырышты:

— Кесәгә сыямыни?

— Әһә! — диде Хатип, канәгать елмаеп.— Кесәгә сыя!

— Күрсәт соң, алайса.

Хатип чалбар кесәсеннән... шырпы кабы тартып чыгарды.

— Менә ул!

— Бумы? Шушымы? Шушы сөйлиме? — Сәетнең гаҗәпләнүе чиктән ашты.

— Әһә,— диде Хатип.— Сөйли! Чәтелдәтеп!

— Синең әкиятеңә ышанган мин җүләр,— диде Сәет, үпкәләп. Һәм борылып китмәкче булды.— Дус, имеш...

— Сөйли бит ул, сөйли! — дип кычкырды Хатип.— Тик безнеңчә генә түгел. Менә тыңла!

Хатип шырпы кабын Сәетнең уң колагына якын китерде.

— Ишетәсеңме, сиптерә генә, ә?

— Юк, ишетмим,— диде Сәет.— Сөйләми бу.

— Ничек инде, сөйләми?!

Хатип транзисторын үз колагына куеп тыңлый башлады.

— Сөйләргә тиеш! Бүген иртән генә сөйли иде. Сөйләргә тиеш! — дип кабатлады ул. Шырпы кабын әле бер колагына, әле икенчесенә китереп терәде.

— Ватылгандыр,— диде Сәет, канәгать елмаеп.

— Юк, ватылырга тиеш түгел! Түгел! Иртән генә сөйли иде,— дип мыгырданды Хатип.

Ул шырпы кабын сак кына ачты. Тартмачыкта хәлсез бал корты ята иде.

— Ба... ба... бал корты? — диде Сәет, гаҗәпләнүдән тотлыга-тотлыга.— Ү-ү-ү... л-лә бит инде бу хәзер!

— Һи, исең киткән икән. Үлсә, икенчесен тотам мин аның. Айн момент! — диде Хатип.

Шулвакыт алар абайламый да калдылар. Бал корты, соңгы көчен туплап, нәни канатларын җилпеде дә, безелди-безелди, Хатипның маңгаена, төгәлрәк итеп әйткәндә, ике каш арасына килеп кунды.

— Сөйли...— дияргә генә өлгерде Хатип.

Бераздан аның маңгаенда «кузы чикләвеге» пәйда булды.

## АЛСУ АЛМА

Баһадир, бакчага кереп, алмагачтагы бердәнбер алманы үрелеп алды да тәмләп ашый башлады...

— Тәмле! Искиткеч! — диде ул, башын чайкый-чайкый.

Аның ашаганын карап торган энесе Фәндәвис: «Абый кебек үскәч, мин дә үрелеп кенә алма алырмын әле!» — дип уйлады һәм төкереген йотып куйды.

— Тәмле булды бу! — диде Баһадир һәм алма чүбен алмагач төбенә ыргытты.

«Алманы үрелеп алгач, абый белән икәү әнә шулай тәмле итеп ашар идек»,— дип уйлады Баһадирның энесе Фәндәвис һәм әле алмагачка, әле алма чүбенә карап алды.

— Тәмле булды бу алма! — диде янә Баһадир һәм, күлмәген өскәрәк күтәреп, эченә суккалады...

Алма чыннан да тәмле иде.

## ДӨГЕ БОТКАСЫ

Бик ачыккан иде шул Баһадир: дөгенеке дип тормады, бер савыт ботканы ялт иттереп куйды.

— Менә үскән минем улым! — дип мактады аны әнисе.— Әллә тагын ашыйсыңмы?

Бик ачыккан иде шул Баһадир: дөгенеке дип тормады, янә бер савыт ботканы ялт иттерде.

— Минем абый зур шу-у-ул! — дип уйлады Баһадирның энесе Фәндәвис һәм алдындагы ботканы авырсынып кына ашый башлады...

Баһадирның энесе Фәндәвиснең тамагы тук иде шул.

## БӘРӘҢГЕТОР

...Хезмәт дәресе. Кечкенә каютбүлмәдә, җитди кыяфәт чыгарып, Эдуард утыра. Аның алдындагы ялтыравык өстәлдә телевизор сыманрак бер нәрсә. Стабилизаторны хәтерләткән берничә тартмачыкта төрле төстәге утлар җемелди. Кая гына күз салма, анда — кнопка-пробка, шөреп-мөреп ише әйберләр...

Укытучы тавышы:

— Эдуард, син әзерме?

Эдуард, җәһәт кенә тегене-моны боргалаштыргалап, имән бармагы белән тегендә-монда баскалап алды да җавап кайтарды:

— Мин әзер, Галимә Галләмовна!

Укытучы тавышы:

— Укучылар, Эдуард та әзерләнеп бетте. Бәрәңге ала башлыйбыз. Бер... ике... өч!

Эдуард каршындагы әлеге телевизор сыман нәмәрсәдә бәрәңге басуы пәйда булды. Экранның уң ягыннан «пылт» итеп кечкенә «беттем-беттем» тракторына охшаган арбалы машина калкып чыкты да алга таба элдертте... Ул да булмады, арбага бернинди кантарсыз, балчыксыз, чип-чиста бәрәңгеләр коела башлады...

«Бигрәкләр дә кызык инде бу дөнья,— дип уйлады Эдуард, күзләрен экраннан алмыйча,— әле кайчан гына укучылар трактор артыннан сибелеп-күмелеп калган бәрәңгене чиләккә кул белән җыйганнар. Ул месkenнәр, тракторлар бик еш ватылып-нителеп ятканда, бәрәңгене көрәк йә сәнәк белән казыганнар. Ә хәзер? Хәзер рәхәт. Хәзер шундый күңелле бәрәңге алулары! Басуга барасы юк, төбенә балчык ябышкан чиләкне сөйрәп йөрисе юк, кулны туфракка батырып бәрәңге эзлисе юк. Каютбүлмәгә керәсең дә, бер-ике төймәгә

төрткәлисең — и вәссәлам! Каз йомыркалары кебек ап-ак бәрәңгеләр арбага явып кына тора!»

Эдуард, үзе дә сизмәстән, бер-ике төймәгә төрткәләп алды. Ялгыш төртүен аңлап алганда соң иде инде: экрандагы трактор туктап калган иде...

Укытучы тавышы:

— Эдуард! Нәрсә булды анда синең бәрәңгеторыңа?

Шактый азаплангач кына, Эдуард тавыш бирде:

— Бер предохранитель янган, Галимә Галләмовна. Шуны алыштырдым.

Укытучы тавышы:

— Кара аны, Эдуард, бәрәңгеторыңны тагын бер туктатсаң, билгеңне төшерәм. Йә икенче хезмәт дәресенә кертмим.

Эдуард, пышылдап кына диярлек:

— Гафу итегез инде, Галимә Галләмовна. Норманы йөз егерме процентка үтәргә сүз бирәм,— диде.

Укытучы тавышы:

— Яхшы, Эдуард. Эшләвеңне дәвам ит. Игътибарлы бул!

...Ул арада ике арба бәрәңге белән шыплап тулды. Эдуардның бәрәңгеторы өченче арбаны такты да бәрәңге алуын дәвам итте...

Кинәт кают-бүлмәнең түшәменнән тамчылар тама башлады. «Өске катта су кранын ачып калдырганнар»,— дигән уй йөгереп узды малайның башыннан. «Аппаратны харап итә бит инде бу». Эдуард урыныннан торды да аппаратны гәүдәсе белән каплады.

— Галимә Галләмовна! Галимә Галләмовна! — дип кычкырды ул.— Кают-бүлмәгә су үтә!..

Шул мизгелдә ул үз тавышына үзе уянып китте һәм бәрәңге чүпләре катыш юеш салам өстендә буш чиләген кочаклап ятканын шәйләде. Каршында Галимә Галләмовна басып тора иде.

— Эдуард, бер-бер хәл булдымы әллә? — диде укытучы.— Сине эзли-эзли җаннарыбыз чыкты. Авыргансыңдыр да, безгә әйтмичә генә, өеңә кайтып киткәнсеңдер, дип уйладык. Иптәшләрең синең кишәрлекне дә чүпләп бетерделәр. Әйдә, яңгыр астында торма, ышыккарак барыйк...

Бу вакытта яңгыр, тагын да көчәя төшеп, ишеп ява иде.

## ЙӨЗ ПРОЦЕНТ

Вәсим, тәрәзәгә караган килеш, авторучка башын чәйнәштерә-чәйнәштерә, бик озак уйланды. Ниһаять, төпле бер фикергә килеп, алдындагы шакмаклы дәфтәр битенә яза башлады:

«Хат башы — яз каршы!

Исәннәрмесез, кадерле редакциядәге кадерле апалар һәм абыйлар! Мин сезнең гәзитнең һәр санын, әле бүген килеп җитмәгәнен дә бик яратып, йөз процент укып барам. Безнең класстагы һәркем, минем шикелле, шулай итә. Чөнки алар да яраткан гәзитебезне бик яраталар. Быел, подписка башлану белән, без бердәм рәвештә, яраткан гәзитебезгә йөз процент язылдык. Шушы хәбәр тиз көндә гәзитнең дүртенче битендә басылып чыгар дип өмет итәм һәм сездән истәлекле бүләкләр һәм мактау кәгазе көтеп калам...»

Вәсим язуыннан туктады да янә беравык уйланып алды. Шуннан соң ул хатын шундый сүзләр белән дәвам иттерде:

«Яраткан гәзитебезгә язылмыйча калучылар бик сирәк. Аларның сәбәпләре бар. Барысыныкы да ышандырырлык. Фәридә Сафинаның әти-әнисе кунакта икән. Шулар кайткач

кына язылам, ди Фәридә Сафина. Ул сүзендә тора торган кыз. Мин аңа йөз процент ышанам. Марсель Вәлиевнең бу арада нишләптер кәефе юк әле. Кәефем әйбәтләнгәч, әбизәтельне язылачакмын, ди. Ул сүзендә торырдай малай. Моңа да йөз процент ышанырга була. Калганнар белән сөйләштем. Рәис Харрасов, Рәйфә Сабирҗанова һәм тагын Айдар Садыйков кебек тагын биш-алты классташым киләсе атнаның чәршәмбесендә, йә дүшәмбесендә язылачакбыз, диделәр...»

Вәсим янә уйланып алды.

«Сүземне йомгаклап тагын шуны әйтәсе килә, кадерле редакциядәге кадерле апалар һәм абыйлар, сезгә йөз процент вәгъдә бирәм: үзем берсекөнгә һичбер икеләнүсез язылам яраткан гәзитемә.

Минем язар сүзем бетте. Подпискага алдан язылып бетүебез турында хәбәр иткәнем өчен сездән истәлекле бүләкләр һәм мактау кәгазе көтеп калам. Классташларымның күзе шар булсын әле.

Сагынычлы кайнар сәлам белән:

Вәсим Хәкимҗанов, алдынгы укучы».

## ИКЕ ЧИЛӘК СУ

Сәрияне тимурчылар командиры итеп сайладылар. И сөенде дә инде Сәрия, и сөенде! Классташлары күрмәгәндә генә шатлыгыннан кулларын чәбәкләп тә алды. Сөенмәслекмени?! Командир хәтле командир булып кара әле син! Югыйсә отряд сборы саен Әкълимә белән Фәридәне генә мактыйлар:

— Икесе дә ярдәмчел. Бик яхшы укыйлар. Менә кемнәрдән үрнәк алырга кирәк! — диләр.

Моннан соң Сәрия телегездән дә төшмәс әле. Менә күрерсез!

Сәрия, эре-эре атлап, такта янына чыгып басты да, йөзенә эшлекле кыяфәт чыгарып, ярдәмчеләренә фәрман бирде:

— Тимергали! Бүген син Җәмил бабайларның утыннарын ярырсың!

— Ә син, Хәләф, Госман бабайларның ишегалдын себерерсең, мин үзебезнең урамдагы ялгыз әбиләргә су китерәм...

Сәрия, эшне хәл ителгәнгә санап, үз урынына барып утырды да, сумкасыннан өр-яңа дәфтәр алып, кызыл фломастер белән түбәндәге сүзләрне язып куйды:

1. Майбәдәр әби — ике чиләк су. (Имза.)

2. Хөббениса әби — ике чиләк су. (Имза.)

...Сәрия өйгә уктай атылып кайтып керде. Ишектән керә-керешкә үк:

— Әни! Безнең чиләк-көянтә бармы? — дип сөрән салды.

Әнисенең йөзләренә елмаю җәелде.

— Бар, кызым, бар. Ник булмасын! — диде ул кабалана-кабалана.— Менә чиләкләр, менә көянтә. Ә-ә... Нигә кирәк булды әле ул сиңа, кызым?

— Аңлатып торырга вакыт юк, әни. Суга барам...

Сәрияне ай күрде, кояш алды.

Әнисенең:

— Капкалап алыр идең, кызым,— дигән сүзләрен ишетмәде ул...

Озак та үтмәде, Сәриянең бөтен ишегалдын яңгыратып кычкырганы ишетелде:

— Майбәдәр әби! Майбәдәр әби, дим, су апкайттым сиңа!

Майбәдәр әби абына-сөртенә болдырга чыгып басты.

— Уф, йөрәгем! Ут чыккан мәллә дип торам, син икәнсең әле, Сәрия кызым. Су дисеңме?

— Әйе, Майбәдәр әби, сиңа су китердем. Су кирәкме?

— И-и-и кызым, кул-аякларың сызлаусыз булсын инде. Суым җитәрлек ие шул. Әле генә чишмәдән үзем алып кайткан идем. Әйдә, кызым, чәй эчәргә кер.

— Юк, Майбәдәр әби, кереп тормыйм. Ашыгам! — диде Сәрия һәм пәлтә кесәсеннән яшел тышлы яңа дәфтәрен тартып чыгарды.— Менә монда, «имза» дигәннең алдына кулыңны гына куй да, мин китәм...

— Хөббениса әби!

— Әү, кызым.

— Су кирәкме? Су китергән идем.

— И рәхмәт яугыры, менә әле генә Сәбәх кызы белән Харис кызы китереп киткәннәр иде шул.

«Әкълимә белән Фәридә эше»,— дип уйлап алды Сәрия.

Әби сүзен дәвам итте:

— Куяр урыным юк шул, бәбкәем. Бөтен чиләкләрем, ләгәннәрем тулы су.

— Алайса...— диде Сәрия.— ...менә монда кулыңны куй да, Хөббениса әби...

— Сәбәх кызы белән Харис кызы кул куйдырып тормаган иде торуын, нигә кирәк булды соң әле ул, бәбкәем? — дип сөйләнә-сөйләнә Хөббениса әби Сәрия кулындагы авторучкага үрелде...

Хупҗамал әби белән Гайнекамал әбигә кул куйдырып чыкканда, Сәриянең җеп өзәрлек тә хәле калмаган иде. Суы яртылаш кына калган чиләкләрен өстерәп, өйгә уфылдап кайтып керде ул. Каршысына йөгереп килгән әнисенә:

— Әни, безгә су кирәкме? — дип пышылдады.

— Кирәк, кызым, кирәкмәгән кая! — диде әнисе, каушап.

Һәм кызының иңсәсеннән көянтәне алды да:

— Үзем генә барасым калган аны, кызым,— диде.— Күр инде, бөтенләй төсең качкан.

Сәриягә бераздан соң гына хәл керде. Теле ачылды:

— Әни, менә монда кулыңны куй,— диде ул һәм, бөгәрләнеп, юешләнеп беткән яшел тышлы дәфтәрен әнисенә сузды...

## ИНША

Әдәбият укытучысы Тәнзилә апа «Үскәч кем булырга телисең?» дигән темага инша язып килергә кушты. Өйгә кайткач, иң беренче эш итеп шуңа тотынды Рәфинә. Бик озак уйланды. Чыннан да, кем булырга икән үскәч?

— Кызым,— дип эндәште шулчак әнисе.— Ипи беткән икән, тиз генә кибеткә барып киләлмәссеңме?

— Дәрес хәзерлим! — дип кычкырды Рәфинә һәм ак кәгазьгә беренче җөмләне язып куйды: «Үскәч мин икмәк пешерүче булам».

Тагын нәрсә язарга? Рәфинә беравык уйга калды.

— Апа, апа,— диде энесе Илшат.— Рәфинә апа, шакмакларны тезеп кенә күрсәт әле...

— Комачаулама! — диде Рәфинә һәм «Тәрбияче булудан да әйбәт һөнәр юктыр дөньяда!» — дип язды.

— Кызым,— диде әтисе.— Телевизорны гына кабызчы. Концерт башлана хәзер...

— Үзең кабыз. Минем эшем бар,— диде Рәфинә һәм «Атаклы җырчы булгач, матур күлмәкләр генә киячәкмен»,— дип язып куйды.

— Кызым, Тәнзилә апаңны гәҗиткә мактап язганнар,— диде бабасы.— Бик әйбәт укытучы дигәннәр...

Рәфинә бабасы әйткәннәрне ишетмәмешкә салынды. Кәгазьгә «Укытучы — мактаулы эш. Минем укучыларым сүз тыңлаучан һәм тәртипле булырлар...» дигән сүзләр тезелде.

...Төштә Рәфинәнең иншасына укытучы Тәнзилә апа дә-ә-әү «5»ле билгесе куйды.

## ОЧТЫ, ОЧТЫ КАРГАЛАР...

Рәис күңелендә бер ай чамасы йөрткән серен Морат белән уртаклашырга булды.

Иң элек ул Моратка сорау арты сорау яудырды:

— Тиздән сыйныф җыелышы булачакмы? — диде ул.

— Булачак,— диде Морат ваемсыз гына.

— Булгач, анда кемнәрдер очачакмы?

— Очачак, әлбәттә,— диде Морат.— Шуңа да сайлау җыелышы бит ул!

— Очканнар урынына кемнәрнедер сайлап куячаклармы?

— Куячаклар, әлбәттә,— диде Морат.— Шуңа да җыелыш бит ул!

— Алайса, бел: очачаклар арасына мин дә, син дә эләгергә мөмкин,— диде Рәис.— Син, физорг буларак, үзең дә селкенмәдең, башкаларны да селкетмәдең. Ягъни мәсәлән, бер эш тә эшләмәдең. Мин дә, стена газетасы редакторы була торып, сыңар гәҗит тә чыгармадым. Вакыт та булмады инде...

— Нишләптер аңлап җиткермим әле мин сине, Рәис,— диде Морат.— Нәрсә әйтергә телисең соң син?

— Сөйләп бетергәнне көт,— диде Рәис сабыр гына.— Әгәр дә син физорглыктан, мин редакторлыктан очсак, кызлар алдында дәрәҗә төшә безнең. Аңладыңмы инде?

— Менә хәзер аңлашыла башлады,— диде Морат.

— Тыңлый белсәң, аңлашыла инде ул,— диде Рәис һәм черт итеп җиргә төкерде.— Безгә хәзер Мирхәйдәр тирәсендәрәк йөрергә кирәк. Ничек тә аның белән дуслашу ягын карыйк. Ни әйтсәң дә, ул бит староста! Җыелышта безне яклап бер-ике сүз әйтсә, безгә җил-яңгыр тимәскә мөмкин.

— Без болай итик,— диде Рәис.— Җыелышка хәтле ару гына йөрик. Дәресләргә соңга калмыйк. Тәртип бозмыйк. Үзебезне яхшы яктан гына күрсәтик...

Шуннан соң Рәис Моратның колагына нидер пышылдады...

Икенче көнне Морат Мирхәйдәр янына килде дә, кулындагы китабын сузып:

— Мирхәйдәр, мин сиңа Чеховның «Хамелеон»ын бүләк итәм,— диде.

— Нишләп әле тик торганда китап бүләк итәсең? — дип сорады Мирхәйдәр.

— Ни бит... Мин... Ни... дусларга китап җәл түгел,— дип сөйләнде Морат.— Аннан соң мин аны бит... Ни... язып бирәм...

Язучыларның кешеләргә китапларны язып бирүләре турында ишетеп белә иде ул. Шуңа күрә тиз генә китапны ачты да, эре-эре хәрефләр белән: «Иң якын дустым Мирхәйдәргә иң якын дустың Мораттан»,— дип язды һәм, елмаеп, китапны Мирхәйдәргә бирде.

— Рәхмәт,— диде Мирхәйдәр.

Бераздан Мирхәйдәр янына Рәис килде.

— Мин сиңа «Очты, очты каргалар...» дигән китап бүләк итәм,— диде ул.

— Нишләп әле бөтенегез дә миңа китап бүләк итәргә уйладыгыз? — диде гаҗәпләнеп калган Мирхәйдәр.

— Соң... Мирхәйдәр, унҗиде көннән синең туган көнең бит! — диде Рәис.— Башкалар өлгергәнче бүләк итә торыйм дигән идем. Туган көнең җиткәч, тагын берәр китап бүләк итәрмен әле...

— Рәхмәт, рәхмәт,— диде Мирхәйдәр, кыенсынып кына.

«Эшләр җайга салынды»,— дип пышылдады Рәис Морат янына утыргач.

— Эһ-һе! — диде тегесе һәм баш бармагын тырпайтты.

...Менә түземсезләнеп көткән җыелыш көне килеп җитте. Укытучы Роза апа янына эре-эре атлап Мирхәйдәр чыгып басты.

«Без монда. Безне күрәсезме?» — дигәнне белдереп, Рәис белән Морат Мирхәйдәрнең авызына төбәлделәр.

Сайлаулар башланды.

— Әгәр сез каршы килмәсәгез, физорг Морат белән стена газетасы редакторы Рәис турында бер-ике сүз әйтер идем,— диде Мирхәйдәр.

— Без каршы түгел. Сөйлә! — диде Гафият, барысы өчен дә җавап биреп.

Рәис Моратка елмаюлы караш ташлады. Тегесе авызын ерды.

— Рәис белән Морат әйбәт кенә малайлар,— диде Мирхәйдәр.— Соңгы вакытта тәртипләрен дә яхшырттылар. Тик...

Рәис белән Морат дерт итеп куйдылар.

— Тик...— диде Мирхәйдәр.— Миңа калса, аларны физорглыктан һәм редакторлыктан азат итү әйбәтрәк булыр шикелле.

— Алар урынына кемне тәкъдим итәсең? Сөйлә! — дип кычкырды Гафият.

— Морат урынына Зиннурны, ә Рәис урынына...

Бу вакытта Моратның күз аллары караңгыланды, ә Рәис, үзе дә сизмәстән:

— «Очты, очты каргалар...» — дип пышылдый иде.

## КАМИЛНЕҢ КӨЛӘСЕ КИЛӘ

Камилнең көләсе килә башлады. Тик көләргә сәбәп кенә юк. Болай гына көлсәң, җүләр диярләр...

— Карале, Ринат,— дип эндәште ул, мыш-мыш килеп, җәйге күренешне рәсемгә төшереп азапланган дустына.— Көлдер әле мине. Көләсем килә!

— Вакыт юк! — диде тегесе.— Күрмисеңмени, рәсем ясыйм бит!

— Көлдер инде-е-е,— дип ялынды Камил.— Үзең көләсең килгән вакытта мин дә көлдерермен...

— Әйттем бит инде — вакыт юк! — диде Ринат төксе генә.

— Алайса... алайса...— Камил өстәл өстендә яткан авторучканы кулына алды.— Алайса... Менә моны бармакларың арасына кыстырып сындыра аласыңмы?

Ринат, бәйләндең инде дигәндәй, Камилгә күзләрен акайтып карады да:

— Бир. Сындырам. Бүтән комачаулама,— диде һәм тешләрен чытырдатып кысты да «эһ» дигәнче ручканы шартлатып сындырды.

Шуны гына көтеп торган Камил, эчен тотып, рәхәтләнеп көләргә тотынды:

— Ха-ха-ха... Уф... үләм... Хи-хи-хи...

— Нигә көләсең? — диде Ринат.— Үзеңнең ручкаң сынды бит! Минеке дип белдең мәллә?

— Ә?!

Камилнең көләсе килми башлады...

## ПОПУГАЙ

Озын тәнәфес иде.

Классның физоргы Нияз мәктәптә «шагыйрь» дип даны таралган Хәнәфинең почык борынына күз төшереп алды да:

— Әйдә, Хәнәфи, берәр шигырь сөйләп җиффәр әле,— диде.

— Әйе... Әйдә берәр шигырь сөйләп җиппәр әле, малай,— диде Гафият тә, Ниязның сүзләрен җөпләп.

— Алай бик ялынгач, сөйләмичә дә булмас,— диде мәктәпнең танылган шагыйре Хәнәфи һәм түш кесәсеннән таушалып беткән блокнотын тартып чыгарды да төрле якка сибелгән пырдымсыз чәчләрен тагын да туздыра төште.

— Әйе... Без бик ялынгач, сөйләмичә дә булмас,— диде Гафият.— Сиптер әйдә!

Хәнәфи очкынланган күзләрен тәрәзә пыяласында бәргәләнгән чебенгә текәде дә өч көн элек язган шигырен сөйли башлады:

Абый кайтты армиядән,
Эшләпәсе башында.
Мин дә шигырь язам әле
Алтын көз айларында...

— Йә, ничек? — диде ул.— Шәпме?

— Әйе... Ничек? Шәпме? — диде Гафият тә, карашын әле Ниязга, әле озын буйлы Айратка күчерә-күчерә.

— Шә-ә-әп булган бу! — диде Айрат, соклануын яшерә алмыйча.

Гафият тә үз фикерен әйтергә ашыкты:

— Әйе, булган бу, малай!

Хәнәфинең баш түбәсе классның түшәменә тигәндәй булды. Почык борыны әкрен генә өскә күтәрелә башлады. Хәнәфи, тагын бер-ике җылы сүз өмет итеп, Гафияткә төбәлгән иде, шулвакыт Нияз сүзгә кушылды:

— Барып чыкмаган әле бу, Хәнәфи дус! Чиле-пешле урыннары бар — төзәтергә кирәк.

Гафият тә түзмәде:

— Әйе... Чиле-пешле урыннары бар — төзәтергә кирәк, Хәнәфи дус! — диде.

Хәнәфи танымаслык булып үзгәрде. Почык борыны җыерылып килде.

— Син... син... попугай син! — дип кычкырды ул Гафияткә, еларга җитешеп.

— Әйе... Попугай син! — диде Гафият тә, күкрәген киереп.

— Нәрсә? Минме? — дип җикеренде Хәнәфи.

— Әйе... Нәрсә? Минме? — дип чыелдады Гафият.

— Син шул, син, син! — диде ярсыган Хәнәфи, каз йомыркасы кадәр булып йомарланган йодрыгын Гафиятнең борын төбендә уйнаткалап.— Беләсең килсә, сине мәктәпнең җанлы почмагына куярга кирәк...

Әтәчләнү ни белән беткән булыр иде — әйтүе кыен, әмма нәкъ шул вакыт класска бер минут та алдашмыйча тора алмаган Алдар Сәлим килеп керде.

— Малайлар,— диде ул, еш-еш сулап,— әле яңа гына ишеттем. Кибеттә попугай саталар икән. Теп-тере попугай. Койрыгы менә мондый! Күзләрен әйткән дә юк! Теттереп сөйләшә. Мин үзем хәзер сатып алам. Сезгә дә кирәкме? Ничәү кирәк? Кирәк булса, әйдәгез бу дәрескә кереп тормыйбыз. Попугай алырга барабыз. Кемнәр минем белән бара, әйдәгез!..

Шулай диде дә Алдар Сәлим, юкка да чыкты.

Нишләргә белмичә басып торган Гафияткә җан керде. Хәнәфигә карап, йодрыкларын төйнәде дә... ишеккә ташланды. Аның:

— Кемнәр минем белән бара, әйдәгез! По... по... пугай алырга барабыз! — дигән сүзләре генә ишетелеп калды.

## КАБАК БӘЛЕШЕ

Кабак бәлеше кабак бәлеше инде! Телеңне йотарлык. Авызыңны чапылдата-чапылдата, майга буялган бармакларыңны берәм-берәм ялаштыргалап ашыйсың. Бүтәннәр сиңа кызыгып карап тора, ә син аларга бөтенләй игътибар итмәгән булып, авызга капканыңны тәмләп кенә чәйни бирәсең. Чәйнисең, чәйнисең...

Шулчак берсе, түзмичә, төкереген йота-йота:

— Алмаз, әз генә сындырып бир әле,— дип сорый. Ә син бәлешнең соңгы кисәген авызыңа дыңгычлап тутырасың да көч-хәл белән генә:

— Биг бигег игем гә, бегге гул! — дисең.

Әйе, кабак бәлеше тәмле инде ул тәмлесен... Их, кичә Сәмига апаның кабагын бакчасыннан күтәрешеп кайткан булсам! Туйганчы сыйланган булыр идем бүген...

— Алмаз, Яңа елга багышлап стена газетасы чыгарабыз. Синнән — мәкалә! — диде стена газетасы редакторы Вәсим.— Аңладыңмы, Алмаз?

— Ярар, язармын,— диде Алмаз һәм янә татлы уйларга бирелде...

Кабак бәлешенә җитми инде! Тәмләп... Их, әгәр кабак сабагының чәнечкесе бармакка кадалмаган булса кичә... Җиргә куйганны сизми дә калдым шул,— йөгердем генә өйгә! Кабак бәле... Туктале, нинди мәкалә язарга икән соң? Тәнәфес вакытында мәктәп ишегалдындагы бозлавыкта шуучылар турында быел гына өч мәртәбә яздым инде. Әллә балыкчылар турында языйм микән? Алар турында бер генә мәртәбә...

Алмаз тегеннән-моннан кисеп алып ябыштырылган мәкаләләр дәфтәрен ачты. Әһә, менә ул мәкалә: «Боз өстендә — балык» дип атала. Бераз төзәткәләргә дә... Әйе, кабак бәлеше ашыйсы кеше идем бит мин бүген... Язасы мәкаләгә исемне ни дип куярга икән? Э-э-эм! «Тәңкәләр җемелди бозда» дип куйсам әгәр? Шәп!.. Кабак бәлеше шәп инде ул!

Алмаз мәкалә язарга кереште: «Балык судан очып чыкты да боз өстенә чәпелдәп төште. Ак каз канаты шикелле ул ак балыкны безнең класста укучы Кәшбиев Илсурның энесе Вилсур белән бер класста укучы Фәндәвис Гайнетдинов каптырды. Мин классташым Илсурның энесе Вилсурның шундый әйбәт дусты булуына чиксез горурланам...»

Бүген кабак бәлешен тәмләп ашый язган кеше була торып, интегеп, тәмләп... мәкалә язып утыр инде...

## ПИРАМИДА

Геометрия дәресе тәмамланып килә иде. Укытучы Һәвәскәр абый:

— Укучылар, калган вакыт эчендә үткән дәресне кабатлап алыйк әле. Йә, нинди тема узган идек? — дип карашын мәгарә тынлыгы урнашкан класска төбәде.

Кыенсынып кына берничә кул югары күтәрелде. Чыш-пыш китте. «Кем кул күтәрә, шуннан сорамый!» — Мәсәлимнең башыннан шундый уй йөгереп узды. Һәм ул, укытучының күзләренә керердәй булып, кулын күтәрде.

«Кул күтәргәннәрдән сорамый...»

Мәсәлим шулай дип уйлап та өлгермәде, Һәвәскәр абыйның тавышы яңгырады:

— Сәмигуллин! Йә, син әйтеп кара.

Класс җиңел сулыш алган вакытта, Мәсәлим өнсез калды: «Беттем!»

— Сәмигуллин! Сине көтәбез, хөрмәтлем! — диде укытучы.

Мәсәлим, сигезгә бөгелеп, урыныннан күтәрелә башлады:

— Үткән дәрестә без... без... без үттек... үткәнне үттек без... дәрестә...

Мәсәлимнең янәшәсендә утырган Зиннур күзләрен елтыратып:

— Урра! Миннән сорамады! Миннән сорамады! — дип пышылдады.

Ни дип җавап бирергә дә белми торган Мәсәлимнең колагына «сорамады» сүзе «пирамида» булып ишетелде.

— Ә... әйе... үткән дәрестә без пирамида турында үттек. Пирамида дип... пирамидага охшаган... пирамидага әйтәләр...

— Менә шушы фигуралар арасыннан безгә пирамиданы табып та күрсәт инде, алайса,— диде Һәвәскәр абый, өстәлгә таба ишарәләп.

Бик озак эзләнә торгач, Мәсәлим кыяр-кыймас кына бер фигураны кулына алды да Һәвәскәр абыйга сузды.

— Менә шушы...

Һәвәскәр абый гаҗәпләнүдән күзлеген бер салды, бер киде.

— Син нәрсә, Сәмигуллин, квадратны да танымыйсың мәллә?

— Юк... ялгыш кына...— дип мыгырданды Мәсәлим. Квадратны урынына куйды да тагын пирамида эзли башлады. Кайсысы икән соң моның пирамида дигәннәре? Бусы өчпочмак бугай инде. Әйе, әйе, өчпочмак — почмаклары өчәү бит. Ә бусы... әллә шушы микән?.. Мәсәлим, башын ишек ягына таба борып, күзләрен чытырдатып йомды да имән бармакларын бер-берсенә якын китерә башлады. Бармак очлары килеп төртелүгә Мәсәлимнең күзләре гөлт итеп кабынды. Шушы, валлаһи, шушы!

Кемдер (Зиннур бугай) эче катып көлә башлады:

— Ромбик бит ул, җүләр!

Мәсәлимнең колагы кызыл чөгендер төсенә керде. Фигураларның әле берсен, әле икенчесен алып карады. Ни булса, шул булыр дип, ул бер читтәрәк яткан фигурага үрелде...

— Ниһаять! — диде Һәвәскәр абый.

Мәсәлимнең эченә җылы керде: «Менә шушы икән бит ул пирамида!»

— Их, Сәмигуллин, Сәмигуллин! Үткән дәресне белмәвең өстенә, алдашасың да икән бит әле син.

Мәсәлим күзләрен челт-челт йомгалады.

Һәвәскәр абый сүзен дәвам иттерде:

— Син бик тырышып эзләгән пирамиданы, Мәсәлим дус, без киләсе дәрестә генә үтәбез әле...

Аннан соң укытучы класска эндәште.

— Укучылар, шулай итеп, без нинди тема узган идек инде?

Класс дәррәү җавап кайтарды:

— Ко-о-н-у-ус!

«Күрәселәр бар икән әле»,— дип уйлады Мәсәлим һәм кулына тоткан конусны өстәл өстеннән эзли башлады...

## ЧЕМЕТЕРЕЛИУН ЙОЛДЫЗ

Соңгы дәрес беткәнлеген белдереп кыңгырау шалтыравы булды, өченчеләрнең «ура» тавышлары класс ишеген дөмберт ачып коридорга ургылып чыкты.

Ризван Бәдримуллин үрә каткан чәчләрен сыпырыштырды да сумкасына китап-дәфтәрләрен тутырып маташкан Алсу Садриҗиһанова янына килеп басты.

— Садриҗиһанова! Э-э-э... Алсу! — дип эндәште ул аңа.— Беләсеңме, әгәр мин, үскәч, ни...— Ул баш чүмечен кашып алды.— Минем Әлфәрит абыем синең Тәзкирә апаң белән йөргән шикелле, мин дә ни... синең белән йөрсәм, беләсеңме, нәрсә бүләк итәр идем сиңа?

Йөзе алма кебек кызарган Алсу оялып башын түбән иде.

— Беләсеңме, Садриҗиһанова... э-э-э... Алсу? Белмисеңдер шул. Мин сиңа, Садр... Алсу... йолдызлар бүләк итәр идем. Унны!

Оялуыннан нишләргә дә белмәгән Алсу кулына сумкасын тотты.

— Юк, җөзне! — дип кычкырды Бәдримуллин.— Ун йолдызны мин Ләләгә бирәм дигән идем. Бирмәсәң, җә үпкәләр. Әйдә, җәл түгел. Ә сиңа Садр... Алсу... җөзне бүләк итәм. Юк, меңне! Милиунны! Юк, терелиунны! Четерелиунны! Юк, метерелиунны!..

Бәдримуллин җилкәсендәге сумкасын парта өстенә куйды да җем-җем янган маңгай тирләрен пинҗәк белән сөртеп алды.

— Беләсеңме, мин сиңа айны да бүләк итәм әле. Ялтыратып. Әлфәрит абыйның солдат каешын ялтырата торган мае бар. Шуның белән айны ышкып ялтыратам да сиңа бүләк итәм. Сумкаңа салып йөртерсең. Китапларың арасына кыстырсаң да ярый...

Бәдримуллин класс түшәменә карап, куллары белән йолдыз чүпләгәндәй итенеп, сөйләвен дәвам иттерде:

— Мин сиңа, Садриҗиһанова, үскәч, менә бу сумканы тутырып кетеремилиун йолдыз бүләк итәм әле. Юк, чеметерелиунны! Юк, бөтен йолдыз...

Бәдримуллинның сүзе шунда өзелде.

— Нишләрмен икән соң мин ул йолдызлар белән, бәбкәем? — диде аңа каршында сулы чиләк тотып торган җыештыручы Хөббениса әби.

Һәм барлы-юклы тешләрен йолдызлардай җемелдәтеп кеткелдәргә тотынды...

## ҺИЧШИКСЕЗ ШУЛАЙ БУЛАЧАК!..

Һичшиксез шулай булачак:

— Син, Диләс, шундый әйбәт малай,— диячәк аңа Кифая.— Моңарчы мин сине аңлап кына җиткермәгәнмен икән. Әйдә, бүгеннән башлап бер партада утырабыз. Өйгә бирелгән эшләрне дә дәфтәремнән күчертермен!..

Һичшиксез шулай булачак: бик озак ялындыргач кына, Диләс Кифая белән бергә утырачак! Өйгә бирелгән эшләрне дә теләр-теләмәс кенә күчерәчәк...

Һичшиксез шулай булачак: класстагы һәр укучы аңа сокланып һәм көнләшеп караячак. Диләс ни теләсә, шуны эшләргә рөхсәт итәчәкләр, ни сораса — шуны бирәчәкләр...

Һичшиксез шулай булачак: моңарчы «Ник чәчеңне алдырмадың?», «Кайчан пөхтәлеккә өйрәнәсең инде?», «Иртәгә үк әти-әниеңне мәктәпкә алып кил!» дип тинтерәткән Вәсилә апасы да аңа елмаеп кына торачак...

Һичшиксез шулай булачак: моңарчы Диләесне бар дип тә белмәгән укучылар: «Синнән дә кулай укучы тапмадык, Диләс, зинһар өчен, ризалаш инде»,— дип кыстый-кыстый аны стена газетасы редакторы итәчәкләр...

Һичшиксез шулай булачак: Диләесне мәктәптә генә түгел, бөтен илдә, хәтта бөтен дөньяда беләчәкләр. Аның даны җир йөзендә генә түгел, Марс, Венера, Нептун... Һәм әле астрономнар да ачып өлгермәгән башка планеталарга да таралачак...

Һичшиксез шулай булачак.

Менә хәзер бер шигырь язачак Диләс, һәм һичшиксез шулай булачак! Һич югында дүртьюллык шигырь язачак Диләс, һәм һичшиксез шулай булачак! «Диләс әйткән иде шул!» — диячәкләр...

Ләкин ни турында һәм ничек язарга?

Гомумән, шигырь нәрсә соң әле ул?

Менә анысын инде Диләс белсә дә әйтмәячәк.

Диләс вәкарь белән генә елмайды һәм карасы кибеп беткән, башы чәйнәлгән зәңгәр авторучкасын өстәл өстендә калдырып урамга трай тибәргә чыгып китте...

Менә ничәнче мәртәбә шулай булды инде...

Һәм... Һичшиксез шулай булачак!..

## ЭЛӘКТЕ

Әһә, эләкте! Урр-р-р... Ә юк, эләкмәгән икән. Менә монысы эләгә дә эләгә инде. Һоп! Тагын эләкмәде. Кача бит инде, кача... Ур-р-ра! Ниһаять, эләкте песигә!..

Кар йомарладым да ишегалдында йөри бирәм. Тә-ә-әк... Тагын нәрсәгә эләктерергә икән? Ата казгамы? Юк. Кирәкми. Болай да янныннан тын алмыйча гына үтәм. Бер йомарлам кар тисә, күзне ачырмас аннары. Әһә! Әнә бер чыпчык. Моңа берне эләктерсәң дә ярый. Ысылдап та куркытмый, тешләми дә. Чыпчык, дим, чырыйк-чырыйк, урыныңда гына тор, оча күрмә! Тә-ә-әк! Менә шулай, менә шулай. Һоп! Эләк... Юк. Очып китте. Әһә, өй кыегына кунды. Тукта, тукта, чырыйк, шунда гына тор. Мин кар йомарлаганны гына көт инде. Хәзер... Хәзер...

Һоп! Ур-р-ра! Эләкт...

Челтер-р-р!

Тәрәзә пыяласы чәлпәрәмә килде. Чыпчык каядыр юкка чыкты. Өйалды ишегеннән әтинең башы күренде:

— Нишләдең син, малай актыгы? Нишләдең, ә?

Бүрек эчендәге колакларым икесе тиң кызыша башлады:

— Эләкте-е-е...

## ШӘП ИТТЕ

...Кай арада узып китте бу яз, ә? Кош оясы ясарга да өлгермәдем бит, ичмасам. Сыерчыклар кайтуга, шәп итеп, матур итеп ясап куясы калган аны.

Куыш агачтан сырлап-бизәкләп ясап җибәргән булсам, егермеләп сыерчык минем ояга килеп сырышачак иде анысы. Ояны шәп итеп тактадан ясаган булсам, ә? Тавык йомыркасы кадәр генә тишек уеп. Усак тактасыннан әмәлләгән булсам, ничегрәк булыр иде икән? Каеннан? Нараттан?!

...Уф-ф-ф! Кай арада узып китте бу яз, ә? Күр инде, җәй килеп тә җиткән. Җәй көне кошларга оя ясасаң ярый, ясамасаң да ярый. Көннәр болай да җылы бит.

...Ни әйтсәң дә, көз көз инде! Җәл, берәр оя ясап булмады, җәй буена эш тыгыз булды шул. Әле анда чабарга туры килде, әле монда дигәндәй... Хәер, көз көне кошларга нигә инде ул оя? Барыбер көньякка китәләр. Ясасын әйдә җылы як малайлары. Шәп итеп. Матур итеп...

...Борын очлары туңа. Бияләй эченә поскан бармакларны суык чеметтерә. Кыш. Кошкайларга-җанкайларга берәр җимлек-мазар куйсаң, әйбәт булыр иде булуын. И чемченерләр иде рәхәтләнеп...

Иллә дә мәгәр, кызык та инде кошлар сыйланганны карап торуы. Черелдәшә-черелдәшә, үзләренчә сөйләшә-сөйләшә, очына-тузына җим чүплиләр, мин сиңа әйтим, кошлар!..

...Уф-ф-ф! Тагын яз җитте бит, ә! Кара инде, кара, кошлар да килеп җиткән икән! Ә-ә-әнә, берсе баш очыннан гына очып бара. Оя ясарга кирәк булыр. Матур итеп. Шәп ит-т-т...

— Ай!..

Борын очыма чулт итеп бер «тамчы» тамды. Шәп ит-те-е...

## ТИШЕК ХӘТЕР

Сөтле чәй чөмерә-чөмерә, кайнар, майлы коймакны тәмләп чәйни генә башлаган идем, күзләрем ботинкаларга төште. Аһ, бу әбине! Тагын оныткан бит. Бигрәк хәтерсезгә әйләнде соңгы вакытта. Күр инде, тагын ялтыратмаган минем ботинкаларны. Әгәр күрмәгән булсам шуны. Шул килеш мәктәпкә киткән булсам... Билләһи, классташлар алдында оятка кала идем.

— Әби, дим, әби!
— Әү, улым! Коймагың беттеме? Хәзер өлгертәм, хәзер...
— Коймак кайгысы түгел әле монда, әби. Кил әле!
— Ни булды, бәбкәем?
Ну бу әбине! Ни булды, дигән була бит, җитмәсә. Бигрәк хәтерсезгә әйләнде.
— Әби, боргаланмыйча гына әйт әле: нәрсә эшләргә оныттың син бүген?
— Уф, аллакаем, нәрсәне генә оныттым икән тагын? Их, бу хәтерсез башкайларымны...
— Җәһәтрәк исеңә төшер, әби, мәктәпкә соңга калдырасың.
— Өстәлгә чәчелеп яткан әсбапларыңны букчаңа салдым инде... Пинҗәгеңнең сәдәпләрен тактым... Нәрсәне генә оныттым икән соң?
— Тизрәк, тизрәк, әби! Ашыгам.
— Кичә каләмеңне югалткан идең, аны табып бирдем шикелле... Күлмәгеңне үтүкләдем... Букчаңа өч алма тыктым...
— Их, әби, әби... Үзем әйтмәсәм, бернәрсә дә белмисең бит син. Кара менә, кара. Чалбарга түгел лә инде. Ботинкаларга кара! Күрәсеңме, үтүклән... кремланмаган бит! Ничек шуны онытасы иттең инде, әби?
— Әй, бу башкайларымны, әй, бу тишек хәтеркәйләремне... Коймак пешерәм дип, онытыплар җибәргәнмен бит! Хәзер, улым, хәзер.
— Колагыңа шуны киртләп куй, әби, ялтырап торган ботинка — укучының күңел көзгесе ул! Шуны онытма...
— Шулайдыр инде анысы, шулайдыр...
Ике коймакны бөтереп авызга чумдырдым. Әби мышкылдый-мышкылдый ботинкаларны ялтырата. Ну, акрын да кыймылдый инде. Кара инде, кара... Кит инде-е-е... Башка берәү булса, әйтер идем инде мин аңа. Үземнең әбием шул. Әйтеп булмый.
— Ярар, әби, җитәр. Бик үк ялтырап тормаса да ярар инде бу юлы. Иртәгә шәп итеп ялтыратырсың... Ой! Соңга калам бит!..
Ике-өч коймакны эләктердем дә чыгып йөгердем. Артымнан әби нидер кычкырып калды...
...Өлгердем! Атылып класска килеп керүгә, классташларым дәррәү көлеп җибәрде. Башымны иеп, аякларыма карасам... ботинкалар өйдә онытылып калган!
Ну, бу әбине! Ботинкаларны аякларга кидерергә оныткан бит, хәтерсез!

## АВТОПОРТРЕТ

Безнең класста бик шәп бер малай бар. Рәсемнәрне, бигрәк тә карикатураларны коеп кына куя инде менә. Аның сурәтләренә сокланмаган кеше юк.
— Исеме, фамилиясе ничек соң ул малайның? — дип сорарсыз инде сез, әлбәттә. Әйтергә дә уңайсыз инде... Мактану кебегрәк килеп чыга. Әйдә, ярар, бик кыстагач, әйтим алайса... Әфләтунов ул! Ягъни мәсәлән, мин...
Менә әле карикатура ясарга уйлап торам. Кемне ясарга икән? Рәсимнеме? Әйдә, ясыйм шуны. Беркөнне ник миннән авыз ерып көлде? Көлмәсен иде. Бөтен класс алдында: «Әфләтунов бер атна инде дәресләргә соңга калып килә. Бүтән болай ташбакаланмасын, вакытында чара күрергә кирәк»,— дигән була җитмәсә. Хәзер үзен ташбакага атландырып куйыйм әле. Җүнле кешедән икенче көлмәскә әйбәт булыр...
Миргалимне дә ясарга кирәк. Классташларына да ярдәмчел түгел. Мәсәлән, ник миңа дәфтәрен кичә биреп тормады. Өй эшен күчерергә. Бирсен иде. Шуның аркасында «икеле» чәпәделәр. Ясадым Миргалимне дә. Ташбакага атланган Рәсимнең җирән чәчен кара төскә генә буядым — Миргалимнең нәкъ үзе булды да куйды...

Кәримне дә ясадым. Йөрмәсен, миннән дә уздырып, кызлар чәчен тарткалап. Ташбакага атланган Миргалимнең борынын бераз гына кәкрәйттем...

Карикатураны стена газетасы редакторы Гөлнарага бирдем.

— Бүген үк гәҗитегезгә кләйләп чәпәгез дә Рәсимнәр, Миргалимнәр турында рәсем асты языгыз. Штубы, иртәгә гәҗит стенада булсын, карагыз аны! — дип бик каты кисәтеп әйттем. Һәм кулларымны чалбар кесәсенә тыктым да сызгыра-сызгыра китеп бардым...

Икенче көнне килсәм, ни күзләрем белән күрим, өелгәннәр, мин сиңа әйтим, стена газетасы тирәсенә. Елышканнар. Этешә-төртешә мин ясаган карикатураны карыйлар. Көлешәләр...

— Вәйт килештергән бу!

— Ташбаканы карагыз әле, малайлар, ташбаканы карагыз!

— Нәкъ үзе бит, нәкъ үзе!

Горур гына атлап малайлар өере янына килеп бастым. Вчүтеки, үзем ясаган рәсем бит — карарга кирәк!

Борынымны гәҗиткә төрттем. Әйбәт чыккан! Сокланудан телемне шартлаттым. Җә, карыйк әле, ни язганнар икән рәсем астына-а-а...

Күзләрем шакмакланды. Рәсем астына, мин ясаган карикатура астына зу-ур итеп: «Автопортрет. Ясады карикатурачы-рәссам Әфләтунов Тәбрис» дип язылган иде...

## КАТКАН ПРӘННИК

Каткан прәнникне авыз эчендә җебетә-җебетә, башкаларга күрсәтмичә генә ашап утырганда, үзем өчен ачыш ясадым: безнең класста сараннар күп икән бит! Әйе, әйе, юмартлар түгел — сараннар! Мондый искиткеч уй кайдан башыңа килде әле, дисезме? Тыңлагыз, аңлатам: әйтик, берәрсе тәмләп конфет ашый, ди. Билгеле, гадәттәгечә, юк-бар сәбәп тапкан булып, мин моның янында таптанам. Әле конфетына, әле күзләренә карап торам. Сорамыйм. Юри сорамыйм. Бирер микән конфет, юк микән? Бу түзми, кесәсеннән бер конфет алып миңа суза. Алам, әлбәттә. Ә үзем эчемнән генә: «Саран, гуҗ, тәмлетамак, тагын берне бирсә, ни була инде?!» — дип тегене тиргим. Әле җитмәсә, шул бер конфеты өчен рәхмәт әйткәнне көтеп торадыр. Әйтте ди, әйтми ни... Мин, конфет суыра-суыра, горур гына китеп барам, теге саран, чепи күзләрен челт-челт йомгалап, артымнан карап кала...

Әйтик, тагын берәрсе класска әфлисун алып килде, ди. Ул аны, әлбәттә, минем авыздан сулар китерерлек итеп, кызыктырып ашый инде. Саран икәнен белсәм дә, сиздерми генә үзен сыныйм. Сорамыйм. Юри. Ялынып сорасалар аны мин дә бирәм. Һәрхәлдә, уйлап карар идем әле...

Яртысы ашалган, татлы суы тамчылап торган әфлисуннан күзләремне алмыйча гына сораштырган булам. «Абыең апкайттымыни?» — димен. Әфлисунының бер кисәген тагын юк иткәнче: «Абыең, синең шикелле, шәп кеше дә инде!» — димен, сүз өчен генә мактаган булып. Ә үзем һаман сыныйм. Шуннан түзми теге, әфлисунының бер кисәген миңа бирә. Ис китмәгән булып алам, әлбәттә. Үзе бирә бит, сорап, ялынып-ялварып алмыйм. Рәхмәт әйтәсе килсә дә, әйтмим. Юри. Ике кисәк бирсә әйткән булыр идем, бәлки. Һәрхәлдә, уйлап караган булыр идем әле...

Әйе, безнең класста сараннар күп икән шул. Үзләре белеп бирү кая ул — сорап-сорап та бирмиләр хәзер. Бозылды халык... Менә миннән сорасалар... Нинди тәм-томым бар, берсен дә җәлләмичә бирер идем! Чын әгәр!..

— Тәбрис, баядан бирле прәнник кимерәсең, миңа да авыз иттер әле!..

Әһә! Әнә, юмарт икәнлегемне сизеп тә өлгерделәр инде, сорый да башладылар. Бирде ди, бирми ни! Үземә дә бер генә прәнник. Кесәдә тагын икәү бар-барын, ләкин аларны мин дәрес

башлангач ашармын дигән идем. Менә булсын иде миндә бер сумка прәнник! Ул чагында һәрберсенә ике яки өч прәнник биргән булыр идем. Һәрхәлдә, уйлап караган булыр идем әле...

## ФОКУСКА КАРШЫ — ФОКУС

Кемгә дә булса фокус күрсәтәсе килеп китте. Коридорны иңләп-буйлап йөрим шулай. Күрәм: бер почык борын тәрәзә янында шыпырт кына нидер күшәп тора. Күзләре челт-мелт килә үзенең. «Хәзер ашарга сорый инде бу»,— дип, эченнән генә минем турыда начар уйлап торадыр әле. Теләсә нинди бала-чагадан тәм-том сораныргa мин ул хәтле беткән малай түгел бит әле.

Килеп бастым почык борын каршына.

— Фокус-мокус күрәсең киләме, әрекмән колак? — дим моңа.

Килә дигәнне аңлатып башын гына селки бу. Кара син аны, ә! Сүзен дә әйтә алмый. Чыпчык йомыркасы гына сыярлык авызына алагаем тутырмаса ни булган инде, комсыз!

— Җәмил Кия дигән фокус күрсәтүче турында ишеткәнең бардыр?! Менә мин шул Җәмил Киядән дә шәбрәк күрсәтәм...

Теге, ниһаять, чәйни торгач, авызындагы ризыгын йотып җибәрде дә:

— Җәмил Кия түгел, Эмиль Кио ул! — дип чәпчеде.

— Абзаңны өйрәтмә,— дидем мин төксе генә.— Җәмил Кия икәнен мин белгәндә, син тумаган да идең әле. Җәмил Кия — аның татарча исеме, бик беләсең килсә... Йә, күрсәтимме фокус?

— Күр-рсәт...

— Тә-ә-әк... Карале, алай-болай печинҗәң юктыр? Печинҗә белән күрсәтәм...

— Берәү генә бар,— ди бу.

— Чыгар,— мин әйтәм.— Бу фокусны күрсәтү өчен өч-дүрт печинҗә кирәк иде дә инде. Ярар, бер печинҗә белән генә маташып карыйм. Тик, кара аны, әгәр фокус барып чыкмаса үзеңә үпкәлә. Өч-дүрт печинҗәң булмаганга мин гаепле түгел...

Сизеп торам: теге, эченнән сыкрап кына, печинҗәсен миңа суза.

— Алай жәлләп бирсәң, кирәкми. Печинҗәң үзеңә булсын! — дидем мин.— Жәлләп бирсәң, фокус барып чыкмый да чыкмый инде ул.

— Жәлләмим лә,— ди бу.

— Алайса, фокусны башлыйм. Карап тор менә: печинҗәне сул учка салдым. Булдымы? Булды. Хәзер мин уң кулны синең баш өстендә йөртәм. Күрәсеңме, ничек матур итеп йөртәм кулны. Хәзер син менә шул кулның имән бармагыннан күзләреңне алмаска тырыш... Ныклабрак кара... Чәвәләй-сәвәләй, чупыр-купыр, фурс-мурс-һоп!..

Мин җәһәт кенә печинҗәне авызга шудырам. Тәмле-е! Тегенең күзләре минем имән бармакның хәрәкәтләнгәнен күзәтә...

— Менә булды да фокус! — дидем мин, печинҗәнең язмышын матур гына тәвәкәлләгәч.

Почык борын әле минем сул учка, әле үзенең баш очында һаман да йөреп торган уң кулның имән бармагына карап калды.

— Ә печинҗә кайда? — ди бу. Чүт кенә еламый.

— Кайда дип... Менә үзем дә аптырап торам әле: кайда булырга мөмкин бу печинҗә! Фокус бит ул шундый нәрсә, үскәнем, аны хәтта Җәмил Кия үзе дә аңлап бетерми икән кайчагында...

— Беренчедән, Тәбрис абый,— ди бу бераздан,— Җәмил Кия түгел. Эмиль Кио! Икенчедән, син печинҗәне ашадың...

— Бик мөмкин,— мин әйтәм.— Фокус бит ул шундый нәрсә...

— Өченчедән... Тәбрис абый, колагыңа гына бер сүз әйтимме?

— Җә, әйтеп кара,— дидем мин, башны ия төшебрәк, һәм шул вакыт алданганымны аңладым. Аңладым аңлавын, ләкин соң иде инде.

Почык борын минем борынны шундый итеп эләктереп алды, әйтерсең лә келәшчә белән кыстылар, күзләрдән яшьләр атылып чыкты. Анысы гына бер хәл, җитмәсә, теге малай актыгы борыннан тоткан килеш мине үзебезнең класс ишеге янына кадәр алып килде. Алып килде дә:

— Бу фокус, Тәбрис абый, «фокуска каршы — фокус!» дип атала,— диде һәм мине, төрткәләп, ишектән кертеп җибәрде...

## БӘХӘС

Математика дәресе башланды.

Кәримә апа, тактага акбур белән сызгалый-сызгалый, нидер аңлатырга кереште. Ә без, Марат белән икәү, бернәрсәгә дә исебез китмәгән кыяфәт белән, чыш-пыш килеп, сөйләшеп утырабыз.

— Әнә теге карганы күрәсеңме? — диде Марат, авторучка карасына буялып беткән бармагы белән урамга күрсәтеп.

— Күрәм,— дидем мин.

— Синеңчә ничек, карганың кайсы тәпие кыскарак? Уңымы, әллә сулымы? — дип сорады Марат.

— Минемчәме? Минемчә, уң тәпие!

— Ә минемчә, сул тәпие! — дип, үз тискәресенә барды Марат.

— Юк, уң тәпие! — дидем мин.— Әнә, уң яккарак авышкан да хәтта...

— Сул тәпие дигәч, сул тәпие инде!

— Уң тәпие!

— Әйдә бәхәс! — диде Марат.

— Әйдә! — дидем мин.— Ә нәрсәдән бәхәсләшәбез?

— Бер банка җиләк вәринҗәсеннән.

«Баллы тамак» дигән кушаматны тикмәгә генә такмаганбыз икән Маратка, дип уйлап алдым мин.

Бәхәсләштек.

— Ә кая соң карга? — диде Марат, тәрәзәгә таба борылып карагач.

— Чыннан да!

Без бәхәсләшкән арада карга очып киткән иде.

— Күңелеңне төшермә,— дип юатты Марат.— Әйдә Сәлимәнең чәч толымы турында бәхәсләшәбез. Үзе үргәнме ул аны, әллә әнисе үргәнме?

— Әйдә соң!

Шулвакыт укытучы апаның тавышы ишетелде:

— Әфләтунов! Кәримуллин! Чыгыгыз әле такта янына!

Без дәррәү торып бастык. Марат, парта өстендә яткан ручкасын алырга иелгән булып, миңа пышылдады:

— Әйдә бәхәс! Миңа «икеле» куячак!

— Юк, сиңа түгел, миңа куячак!

— Юк, миңа!

— Ә миңа беренче итеп куячак! Әйткән иде диярсең...

— Юк, миңа!..

— Әфләтунов! Кәримуллин! Саңгыраулангдыгыз мәллә?

Башларыбызны горур тотып такта янына атладык.

...Такта сөртергә чакырган икән Кәримә апа.

## ШАМАКАЙ

Их, Нәфисә, Нәфисә!

Ничекләр генә көлдерергә инде сине, ә? Ничекләр генә итеп елмайтырга? Сине көлдерәм дип ниләр генә уйлап чыгармадым бит мин. Төннәр буе, дәресләр буе күпме баш ваттым. Әле менә бүген дә, география дәресендә, колакларның икесен тиң селкеткән идем — иң элек кәнфит-прәннек күп ашаудан унсигезгә генә калган тешләрен «җемелдәтеп» сипкелле Хәнәфи пырхылдады. Аңа кушылып бөтен класс гөжләргә тотынды. Ә Нәфисә көлмәде, керфекләрен дә сирпеп карамады, ичмасам...

Әдәбият дәресендә Мәхмүт, бик әртистләнеп, «Мокамай»ны сөйләде. Сәлимә апа «5»ле куйгач, авызын әрекмән яфрагын хәтерләткән колакларына кадәр ерып, урынына утыруы булды — чәрелдек тавыш бөтен классны дер селкетте. Кеп-кечкенә кнопка шулхәтле зур тавышка сәбәпче булыр дип башыма да китермәгән идем. Эшнең нидә икәнен секунд эчендә аңлап алган классташлар, парталарга башларын бәрә-бәрә, тез башларын калтырата-калтырата, борын асларын куыкландыра-куыкландыра көлделәр. Мин дә хихылдадым. Ә Нәфисә — юк! Көлми, и вәссәләм!..

Бер җаен табармын табуын...

Хәер, таптым да бугай инде: авторучка карасын агызып, мыек ясадым. Чем-кара мыек. Чегәннәрнеке төсле...

Тарих дәресендә укытучы Хөрмәт абый канатланып, дәртләнеп әллә нәрсәләр сөйли башлаган гына иде, минем чырайны күреп, телсез калды. Классташлар тотындылар көләргә! Мин көләм, алар көлә. Алар көлә, мин...

Әлеге дә баягы Нәфисә генә көлмәде. Кара күзләре белән бер тутырып карады да:

— Җитәр инде, Тәбрис, шамакайланма,— диде.— Син бит үзең бик әйбәт малай!

Һәм шундый итеп елмайды — «кара мыек» өстендә тырпаеп торган борын очыма тир бәреп чыкты хәтта.

Көлке түгел, малайлар!

## УТЛЫ ТУП

«Прәнник бирәм, Тәбрис!» — диегез. «Бер атна буена мәктәпкә синең сумкаңны да күтәрешеп барырмын, Тәбрис!» — диегез. Тагын әллә ниләр диегез, барыбер үз сүземдә торачакмын: безнекеләр уйный белми. Юк, белмиләр! Кая ул уйнау! Аякларын да күтәрә алмыйлар бит әнә. Кара инде, кара инде Нәҗипне! Кеда башына песи кебек кенә килеп яткан тупка да юньләп тибә алмый бит. Җебегән. Чиле-пешле йомырка! Үзем уйнасаммы?! Күрсәтер идем тибеп. Капкада Ренат Дасаев хәтле өч Мәхмүт торсын, мин типкән туп әнә шул өч Мәхмүтеңне мәтәлдереп ситкыга сыланачак! Эпекәем менә!

Нинди шәп туп чирәм өстенә зерәгә чабулап йөри. Юньләп тибүче юк. Тегеләр ярыйсы уйный. Аларга ул кадәр сүз әйтеп булмый. Әнә бит безнекеләр капкасына өч тупны бер-бер артлы чәпәделәр. Авыз ачып, чирәм санап йөрсәң унны да чәпәрләр әле. Фамилияңне сорап тормаслар. Кара инде бу Әлфиргә генә бер! Ерык авызын җыя алмый азаплана. Ә-ә-ә... тегеләр капкасына бер туп керткән икән. Ялгыш...

Юк инде, булмады. Ибраһим да ышанычны акламады. Үзен көчкә сөйри. Кая инде аңа тупны куып җитәргә! Кара инде, кара инде, шулай тибәләрмени?! Нәрсә?! Тагын туп тегеләр

капкасына очты. Их, керде бит тәки. Әйе шул, Ибраһим маладис ул! Ул типкән туп Мәхмүтнең үзен сөйрәп алып керә капкага. Нәҗип тә әйбәт кенә уйный башлады. Шулай да... мин булсаммы?! Мин булсам, туп җиргә дә төшмәс иде... Очып кына барыр иде дә — һоп! — ярты сәгать эзләрләр иде мин типкән тупны. Кара инде, кара инде бу Мирсәеткә!

— Мирсәе-е-ет! Кизәнеп ти-и-ип! Җәлләмә сыйрагыңны!

Минем киңәшне ишетте бугай, Мирсәет, дуамалланып, тупка тибеп җибәрде... Җибәрде...

Өч секунд та үтмәгәндер, мин борынымны тотып җиргә аудым...

...Туптан ут чәчрәгәнен генә хәтерлим.

## КУШАМАТ

Мактанып әйтүем түгел, класстагы барлык малайга да кушаматны мин уйлап таптым. Мәсәлән, Маратка «Ташбака» дип куштым. Чөнки гел акрын кыймылдарга ярата. Нәҗипкә «Куян»ны чәпәдем — концерт-мазар булган саен куян турында шигырь сөйли. Мәхмүткә «Бал авыз» кушаматы ябышты — көн саен тәнәфестә бал ягылган ипи ашый. Умарталары бар дигәч тә...

Ә үзеңнең кушаматың бармы, дисезме? Юк! Нишләп булсын, ди! Кушаматларны мин үзем кушам бит! Үземә дә кушамат такмам инде...

...Класска килеп керүгә күзләрем тактага төште. Нәрсә бу? Акбур белән сырлый-сырлый такмак язып куйганнар:

Ярата дәрестә күшәргә,
Ярата кушамат кушарга...
Ялганлаудан бер дә бушамас.
Кушаматы аның — Кушамат!

Кушамат?! Миңамы? Ачуымнан кычкырып җибәргәнемне сизми дә калдым:

— Кайсыгыз язды? Синме, Ташбака? Синме, Бал авыз?

— Без яздык! — диде Куян тыныч кына.— Син генә кушаматсыз йөрмәссең бит инде, әйеме, Кушамат?!

— Ә?! Ә-ә... э-э-э... әйе-е-е...

Мин Куян... Куян... Юк ла... Нәҗипнең карашыннан бөрешеп куйдым.

## КӨТӘБЕЗ

Без һәммәбез дә көтәбез.

Әти дөнья көтә.

Апам тәрәзәдән күзен алмый. Кемнедер көтә.

Беләм инде, беләм, күршебез Таһир абыйның безнең өй турысыннан үткәнен көтә.

Абый каникулны көтә. Каникулга чыккач, атлар көтәм, ди.

Әни мичкә бәлеш тыкты. Шуны көтә.

Ә мин? Мин шул бәлешнең пешкәнен көтәм.

Ә мине тышта балыкка барырга дип Айрат көтә. Көтсен. Мин дә көтәм ич...

Бәлеш пеште. Рәхәтләнеп сыйландым да урамга — Айрат янына чыктым. Чыксам... Айраттан җилләр искән!..

Көтә белмәгән кешеләргә исем китә минем.

Ә сезнең?

## ЧЫН КҮҢЕЛДӘН

Айрат, озын тәнәфес икәнен онытып, Шәйхи Маннурның «Чын сөю бармы?» дигән китабын укып утыра иде. Аның янына Тәбрис килеп басты.

— Ташлап тор китабыңны. Бер сүз бар ие,— диде ул.

— Әйт сүзеңне,— диде Айрат, башын күтәрмичә генә.

— Мәктәп ишегалдына чыгыйк,— диде Тәбрис.— Шунда әйтәм.

Айрат авырсынып кына китабын парта астына чумдырды.

Ишегалдына чыктылар.

— Чын күңелдән сөйләшик әле,— диде Тәбрис, чаган агачына елыша төшеп.

— Әйдә соң,— диде Айрат.— Тик ни турында чын күңелдән сөйләшәбез?

— Аңламаганга салышма, китап корты! — диде Тәбрис һәм сүзләрне буташтыра-буташтыра бер җөмләгә тезде: — Аңа... син... Нигә... баягынак... бүген... үткән... дәрестә... карап утырдың... елмаеп?

— Кемгә, кемгә? — диде Айрат.

— Соң... Шуңа инде — аңа! Кемгә булсын тагын,— диде Тәбрис һәм бөтен ачуын җыеп Айратка төбәлде.

— Венераны әйтәсең мәллә? — диде Айрат һәм пырхылдап көлеп җибәрде.

— Әйе... Аңа ник елмаеп карадың? — дип бәйләнүендә булды Тәбрис.

— Караса ни. Анда синең ни эшең бар? Сатып алмагансыңдыр бит Венераны?

— Әле соң түгел,— диде Тәбрис һәм биленә таянды.— Колагыңа киртләп куя аласың: бүгеннән башлап аңа синең тарафтан елмаю тыела!

— Нәрсә, нәрсә?! — дип чәчрәде Айрат.— Синнән сорап торалар, ди. Үскәнем, бик беләсең килсә, без аның белән күптән дуслар инде.— Ул тагын да ышанычлырак булсын дипме: — Чын дуслар! — дип тә өстәде.

Тәбриснең мускуллары күгәрчен йомыркасы кадәр булып кабарды.

— Күрәм, син чын күңелдән сөйләшкәнне аңламыйсың,— диде ул...

Ике яшь «әтәч», очына-очына, бер-берсен дөмбәсләде. Әүмәкләшеп арыгач, икесе дә чаган төбенә ауды.

— Соңгы тапкыр... Чын күңелдән... сорыйм,— диде Тәбрис кабарган иреннәрен көч-хәл белән кыймылдатып.— Ник елмай...

Сүз шунда өзелде. Тәбриснең карашы арка терәвечле эскәмиягә төшкән иде. Анда аларның классташы физорг Тәфкил белән сылу Венера чөкер-чөкер килеп ни турындадыр сөйләшеп утыра иде.

«Таза булмаса, моның белән дә чын күңелдән сөйләшкән булыр идем инде мин»,— дип уйлады Тәбрис, Тәфкилгә карашын ташлап. Һәм әле күз төбе күгәргән Айратка, әле үзенең шиңгән мускулларына карап көрсенеп куйды.

## «ТАЛА ИКЕ БЕЛӘГЕМ...»

Хәтере шәп Тәбриснең. Әле менә бүген иртән радиодан концерт тапшырганнар иде. Бер бик матур җырның «Тала, тала, тала, тала, тала ике беләгем...» дигән сүзләрен шундук отып алды ул. Җырчы абый әллә ашыгыбрак җырлады инде, калган сүзләрен отып өлгерә алмады. «Мин дә җырчы булачакмын!» — дигән уй нәкъ менә шул вакытта килде Тәбриснең башына...

Өйдә сеңлесе идән юып маташа иде. Аның берничә мәртәбә уфылдап куйганын ишеткәч, Тәбрис чыдый алмады:

— Ачуны китереп уфылдамале,— дип кычкырды ул сеңлесенә.— Әйдә, тизрәк кенә юып бетер дә шул идәнеңне...

Аяк арасында мәче буталып йөри иде, ачудан аның койрыгына басып чырыйлатты Тәбрис.

— Өйрәтеп торганчы, булышыр идең, ичмасам,— диде сеңлесе.

— Күп сөйләшмә. Минем ашыгыч эшем бар,— диде Тәбрис.— Өйдә тизрәк юып бетер дә...

Сеңлесе ике дәү чиләкне алып, чишмәгә суга китүгә үк, өйдә бер ялгызы гына калган Тәбрис, камышлар арасында чурылдаган яшел бака тавышлары чыгарып, җырлый башлады:

Тала, тала, тала, тала,
тала ике беләгем-м-м...

Бу юлларны бер туксан тугыз мәртәбә шулай ачыргаланып җырлады Тәбрис. Урындыкка басып та, диванга кырын ятып та җырлап карады. Танылган артистлар шикелле кулларын кушырып та, өстәл читенә таянып та җырлады, Галимәттиләрнең кәҗә бәтиләре шикелле, үрле-кырлы сикергәләп тә алды...

Тала, тала, тала, тала...

«Гитара белән җырласаң иде бу җырны»,— дип уйлады Тәбрис. Кызганыч, гитара юк. Хәер, гитара булудан ни мәгънә — барыбер уйный белми бит. Шулай да гитара белән җырлау килешер иде микән, дип ул кулына озын саплы чүмеч алды. Гитара чирткән төсле кыланып, баягыдан да яман сикерә-сикерә, боргалана-боргалана җырларга тотынды:

Тала, тала, тала, тала...

Сеңлесе чишмәдән кайтып кергәндә, Тәбриснең маңгае шабыр тиргә баткан иде. Маңгай гына бер хәл, чүмеч сабы да тирләп чыккан иде.

...тала ике беләгем...

Пружина кебек кысылган мәче, мыекларын селкетергә дә куркып, бу мәхшәр-тамашаны диван астына посып кына күзәтеп ята иде. Ул-бу булмагае, дип ул арткарак шуышып куйды...

Тәбриснең әтисе эштән кайтты.

— Сеңлең булдырган, бүген бик күп эшләр эшләгән,— диде ул Тәбрискә.— Ә син, улым, ниләр майтардың?

Җавап сүзе ишетелмәгәч, әтисенең кашлары җыерылды.

— Марш абзар чистартырга! — диде ул.

...Озак матавыкланды Тәбрис абзарда. Борын очында эленеп торган тозлы тир тамчысы зурайганнан-зурая барды, ахырда, өзелде дә ботинка башына чупылдады. «Теге җырчы абыйга да әтисе шулай эш кушкандыр әле»,— дип уйлады ул эчке бер юаныч белән. Һәм кабарган уч төпләренә хәлсез генә карап алды...

Тәбриснең ике беләге дә талган иде.

## БАТЫР МАЛАЙ

Салих, колагыма керердәй булып:

— Сигезенче класста, теге, бар бит әле, ни, ә-ә-ә... Газинур! Шуны беләсеңме? — дип пышылдады.

— Самбист Газинурны әйтәсеңме? — дидем мин битараф кына.— Беләм, ник белмәскә!

— Белсәң шул,— диде Салих һәм як-ягына карангалап алды,— мин аның... нинең... Газинурның җәлпәк борынына берне кундырдым! Җиргә сеңә язды...

— Кит аннан! Булмасны!

Салих як-ягына янә каранып алды.

— Борыныннан... тфү!.. күзләреннән утлар чәчрәде... Сәхәп бабайның бүреге кадәр булып. Үзем дә печтек кенә шүрләп куйдым хәтта.

Салих җентекләп сөйләргә әзерләнде.

— Ну, малай, кундырсам шәп кундырам инде мин! — дип мактанып алды ул.— Йөрмәс моннан соң кәпрәеп.

— Ышанмыйм! — дидем мин.

— Акча түләп ышандыра алмыйм инде, малай! — диде Салих.

Сизеп торам, сөйлисе килә тегенең.

— Шундый итеп кундырдым,— дип сүзен дәвам иттерде Салих.— Кары шәп иде. Җепшек кар!

— Нинди кар тагын? — дидем мин, берни дә аңламыйча.

— Нинди кар булсын инде?! Газинурның борынына мин ыргыткан кар! Койма артына постым да — һоп! Тондырдым берне. Төз атам бит мин, үзең беләсең...

— Э-э-э...

— Ярый әле үзе күрмәде,— диде Салих.— Газинур як-ягына каранган арада, мин үзебезнең сарык абзарына кереп качкан идем инде...

## СУПЕРЧАНА

Чана ясадым. Шәп килеп чыкты — искиткеч! Әйбер-сәйбер ясарга оста инде мин шулай. Коеп кына куям. Әйткәнем шул: синең сәләмә чанаң янында минем чана — галәмәт!

Шуганда җайлы булсын өчен дип, чанага йомшак утыргыч белән иске виләсәпиднең рулен беркеттем. Каршыга очраганнарны кисәтер өчен рулгә кыңгырау куйдым. Чананың алдында да, артында да бәтәрәй белән эшли торган яктырткычлар барлыгы турында әйтеп тә тормыйм. Караңгы төшкәч тә шуган чакларны искә тотып куйдым аларны. Кечкенә букча элергә дә урын таптым. Букчада — май ягылган ипи белән термос. Термоста — мәтрүшкәле кайнар чәй... Тагы... Ә-ә-ә, көзге барлыгын әйтергә онытып торам икән. Кыскасы, минем чана — суперчана! Тауга выжылдап шуып менеп китәсең — артта җил генә кала да сызгырып, карлы буран гына кала ыжгырып. Сизеп торам, синең колакларың тырпайды: «Ничек инде... Таудан шуып төшәләр, тауга шуып менмиләр...» — дисең. Шу син үзең сәләмә чанаң белән түбән таба. Ә минем чана... Минем чана — тауга шуып менә торган чана! Шуңа күрә чанага тормоз да куймадым мин. Тау менгәндә тормоз кирәкми. Иллә дә җилдереп менә инде чанам. Шул чагында магнитофоннан җыр да тыңлап җибәрсәң:

...Керкәле таулары биек,
Биек булса да меник...

Телисеңме, мин сиңа шушы суперчанамны җәлләмичә бирәм. Миннән бүләк булыр үзеңә. Йөрмә ул сәләмә чанаңны өстерәп...

Үземнеке шикелле чананы мин сиңа йөзне ясап бирә алам. Юк, меңне! Миллиунны!.. Рәсем ясарга оста мин. Кәгазь белән каләм генә җитсен.

## БОНЖУР, МАЛАЙ!

*(Тәбрис Әфләтуновның чит илдәге яшьтәшенә язган хаты)*

Исәнме, чит илдәге таныш булмаган минем кадерле дустым, киндерсюрприз! Сәлам, кәнишне!

Сиңа таныш булмаган кадерле дустың Тәбрис безнең илдән хат яза. Бонжур, малай! Минем әтием, әнием, әбием, бабаем бар. Синекеләр бармы? Данкешен! Тагын бер сеңлекәш, бер энекәш һәм дә ике абыем бар. Синекеләр бармы? Напасаран! Адидас. Мин класста гел «5»легә генә укыйм. Гутен морген, гутен таг! Упшымто, безнең класста һәркем гел «5»легә генә укый. «2»ле алучылар күп түгел. Шуңа күрә классны артка сөйрәүчеләр бөтенләй юк диярлек. Әлпитиси! Син ничәнче класста укыйсың? Морда! Минем шикелле бөтенесен әйтеп

яз. Айнцваен! Мин китап укырга бик яратам. Безнең авылда бөтен кеше дә китап укырга бик ярата. Пепси-кола. Безнең авылда Габдулла Тукайны белмәгән кеше юк. Син дә беләсеңдер әле Габдулла Тукайны?! Привет! Безнең класста алты укучы укый. Бишесе малай, берсе кыз. Чупа-чупс! Барыбыз да ипле, чиста-пөхтә, тәүфыйклылар. Твикс! Син тәүфыйклымы? Пардон! Минем әти агроном булып эшли. Синең әтиең агрономмы? Әйтеп яз. Гутбай! Безнең авылдагы бөтен кешедә дә машина бар. Гитлер капут! Безнең авылда әбиләр дә кибеткә машина белән генә баралар. Жывачка. Чират торып тормыйлар. Ай лавью. Безнең авыл кибетендә бөтен нәрсә бар. О, кей! Җаның ни тели кибеттән, шуны сатып алаласың. Халык чиратның ни икәнен дә белми. Черт побери! Шул, юграк әйберләр кайтса гына инде. Яңа тотылган балык, лимонад һәм башка тәм-томнар сыманрак. Чао! Мин үскәч космонавт булам. Вива, Куба! Әгәр космонавт булалмасам (тешләрем начар минем), һичшиксез, берәр нинди галим булам. Кетчуп! Әгәр дә галим булып булмаса, завод-фабрика башлыгы булам. Бездә бөтен кеше дә үскәч шулай итә. Стиморол! Син үскәч космонавт буласыңмы? Булсаң әйтеп яз — айга яисә Марска бергә очарбыз. Бонжур, малай! Пиши против! Хенде хох!

## СЫБЫЗГЫ

Хөсәен сыбызгылар җыя.

— Өйдә минем йөзләп сыбызгы бар инде,— ди ул.

Бардыр да. Көн саен мәктәпкә яңа сыбызгы алып килә бит. Һәрберсен күрсәтә-күрсәтә мактана әле җитмәсә:

— Монысын фәлән абыем бүләк итте... Ә бусын төгән абыем бирде... Менә монысын... калайдан ясалганын Гаптери абзый бирде,— дигән була.

Бүген генә, никтер, сыбызгысыз килде Хөсәен. «Өйдә онытып калдырганмын»,— ди. Алдый, билгеле. Без белгән, әй лә, без белмәгән бүтән сыбызгысы юк инде аның.

— Фью-фью-фи-и-ит!

Чү! Сыбызгы тавышы түгелме соң бу? Шул ич. Хөсәен алдаган ич безне. Әнә бит, алып килгән...

— Фью-фи-фью-фит!

Укытучыбыз Фәния апаның кулындагы акбуры идәнгә төшеп каядыр тәгәрәде. Без һәммәбез артка борылып карадык.

— Фью-фью-фью...

Партасына башын кырын салып йокыга киткән Хөсәеннең борыны сызгырган саен китап битләре җилфер-җилфер килә иде.

Менә сиңа яңа сыбызгы!

# КӘМИТЛӘР

## ЧӘПӘЛӘЙ ҺӘМ ТӘПӘЛӘЙ МАҖАРАЛАРЫ

*(Әкият-пьеса)*

КАТНАШАЛАР:
Әкиятче
Тылсымлы агач
Чәпәләй
Тәпәләй
Һауһауҗан
Мырау
Мыргали

БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Пәрдә алдына Әкиятче чыгып баса.

Әкиятче (*залдагы балаларга дәшә*). Исәнмесез, балалар?!
Балалар. И-сән-ме-сез!
Әкиятче. Телисезме, балалар, мин хәзер әкият сөйлим сезгә?
Балалар. Телибез, телибез!
Әкиятче. Шыттыр, мыттыр, фаласа — сөйли башлыйм, алайса...

Баллы икән алмагыз,
Ачы икән тормагыз...
Әкиятем — булган хәл:
Авыз ачып тыңлагыз!
Бүген-кичә үткәндә,
Һәм берсекөн җиткәндә,
Мин әле сабый чакта,
Син әле абый чакта,
Ул әле малай чакта,
Әтиләр бабай чакта,
Нәниләр әни чакта
Булган, ди, мондый хәлләр...

Ут сүнә. Әкиятче югала. Акрын гына пәрдә ачыла. Сәхнәдә — авыл күренеше: ишегалды, өйнең бер тәрәзәле өлеше күренеп тора — тәрәзә ачык, телевизорда мульфильм бара, ахры, бүре тавышы ишетелә: «Ну... Ну... заяц, по... погоди!» Сиртмәле кое. Эт оясы. Оя янында Һауһауҗан йокы симертә. Койманың теге ягында да, бу ягында да агачлар күренә. Коймага вилсәпид сөялгән. Салмак кына шомлы-сихри көй агыла башлый. Кинәт ишегалдындагы бер агач «әллә нишли» — ул калтырарга-дерелдәргә тотына... Көй көчәя. Агач шулвакыт яшел җенпәригә әйләнә. Дөресрәге, ул Тылсымлы агачка әверелә.

Тылсымлы агач. У-у-ух! (*Ачык тәрәзә янына килә.*) Туйдырды бу ялкау мәченең бот күтәреп, телевизорны өзлексез каравы! У-у-ух! (*Йоклап яткан эт янына килә.*) Туйдым бу ялкау этнең йокы бүсеп ятуыннан! У-у-ух! Нишләтергә инде боларны, ә? Берсе өзлексез шульти-мульти карый, икенчесе көне-төне төш күрә. Тьфү, ата ялкаулар! Тәмам эшлексезгә әйләнделәр... Ичмасам, укый-яза да белмиләр бит. Бер-бер чара күрмичә булмас бу ялкауетдиннәргә! *(Кинәт Һауһауҗан гырлый башлый.)* Кара инде монысына, карагыз инде

моның гырлавына!.. Трактормыни! Туктатмасаң, бензине беткәнче гырлаячак бу. *(Янына килеп Һауһауҗанны селкеткәли.)* Әлү, әлү, Ялкауетдин Тракторович!.. Сүндер моторыңны! *(Этнең танауыннан тарта, Һауһауҗан гырлавыннан туктый, икенче якка борылып ята.)* Менә шулай... Ичмасам, гырлавыннан туктады. Бу-у-у... Өстенә менеп «Ламбада» биесәң дә уянмый бу! Юри генә биеп карыйм әле... *(«Ламбада» биюе көе агыла. Һауһауҗан өстенә менеп биергә тотына. Бераз хәрәкәтләнгәч туктый.)* Ю-юк-ук, боларга, чыннан да, бер-бер чара эшләмичә булмастыр. Мин бу Йокысимертәевич белән Мультфильмкараевичны мәзәк итәм болай булгач... Тылсымыңны бик кирәк чакта гына файдаланырсың дигән иде Йөзьяшәр агач бабам... Кулланырга туры килер, ахры... Тә-ә-әк... Башлыйм, алайса... Әфсен-төфсен, чәфсәләй... Финус-кинус, фәсмәрәй... Дөмберт-мөмберт, дәфлитән, авызыңа чап итәм...

Тылсымлы агачның күлмәк яфракларында сүзләр пәйда була.

Әһә, булды шикелле! Әгәр бу ялкауетдин-наданетдиннәр монда язылганнарны укый алса, шул чагында гына алар үз халәтләренә кайта алырлар... *(Тәрәзәгә карап, сихри сүзләр әйтә.)* Ечәм-ечәм, фәс-перәс! Накчый-накчый, чи-чипес! *(Һауһауҗанга карап, кулларын әллә ниләр кыландыра.)* Һаудыр-һаудыр, асмалай.

Кинәт Тылсымлы агач, әүвәлге халәтенә кайтып, агач булып катып кала. Өй эчендә дөбердәгән, мияулаган тавышлар ишетелә. Ул да булмый, тәрәзәдән башта Мырау сикереп чыга, аның артыннан — Чәпәләй, Тәпәләй. Ишегалды буйлап куышалар.

Чәпәләй. Качма, Мырау, качма, барыбер тотам мин сине!

Мырау. Сез түгел, мин сезне куарга тиеш! Мин ашарга тиеш сезне! Белдегезме? Мин — мәче чөнки!..

Чәпәләй. Юк, син мәче түгел. Син — тычкан! Ә без мәчеләр!

Тәпәләй. Әйе, син — тычкан! Ә без — мәчеләр!

Мырау. Юк, юк, мәче мин! Мин сезне ашарга тиеш!

Чәпәләй. Ашамыйча гына тор әле! Җә ашаган диярләр...

Тәпәләй. Әйе, ашамыйча гына тор, яме! Без сине үзебез ашыйбыз. Менә хәзер тотабыз да ашыйбыз!

Мырау. Якын гына килеп карагыз... Бетерәм мин сезне. Мин — каратист! Мин — кара пояслы мәче, беләсегез килсә!

Чәпәләй. Шыттырма, Мырау! Мин ул — кара пояслы мәче! Шулай бит, Тәпәләй?!

Тәпәләй. Әйе, мин ул — кара пояслы каратист. Ә Чәпәләй — сары пояслы!

Чәпәләй. Син нәрсә, Тәпәләй. Мин ул — кара пояслы!

Тәпәләй. Әйе, мин ул — кара пояслы!

Чәпәләй. Ярар, алайса, икебез дә кара пояслы. *(Мәчегә.)* Ишеттеңме, куркак? Без — каратистлар. Без сине хәзер айн-цвайн итәбез... Хи-и-а!

Ул, каратэ күрсәтәм дип, ялгыш Тәпәләйгә тибә. Тәпәләй мәтәләп китә. Мырау агач артыннан эчен тотып хихылдый.

Тәпәләй. Син нәрсә... Чәпәләй?! Миңа типтең бит!

Чәпәләй. Типмәдем мин сиңа... Син үзең ялгыш... минем аякка эләктең...

Тәпәләй. Эләкте, әйе... Күзләреңне ачып аен-цваенла инде...

Чәпәләй. Ярар, җыламасана... Бер типкәннән мәче үлми... Әнә теге куркак тычканны тотарга булыш ичмасам...

Мырау. Тотмый гына торыгыз әле... Хәзер мин сезнең үзегезне тотам... Агач артыннан гына чыгыйм...

Тагын куыша башлыйлар.

Чәпәләй. Яхшы чакта тукта, дим, Мырау... Әгәр туктамасаң, белеп тор, без синнән кәтлит ясыйбыз!

Тәпәләй. Пилмән, диген, Чәпәләй... Пилмән яратам мин...

Чәпәләй. Кәтлит дигәч, кәтлит инде. Мин пилмән камыры яратмыйм...

Мырау (*кое бурасы артыннан калкына*). Ә мин тотсам, беләсезме, нишләтәм сезне? Мин сезне каклыйм, тозлыйм, табада кыздырам... белдегезме?

Чәпәләй. Уф, көлеп үләм! Кем кемне куа соң әле монда?

Тәпәләй. Әйе, монда кем кемне куа соң әле? Минме, әллә синме?

Чәпәләй. Мин, кәнишне!

Тәпәләй. Юк, мин куам! Күрмисеңмени, тирләп беттем инде...

Чәпәләй. Мин күбрәк тирләдем...

Мырау. Юк, күбрәк мин шыбыр тиргә баттым... Димәк, мин сезне куам булып чыга...

Чәпәләй. Чыга-чыга... Тычкан башың белән күп сөйләшеп тор әле, җәме! Хәзер капут ясыйм.

Тәпәләй. Әйе, ачуны китермә безнең! Капут сиңа хәзер! Ишеттеңме, мерсимадам?

Мырау (*кулын югары күтәреп ала*). Напасаран! Хәл генә җыйыйм. Бетерәм мин сезне!

Чәпәләй. Тәпәләй, син теге яктан чамала! Мин бу яктан... Атакага, ур-р-ра!

Тәпәләй. Ур-р-ра!

Мырау кое өстенә менеп баса. Сиртмә чылбырына эленгән чиләккә ябыша һәм дөбердәп коега төшеп китә.

Мырау (*тавышы коедан ишетелә*). Коткарыгыз, ба-та-ам!

Чәпәләй белән Тәпәләй, иелеп, коега карыйлар.

Чәпәләй. Әйттем мин сиңа, Мырау. Качма, дидем.

Тәпәләй. Әйе, әйттем мин сиңа, Мырау!

Мырау. Кот-ка-ры-гыз!.. Үлә-ә-әм...

Чәпәләй. Бераз тагын коен инде, Мырау. Без сине пычрак килеш ашый алмыйбыз бит.

Тәпәләй. Әйе, юын бераз! Безгә ги-ги-ена сакламыйча һич ярамый! Тешләр бозыла, алайса...

Чәпәләй. Диз-зен-терия, диген...

Тәпәләй. Әйе, диз-зен-терия була, алайса...

Мырау. Кот... кот... ыгыз!.. Зин... зин... һар!..

Чәпәләй. Чыгарыйк булмаса, Тәпәләй... Тотын чылбырга!

Тәпәләй. Әйе, чыгарыйк, Чәпәләй. Тотын син дә чылбырга!

Икәүләп чылбырны өскә тарта башлыйлар.

Чәпәләй. Ай-яй авыр икән бу Мырау... Бер центнер бардыр...

Тәпәләй. Биш центнер, диген!..

Чәпәләй. Коеның суын эчеп бетергән бугай бу?!

Тәпәләй. Бетермичә! Ул хәтле акыруына! Төптәге ләмне дә йотмаса ярый әле...

Чәпәләй. Иренмичә син аш пешерсәң, ашка су салып торасы булмый инде... Хи-хи-хи-хи... Иеме, Тәпәләй?

Тәпәләй. Ие, Чәпәләй... Ите дә, суы да Мырауның үзендә. Хи-хи-хи...

Мырауны көч-хәл белән өскә чыгаралар да җиргә төшереп яткыралар. Чәпәләй Мырауның битенә суккалый.

Чәпәләй. Әллә үлгән инде?

Тәпәләй. Йөгереп килеп бер тибимме эченә? Хәзер терелә!

Чәпәләй *(колагын Мырауның күкрәгенә, йөрәк турысына куеп тыңлый).* Үлмәгән әле... Тибә йөрәге... Дөп-дөп итә... Дөп-дөп итә...

Тәпәләй. Дөп-дөп итеп кул белән бер тибимме? Юкса кул бик яман кычыта башлады...

Чәпәләй. Ахмак син, Тәпәләй. Кул белән тибәләр димени?

Тәпәләй. Алайса... алайса... аяк белән берне сугам...

Мырау *(күзләрен ача).* Мин... мин... кайда?..

Тәпәләй *(кулын наган сыман итеп, Мыраугa тибә).* Хенде хох, мерсимадам!

Эт оясы янында яткан Һауһауҗан куркуыннан сикереп тора, кулларын күтәрә.

Һауһауҗан *(кычкырып җибәрә).* Бә-ә-ә!..

Чәпәләй белән Тәпәләй аңа борылып карыйлар да көлеп җибәрәләр.

Тәпәләй. Сиңа әйтмим мин, йокы бүксәсе! Гырлавыңны бел!

Һауһауҗан *(кулларын төшереп, күзләрен уып ала).* Ни булды? Ә?

Чәпәләй. Тик кенә ят, яме! Юкса сине дә коега чумдырып алырга күп сорамабыз.

Тәпәләй. Әйе, без сорап-нитеп тормыйбыз. Айн-цвайн! Әллә синең дә су эчәсең киләме? Килсә, чумдырып алам мин сине.

Чәпәләй. Тәпәләй, телеңне әрәм итеп сөйләшмә! Ул болай да чылбырда. Качмас. Монысын бәйләп куярга кирәк. Бар, тиз генә бау алып кил!

Тәпәләй бау эзләп китә.

Һауһауҗан. Бә-ә-ә... Сез... Сез... нишлисез сез?

Чәпәләй. Тире игәп, күн эшлибез! Күрмисеңмени, ахмак тәкә, ашка ит әзерлибез бит. Тычкан ите!

Һауһауҗан. Бә-ә-ә... Кем тәкә, чикылдык, минме? Кем тәкә?

Чәпәләй. Син булмыйча, мин булмам инде... Әйе, син — тәкә! Ә менә бу... *(Ул Мыраугa типкәләп ала.)* Бу — тычкан. Олы тычкан!

Мырау *(аңына килә).* Мин... мин... тычкан?! Юк, мин тычкан түгел... Мин — мәче... Мин — Мырау!

Мырау торырга азаплана. Бау күтәреп Тәпәләй килеп җитә.

Тәпәләй. Хенде хох, мермисадам! Урыныңнан кузгалма! Юкса баш белән берне сыларммын!.. *(Чәпәләй белән икәүләп Мырауны бәйлиләр.)*

Чәпәләй. Тизрәк бәйлик. Йә тагын качар...

Һауһауҗан. Нишләттегез Мырауны? Бауны чишегез хәзер үк! Бә-ә-ә...

Чәпәләй. Һай куркытты берәү! Һай бер мыегым селкенде...

Тәпәләй. Чәпәләй, барып тибимме шуның авызындагы радиосына? Баш белән... Баш кычыта башлады... *(Башын кашып ала.)*

Чәпәләй. Ашыкма, башта бу тычкан белән эшне бетерик инде...

Мырау. Мин тычкан түгел... Сез тычкан! Мин — мәче! Һауһауҗан, әйт әле, мин мәче бит, әйеме?

Һауһауҗан. Әйе, син — мәче. Мәче булмыйча кем буласың инде син тагы!

Мырау. Күрдеңме, Һауһауҗан мине мәче диде.

Чәпәләй. Дисәни. Ул ахмак тәкә ни әйтмәс.

Тәпәләй. Әйе, ул дивана тәкә ни сөйләмәс.

Һауһауҗан. Нинди тәкә булыйм ди мин! Мин — эт, эт мин! Һау-һау!

Чәпәләй. Өрә белгән тәкә син! Белдеңме, менә кем син!

Тәпәләй. Әйе, белдеңме инде менә?!

Һауһауҗан. Мырау, әйт әле, мин кем?

Мырау. Син — эт, ә мин — мәче!

Һауһауҗан. Ишеттегезме инде, чикылдыклар? Мин — эт!

Чәпәләй. Болар тәмам ычкынганнар, име, Тәпәләй. Һаман үзләренең кем икәнлекләрен аңламыйлар...

Мырау *(залдагы балаларга дәшә).* Балалар, әйтегез сана, мин мәче бит, әйеме?

Балалар. Әйе, мәче!

Һауһауҗан. Ә мин, балалар, мин эт бит?!

Балалар. Әйе, эт син, эт!

Мырау белән Һауһауҗан. Ишеттегезме?

Чәпәләй. Юк, ишетмәдек. Без бит саңгыраулар! Име, Тәпәләй?

Тәпәләй. Әйе, без — саңгыраулар! Без берни дә ишетмибез. Чәпәләй, син нәрсә дидең?

Чәпәләй. Нәрсә дисең, Тәпәләй? Колак берни ишетми. Ашыйсы килә, дисеңме?

Тәпәләй. Ә? Ишетмим! Әйе, «Ашыйсы килә, дисеңме?» дигәнеңне ишетмим.

Чәпәләй. Мин дә синең «Ишетмим» дигәнеңне ишетмим... Духтырларга күренмичә булмас, Тәпәләй...

Тәпәләй. Әйе шул. Ишетмәгәч бик кыен. Барырга кирәк брачка.

Чәпәләй. Киттек, Тәпәләй!

Тәпәләй. Ишетмим! Вилсәпид белән китәбезме?

Чәпәләй. Әйе! Ишетмәгәч кыен шул. Кайткач, аш пешерербез. Бүген — мәчедән, иртәгә — тәкәдән...

Вилсәпидкә икәүләп атланалар. Чәпәләй рульне тота.

Чәпәләй. Пока!

Тәпәләй. Чоу, мерсимадам!

Җырлый-җырлый әйләнеп йөриләр.

### ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Шул ук ишегалды. Мырау — бәйләнгән хәлдә, Һауһауҗан чылбырда килеш үз урыннарында яталар. Икесенең дә башлары түбән иелгән. Тылсымлы агач кинәт телгә килә.

Тылсымлы агач. Йә ничек хәлләрегез?

Мырау да, Һауһауҗан да бер үк вакытта сискәнәләр.

Һауһауҗан. Син дәштеңме, Мырау?

Мырау. Юк, мин түгел. Ә мин син дип торам.

Һауһауҗан. Син дә, мин дә булмагач, кем дәште соң, алайса?

Тылсымлы агач. Мин дисәм, ни әйтерсез?

Мырау да, Һауһауҗан да Тылсымлы агачка текәләләр.

Һауһауҗан белән Мырау. Син?!

Тылсымлы агач. Әйе, мин, мин! Ник шаккаттыгыз?

Мырау. Син... сөйләшә беләсеңмени?

Һауһауҗан. Гаҗәп! Агач сөйләшкәнне беренче мәртәбә күрәм.

Мырау. Син кем? Әй, сорап торам тагы. Син агач бит инде.

Һауһауҗан. Безнең күз алдында үсте. Бер тапкыр да сөйләшкәне булмады. Ә бүген сөйләшә. Гаҗәп!

Мырау. Гаҗәп кенә түгел бу — могҗиза! Гап-гади агач булып агач сөйләшсен инде...

Тылсымлы агач. Мин гади агач түгел, беләсегез килсә... Мин — Тылсымлы агач!

Һауһауҗан. Тылсымлы?

Тылсымлы агач. Әйе, Тылсымлы агач.

Мырау. Алай бик тылсымлы да булгач, әйт әле безгә: кем безне мондый хәлгә төшерде?

Һауһауҗан. Әйе, әйт безгә: өтек кенә тычканнар ни сәбәпле безне мәсхәрә итте?

Тылсымлы агач. Тычканнар түгел, сез — үз-үзегезне көлкегә калдырдыгыз.

Мырау. Ничек инде — без?

Тылсымлы агач. Шулай. Бик гади. Әгәр сез үтә ялкау булмасагыз, укый-яза белсәгез, мондый хәлгә тармый идегез. Син *(Мырауга карап әйтә)* тычканнардан дер калтырап тормас идең. Ә син *(Һауһауҗанга карый)* тәкә төсле бәэлдәп ятмас идең...

Мырау. Беренчедән, мин ялкау түгел. Икенчедән, әгәр мин син уйлаганча ялкау икән, аннан кемгә зыян?

Һауһауҗан. Әйе, безнең укый-яза белмәвебездән кемгә зыян?

Тылсымлы агач. Үзегезгә!

Мырау. Ничек инде «үзебезгә»?

Тылсымлы агач. Соң... башыгызны эшләтеп карагыз инде бераз. Кемнәр ята соң монда пошаманга төшеп? Сез түгелмени?

Мырау. Без булсаный! Анда синең ни эшең бар?

Һауһауҗан. Ятасыбыз килде дә... Шулай ятабыз әле менә. Вәйт!

Тылсымлы агач. И-и, рәхәттер инде сезгә, алайса?

Һауһауҗан. Әйе, бик рәхәт. Шундый рәхәт инде менә! Чыдаплар булмый рәхәтлеккә. Әйеме, Мырау?

Мырау. Әй-йе... Һай, билем!

Тылсымлы агач. Алай бик күңелле булгач, ятыгыз инде, алайса. Әллә ярдәм итим микән үзегезгә, дигән идем. Күрәм, сез ярдәм-фәләнгә мохтаҗ түгел икәнсез...

Һауһауҗан. Синме безгә ярдәм итмәкче? Кит әле, көлдереп үтерәсең бит.

Тылсымлы агач. Ярый, алайса, бигайбә! Үзегезгә карагыз инде. Әнә, тычканнар да кайтып килә... Юк ла, ялгыш әйттем... Мәчеләр кайтып килә икән... Чәпәләй белән Тәпәләй...

Мырау. Чәпәләй белән Тәпәләй? Һай, нишләргә? Хәзер ашыйлар бит инде алар мине...

Тылсымлы агач. Мин әйттем!

Тылсымлы агач әүвәлге халәтенә кайтып катып кала. Чәпәләй белән Тәпәләй вилсәпид сөйрәп кайтып керә. Икесенең дә башлары, куллары бинтка чорналган.

Чәпәләй. Вилсәпид түгел бу — җенсәпид! Шушы калтырша аркасында чүт башсыз калмадым.

Тәпәләй. Синең баш нәрсә ул, менә мин кулсыз кала яздым.

Вилсәпидне төртеп җибәрәләр. Вилсәпид коймага барып сылана.

Чәпәләй. Тәки инвалид кала яздык, име, Тәпәләй?

Тәпәләй. Ие... Үзең бит, йөртә белмисең...

Чәпәләй. Ә син утырып йөри белмисең...

Тәпәләй. Вилсәпид йөртә белгән мәче күпер астына мәтәлә димени? Кит, җүләр... Ярый әле, Айболит бабай өендә булды... Ул булмаса, эшләр хөрти иде безнең... Минем кул һаман да сызлый әле...

Чәпәләй. Карале, боларның тавыш-тыннары юк. Үлмәгәннәрдер бит?

Икәүләшеп Мырау янына киләләр.

Тәпәләй. Сәлам, мерсимадам!

Мырау дәшми. Боларга карап, куркып тора.

Чәпәләй. Әллә телен йоткан инде?

Тәпәләй. Телен йоткан булса, бик начар бит әле бу! Мин тычкан теле ашарга бик ярата идем... Эм-м-м... *(иреннәрен ялмаштырып ала).*

Чәпәләй *(Һауһауҗанга ишарәләп).* Борчылма. Әнә, тәкә телен ашарсың. Мөгаен, ул йотмагандыр.

Тәпәләй. Дөрес әйтәсең, тычкан теле булмаган чакта миңа тәкә теле дә ярап тора!

Чәпәләй. Ашыйсы килә-ә-ә... Ләкин кызганыч: өч сәгатьсез бернинди ризык та кабарга ярамый безгә.

Тәпәләй. Әйе шул. Айболит бабай шулай диде бит әле. Тешләрегез урыныннан чыгуы мөмкин, диде шул. Барысы да шул синең аркада. Әгәр күпердән очмаган булсак...

Чәпәләй. Мырау белән Һауһауҗанны ашыйм дип, авызны чалшайтып булмый инде, малай, име?

Тәпәләй. Ие, түзәргә туры килә.

Чәпәләй. Тәпәләй, кара әле, бавы бушамаганмы Мырауның? Авызга керде дигәндә генә, кача күрмәсен берүк!

Тәпәләй. Качып кына карасын! Әй, Мырау, ник дәшмисең? Сөйләшеп кал мәче абзаңнар белән.

Мырау. Сез мәче түгел. Мин — мәче.

Тәпәләй. Миңа димәгәе. Хет юлбарыс бул! Барыбер ашыйм мин сине. Чәпәләй, әллә тоз сибикме моңа. Бик эссе бит көн. Бозылуы бар.

Чәпәләй. Кирәкми. Мин тозлы ит яратмыйм.

Тәпәләй. Анысы шулай шулаен, мин дә тозлы ит яратмыйм. Шул... әрәм була күрмәсен дип кенә әйтүем.

Чәпәләй. Бозылса, ник борчыласың... Әле бит безнең запаска тәкә бар... Әйе бит, Һауһауҗан?!

Һауһауҗан. Күрсәтермен мин сезгә запасны! Орынып кына карагыз.

Тәпәләй. Кагылмыйбыз без сиңа. Юк-барга көч әрәм итәргә без җүләр түгел лә. Бер-ике сәгатьтән син бит хәзер үзең кәңкәясең. Чөнки ач бит син... Ә без сиңа барыбер ашарга бирмибез. Вәйт!

Чәпәләй. Тәпәләй, өйгә кереп бераз ял итеп алыйк. Боларга карагач, гел ашыйсы килеп тора... Үзең беләсең, безгә әлегә ашарга ярамый.

Тәпәләй. Ял итик соң, алайса. Минем йокы сәгатем дә җитте. Режим бит, малай!

Чәпәләй. Пока, тычкан әфәнде!

Тәпәләй. Әйе, пока, мерсимадам!

Мырау. Паш-шул!

Тәпәләй. «Пашшул» итәм бит хәзер. Хи-а! *(Каратэ күрсәтәм дип, үзе мәтәлә.)*

Һауһауҗан *(эчен тотып көлә).* Бә-хә-хә-хәә!.. Хә-хә-хә!..

Чәпәләй. Егылган мәчедән көлмиләр! Шуны бел, аңгыра тәкә!

Һауһауҗан шым була.

Тәпәләй *(торып баса).* Көлдерәм мин аны хәзер! *(Тагын каратэ күрсәтмәкче була.)* Хи-а! *(Тагын мәтәлә.)* Тфү! Кул эшләмәгәч, аяк та эшләми!

Чәпәләй. Булды, киттек! Җә башыңны ярырсың...

Тәпәләй. Ух, мин сезне! *(Тегеләргә аягын селки.)*

Өй бүрәнәсендәге зур тишектән эчкә кереп китәләр.

Мырау. Уф, тәмам гарык булдым болардан!

Һауһауҗан. Мин дә туйдым кыланмышларыннан.

Мырау. Ичмасам, бауны да чишеп булмый.

Һауһауҗан. Бу агач дөрес әйтте сиңа. Ялкау булмасаң, мондый хәлгә тармый идең син.

Мырау. Ә үзең? Ә үзең? Үзеңне бел, яме!

Һауһауҗан. Ә мин нәрсә? Мин барыбер көне-төне чылбырда. Ялкауланмас җиреңнән ялкауланырсың...

Мырау. Стоп! Мин белдем, белдем! Башыма барып җитте, ниһаять! Безне бит шушы агач акылга утыртырга уйлаган...

Һауһауҗан. Ничек инде?

Мырау. Ничек инде, ничек инде, ничекнең колагы тишек инде! Шулай. Бик гади бу. Ул безнең ялкауланып ятуыбызны күргән, туйган. Әфсен-төфсенләгән дә мине — куркакка, сине тәкә җанлыга әйләндергән.

Һауһауҗан. Ә... тычканнарны батыр иткәнме?

Мырау. Нәкъ шулай. Тәк шту, безне бу бәладан коткарса, менә шушы агач кына коткара ала.

Һауһауҗан. Баягынак без зерә алай ямьсез кыландык.

Мырау. Үзең бит, «Чыдаплар булмый рәхәтлеккә!» дип шапырынган, мактанган булдың...

Һауһауҗан. Ә син... Ә син...

Мырау. Ә мин... менә монда ятам. Кое янында. Тычканнарга әсир төшкән фил шикелле.

Һауһауҗан. Синме фил? Синме фил? Тфү, мәче ыстырамы!

Мырау. Ә син — мөгезсез тәкә!

Һауһауҗан. Ачуны китермә минем! Юкса тычканнарны чакырам!

Мырау. Тс-сс! Ишетмәсеннәр тагы! Иң яхшысы, безгә хәзер агачтан сорарга кирәк: алсын ул бездән сихерен!

Һауһауҗан. Әйе шул. Ник бая ук минем башыма килмәде бу?

Мырау. Башың бармыни соң синең! Баш урынында буш чүлмәк бит синең!

Һауһауҗан. Җә, җә, сүзеңне үлчәп сөйлә, яме! Матри! *(Агачка дәшә.)* Әй агач! Көлмәсен миннән тычканнар! Ишетәсеңме? Кайтар мине элекке халәтемә!

Мырау. Мине кабат батыр мәче ит! Агач! Сиңа әйтәм!

Һауһауҗан. Безне түгел, мактанчык тычканнарны акылга утырт син!

Мырау. Әйе, ул шантырапаларны мәсхәрә ит!

Тылсымлы агач дәшми. Һауһауҗан тезләнеп ялвара.

Һауһауҗан. Агач абзыкаем! Агач түтикәем! Тагын кем дип әйтим инде сиңа? Господинкаем!..

Мырау *(ул да ялвара).* Әфәндекәем! Ханымкаем!..

Һауһауҗан. Хуҗакаем! Хуҗабикәем!

Мырау. Мистер агачкаем! Синориттекаем!

Һауһауҗан. Иң тәмле сөяккәем!

Мырау. Кит әле, Һауһауҗан, агачка шулай дип әйтәләрмени? Татлы каймаккаем! Сөткәем!

Һауһауҗан. Нишләп сөт булсын ул, тиле!

Мырау. Сөяк тә түгел инде!

Тылсымлы агач һаман дәшми. Күрәсең, аның сөйләшергә исәбе дә юк.

Һауһауҗан. Беләсеңме, Мырау, агач сиңа үпкәләгән.

Мырау. Нишләп миңа? Бәлки, сиңа үпкәләгәндер?

Һауһауҗан. Миңа үпкәли алмый ул. Чөнки мин аңа якынрак ятам.

Мырау *(кинәт сискәнә).* Чү! Кемдер килә бугай! Ишетәсеңме җыр тавышы?

Ерактан җыр тавышы ишетелә:

Гыйлем эстәп, киткән идем,<br>
Ерак-ерак илләргә...

Дөнья гизеп кайтып киләм
Туган-үскән җирләргә!

Җыр якыная, көчәя:

Мин — Мыргали, Мыргали...
Бик бай җырга-моңга мин!..

Мырау. Мыргали?! Ишеттеңме, Һауһау, Мыргали кайта! Күрше кайта! Белем алып кайта! Ур-р-ра!

Һауһауҗан. Ишетмәскә, Чәпәләйләр кебек саңгырау түгел лә мин!

Мыргали керә. Күзлекле. Шәһәрчә киенгән. Мырау белән Һауһауҗанны күрми әле.

Мыргали *(һаман җырлый)*.

Һич сагынмас кебек идем,
Өйдән чыгып киткәндә...
Сагындырган авылкаем,
Сагындырган икән лә!..

Мырау *(шатланып кычкыра)*. Мыргали!

Һауһауҗан. Сәлам, күрше!

Мыргали, сискәнеп, җырлавыннан туктый. Әле Мырауга, әле Һауһауҗанга карый.

Мыргали. Мырау? Һауһауҗан?

Мырау янына килә.

Мыргали. Нишләп ятасың син монда, Мырау? Кем бәйләде сине?

Мырау *(үз хәленнән уңайсызланып)*. Мин... Без... Мин...

Мыргали. Нәрсә, әллә Һауһауҗан бәйләдеме? Ә, Мырау?

Мырау. Мин... Һауһауҗан... э-э-э...

Һауһауҗан. Юк, Мыргали күрше, минем эш түгел. Күрмисеңмени, мин үзем дә чылбырда ич! *(Чылбырын чыңлатып ала.)*

Мыргали. Алайса, кем бәйләде соң Мырауны? *(Бауны чишмәкче була.)* Әл-лл-әл-ә-л... Моны бит чияләй бәйләгәннәр!..

Һауһауҗан. Әйтергә дә оят инде, Мыргали күрше, Чәпәләй белән Тәпәләй бәйләде аны...

Мыргали. Чәпәләй белән Тәпәләй?

Мырау. Мин... Без... Әйе шул... алар... әйтергә дә оят инде...

Мыргали. Ышанмыйм! Мондый хәлнең булуы мөмкин түгел.

Ниһаять, ул бауны чишә. Мырау кулларын угалый. Шулвакыт Чәпәләй белән Тәпәләй бер-бер артлы килеп чыгалар.

Чәпәләй. Бик мөмкин, Мыргалый! Озын муенын боргалый!

Тәпәләй. Хенде хох, Мыргалый! Руки вверх!

Мырау кое артына кача. Мыргали әле аңа, әле тычканнарга гаҗәпләнеп карый.

Мыргали. Син кемнән курыктың, Мырау? Болардан түгелдер бит?

Чәпәләй. Бирәм дигән колына, чыгарып куяр юлына! Тәпәләй, менә тагын безгә бер ыфтарай!

Тәпәләй. Әйе шул, бәрәңге боткасы өстенә бик шәп ыфтарай бу!

Мыргали *(тычканнарга таба атлый).* Күрсәтәм мин сезгә хәзер ыфтарайны, тел бистәләре!

Чәпәләй белән Тәпәләй үзләре дә сизмәстән артка таба чигенеп куялар.

Чәпәләй. Кара, кара, Тәпәләй, бу малакасус бездән курыкмаган була түгелме соң?

Тәпәләй. Стуй, малакасус! Кемгә әйтәләр?!

Мыргали. Әле сез мине мыскыл итәсезме? *(Өсләренә килә.)* Аздыргансың син боларны, Мырау! Аздыргансың!

Чәпәләй белән Тәпәләй, бер-берсенә елышып, җәһәтрәк артка чигенәләр.

Тәпәләй. Чәпәләй, минем ыфтарай ашыйсы килми башлады... Мин первыйга гына да риза...

Чәпәләй дәшми.

Мыргали. Нәрсә, первыйга Мырау белән Һауһауҗан иде мәллә? Хәзер мин үзем сездән первый ясыйм!

Тәпәләй. Минем тамак тук икән, Чәпәләй. Ә синең?

Чәпәләй. Минем дә эпититне җибәрде әле бу тычкан сыңары...

Мыргали. Кем тычкан? Минме? Аһ, җүнсезләр! *(Каударланып куа башлый. Тегеләр ишегалды буйлап качып йөриләр.)*

Мырау. Бир кирәкләрен, Мыргали!

Һауһауҗан. Шул кирәк ул мактанчыкларга!

Мырау *(үзе дә сизмәстән кое өстенә менеп баса да, куркуыннан янә кире төшә).* Напасаран!

Һауһауҗан. Рот-фронт!

Мырау. Вива, Куба!

Мыргали тычканнарны һаман куып йөри. Тегеләр тоттырмый. Менә бермәлне тычканнар икесе ике якка баса. Мыргали кайсын тотарга белмичә тора.

Тәпәләй. Мине түгел, Чәпәләйне тот! Мин тәмсез! Мин бүген иртән битне дә юмаган идем!

Чәпәләй. Юк, юк, Тәпәләйне тот! Мин өч көн юынмаган инде!

Тәпәләй. Ә мин — бер атна!

Мырау *(кул хәрәкәте белән күрсәтеп).* Икесен дә берьюлы тот, Мыргали! Менә болай иттереп!

Чәпәләй. Хәзер иттерәм мин сиңа, яме, Мырау!

Мырау *(урынында очынып).* Кара, кара! Кемгә кычкырган була!.. Мыргали генә тотсын, иманыгызны укытам мин сезнең! Тот шуларны, Мыргали, вакытны сузма!

Һауһауҗан. Давай-давай, Мыргали!

Мыргали тагын куа башлый. Тегеләр бер-бер артлы өй тишегенә кереп югалалар.

Мырау *(кулларын селкеп уфтана).* Их, качырдың бит шуларны, Мыргали! Синең урында үзем генә булган булсам!

Мыргали. Булырга иде. Ник курыктың соң?

Мырау. Ни бит... Ботинка бавы сүтелгән иде бит!.. Шуны бәйләп азапландым...

Мыргали. Алдашма инде, ичмасам, Мырау!

Өй тишегеннән Тәпәләйнең башы күренә.

Тәпәләй. Хәзер без сиңа букыс күрсәтәбез. *(Кулы белән үз башына суккалагандай итә. Ялгыш башын бәрә.)* Ай!

Мырау *(йодрыгын күрсәтә)*. У-у, мин сезне!

Мыргали. Азындыргансың син боларны, Мырау, азындыргансың!

Һауһауҗан. Көне-төне телевизор карады инде Мырау.

Мырау. Ә син көне-төне йокладың.

Мыргали. Йә, йә, әрепләшмәгез! Моннан соң сабак булыр бу сезгә!

Мырау. Ә мин барыбер нигәдер куркам. Оят, шул тычканнардан куркам бит.

Һауһауҗан. Бә-ә-ә... Ә мин бүген өрүемне оныттым. Тәкә шикелле гел менә шулай бәэлдим... Бә-ә-ә...

Мыргали. Мин юкта нәрсә булды соң сезгә? Ә?

Мырау. Безне... безне... менә бу агач сихерләде. Шул мине куркакка әйләндерүче!

Һауһауҗан. Ә мине — бәэлдәтүче!

Мыргали Тылсымлы агач янына килә. Өй тишегенә карый-карый, курка-курка гына Мырау да агач янына килеп баса. Һауһауҗан агачка карап тора.

Мыргали. Яфракларга нининдидер сүзләр язылган...

Өй тишегеннән бокс бияләйләре кигән Чәпәләй белән Тәпәләй, шыпырт кына чыгып, әкрен генә боларга таба киләләр. Тегеләр аларны күрмиләр.

Мырау. Тылсымлы агач бу! Яфракларга берәр сихерле сүзләр язылгандыр әле. Кызганыч, мин укый белмим...

Һауһауҗан. Жәл, мин дә укый алмыйм...

Мырау. Мыргали, син бит укый беләсеңдер?! Укып күрсәт безгә! Сихерен бездән кире алсын Тылсымлы агач!

Мыргали *(иҗекләп, акрын гына укый)*.

Рәгә ңаслуб ряөсшэ
Рәгә ңаслуб елмелеб
Кәриз мәһ шырыт ңаслуб
Әглəх йыдном ңыссамрат.

Чәпәләй белән Тәпәләй тукталып кала. Тыңлыйлар.

Мыргали *(укуын дәвам итә)*.

Мондагы яфракларга
Язылгандыр шул хакта:
Аңларсың бу сүзләрне
Укысаң кире яктан...

Мырау. Мыргали, укы инде тизрәк кире яктан!

Һауһауҗан. Әйе, укы инде тизрәк, Мыргали!

Мыргали. Ашыкмагыз, хәзер укыйм...

Эшсөяр булсаң әгәр,
Белемле булсаң әгәр,
Булсаң тырыш һәм зирәк —
Тармассың мондый хәлгә!

Шулвакыт беренче күренештәге сихри-моңлы көй яңгырап ала. Чәпәләй белән Тәпәләй артларына чигенә башлыйлар.Мырауга кыюлык иңә. Һауһауҗан өреп җибәрә.

Һауһауҗан. Һау-һау!

Чәпәләй. Һай!

Тәпәләй. Беттек!

Мырау, Мыргали, Һауһауҗан аларга борылып карый.Мырау кинәт аларга ыргыла. Чәпәләй белән Тәпәләй бокс бияләйләрен ташлап качалар.

Мырау. Мия-яу!

Чәпәләй. Караул!

Тәпәләй. Коткарыгыз, үтерәләр!

Һауһауҗан. Һау-һау!

Чәпәләй өй ишегенә керергә азаплана. Аның артыннан Тәпәләй төрткәли.

Тәпәләй. Шнель, шнель! Чәпәләй, тизрәк!

Кереп качалар.

Һауһауҗан. Һау-һау. Рәхмәт, Мыргали!

Мырау. Ми-яу! Рәхмәт сиңа, Мыргали! Мыргали, рәхмәт сиңа! Тылсымлы агач, сиңа да рәхмәт!

Тылсымлы агач, ишеткәнен белдереп, җилфердәп ала да тынып кала. Яфраклардагы сүзләр юкка чыга. Ут сүнә. Сәхнә алдында Әкиятче пәйда була.

Әкиятче. Әче икән тормагыз...

Баллы икән алмалар!
Әкиятем шушында
Тәмам булды, балалар!
Тыңлаучысы сез булса,
Сөйләүчесе — мин әле...
Әкиятләрем — бер капчык,
Тагын сөйләрмен әле!
Ә хәзергә... хәзергә
Барасым бар Шәлегә —
Сау булыгыз әлегә!

Тәмам.

# АҢГЫРА САРЫК ҖҮЛӘРЕ

*(Әкият-пьеса)*

КАТНАШАЛАР:
Бәрән
Кәҗәмил
Куянша
Бүретдин
Төлкиназ
Аюулла

## БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

Урман аланы. Уң якта, түр почмакта җыйнак кына өйнең ишекле-тәрәзәле ягы күренә. Ишек өстенә «Куянша» дип язылган такта беркетелгән. Өйнең сул тарафындагы ике агачка челтәрле ятак тарттырылган. Янә бер читтә ике агач үсә — аларга аркылы такта сугылган: ул капка ролен үти. Өй баскычының бер як кырыенда селкенмәле бүре карачкысы тора.

Кинәт «Тукта, Кылыйша! Иманыңны укытам бит хәзер!» дип кычкырган тавыш ишетелә. Җан-фәрман чабып, «капка»дан Куянша килеп керә дә ишеккә таба ыргыла. Баскыч төбендә тукталып, бүре карачкысының

корсагына йодрыгы белән тондырып ала һәм, ишекне җәһәт кенә ачып, өй эченә кереп югала. Капкада Бүретдин күренә. Ул капкадагы аркылы тактаны абайламыйча башын шуңа бәрә.

Бүретдин *(авыртудан үкереп җибәрә).* У-у-у-а-ах!.. *(Башын тотып, капка баганалары тирәли әйләнеп йөри.)* У-у-у... Башым ярылды!..

Өй тәрәзәсе ачыла, аннан Куяншаның башы күренә.

Куянша *(үчекләп такмаклый).*

Тараканнар төште мәллә
Ачыган ашларыңа? —
Калай тәлинкә киеп йөр
Миңгерәү башларыңа!

Бүретдин. У-у-ух! Кылый күз, имгәк ясыйм мин синнән хәзер!

Ул җәһәт-җәһәт кенә тәрәзәгә якынлаша. Куянша тиз генә тәрәзәне ябып, эчтән бикләп куя да, телен чыгарып, Бүретдинне үчекли.

Бүретдин. Чык хәзер үк! Чык, дим, яхшы чакта! Тәрәзәңне он-талкан итәм! Йөрерсең аннары урман бетереп, пыяла эзләп!..

Куянша. Орынып кына кара тәрәзәгә! Мин сине әтигә әйтәм! Ул синең колакларыңны борып өзәчәк! Белдеңме?!

Бүретдин. У-у-у... куркытты берәү. Котым ботыма төште менә... Чык, дим, хәзер үк!

Куянша. Чыкмый гына тор әле! Йә, чыккан, диярләр...

Бүретдин. Беләсеңме, Кылыйша, мин сине нишләтәм? Мин сине... мин сине... Йотам мин сине! Чәйнәп тә интекмим! Кабам да йотам! Ятарсың аннары минем корсак эчендә — акырып-бакырып, үкереп-җылап... Әмма соң булыр.

Ишек янына килеп, аны тартып карый. Ишек бикле — ачылмый.

Куянша. Кагылма ишеккә! Ватсаң, үзең ясап бирәсеңне онытма!

Бүретдин. Ватты ди! Бик кирәге барые ишегеңнең! Хәзер үзең үк «чыгар әле, Бүретдин абзыкаем!» дип ялыначаксың...

Бүретдин өй тирәсеннән агач табып ала да шуның белән ишекне терәтеп куя.

Куянша *(тавышы өй эченнән ишетелә).* Нишлисең син, Бүретдин?

Бүретдин. Тире иләп, күн эшлим! Сизмисең мәллә, ишегеңә терәү куйдым бит. Хәзер давыл чакырып өегезне очыртып җибәрәм. Йөри бир күктә очып!

Куянша. Сиңамы соң давыл чакырту! Мактанчык! Билләһи-валлаһи, әти сиңа күрмәгәнеңне күрсәтәчәк икән!

Бүретдин. Җитте, Кылыйша, такылдама. Туйдым яшелле-зәңгәрле тавышыңнан...

Бүретдин баскычка җайлап утыра. Кинәт ерактан кемнеңдер җырлавы ишетелә. Бүретдин сагая. Җыр тавышы якынайганнан-якыная:

Урманга керим әле,
Урманда йөрим әле.
Бүре-мазар очратып,
Кирәген бирим әле...

Куянша *(тәрәзәдән башын чыгарып).* Ишеттеңме, Бүретдин? Кемдер синең иманыңны укытырга килә. Бар, тизрәк качып өлгер!

Бүретдин. Һәйт! Ал башыңны! Акыл өйрәтмә абзаңа!

Капка төбендә Бәрән пәйда була. Куянша тәрәзәдән башын тартып ала. Бүретдин, Бәрәнне күрүгә, баскычка таба иелә төшә. Бәрән аны күрми, җырлавын дәвам итә-итә, капкадан уза.

Бәрән. Аюдан да курыкмыйм,

Бүредән дә курыкмыйм...
Мин — Бәрән, батыр бәрән —
Бернидән дә курыкмыйм!..

Бүретдин *(урынынан калкынып).* Тәк-тәк-тәк... Миннән дә курыкмыйсыңмы?

Бәрән, Бүретдинне күреп, туктап кала.

Куянша *(тәрәзәдән янә башын чыгара).* Синнән дә курыкмыйм дип җырлады бит инде... Саңгырау мәллә син?

Бүретдин *(Куяншага усал караш ташлап кычкыра).* Яп авызыңны, Кылыйша! *(Йодрыгын селки.)* Кишер кимерә торган тешләреңне коеп төшерәм хәзер! *(Бәрәнгә.)* Тәк-тәк-тәк... Миннән... Бүретдин абзаңнан курыкмыйм дисең инде, ә?!

Бүретдин Бәрәнгә таба якынлаша. Бәрән куркуыннан бераз артка чигенә дә кинәт, капылт туктап кала.

Бәрән *(катгый итеп).* Әйе, курыкмыйм! Аюдан да курыкмыйм, арысланнан да. Беркемнән дә курыкмыйм!

Куянша. Маладис! Нәкъ минем кебек икәнсең! Мин дә курыкмыйм бу тәредән!

Бүретдин. Чурту матыр! Туктыйсыңмы-юкмы син, Куркак батыр? Авызыңны чалшайтам бит!

Куянша *(үчекләп).* Чалшайтканың барыемы соң?..

Бүретдин *(Бәрән тирәли әйләнеп чыга).* Тәк-тәк-тәк... Сосиски кебек кенә гәүдәң белән миннән курыкмаган буласың инде, алайса...

Бәрән. Курыкмыйм дип әйттем бит инде мин сиңа!

Бүретдин. Тәк-тәк-тәк... *(Кинәт, Бәрәнне куркытырга теләп, кычкырып куя.)* Ам!

Бәрән исе дә китмичә басып торуын белә.

Куянша *(кычкырып җибәрә).* Уф, көлеп үләм! Уф, эчем катты!

Бүретдин *(Бәрәнгә, ярсып).* Ник курыкмыйсың? Курык! Син куркырга тиеш!

Бәрән бер сүз дә дәшми басып тора.

Куянша. Акырма ул кадәр! Бугазыңны җыртасың бит! Күреп торасың ич, керфеге дә селкенмәде... Маладис, Бәрән! Минем кебек бул, бирешмә Бүретдингә!

Бүретдин *(Бәрәнгә).* Син... Син... Нишләп курыкмыйсың миннән? Йә, әйт, нишләп курыкмыйсың?

Куянша. Сорау алган буласың... Син нәрсә, Бүретдин, пыркурыр мәллә? Курыкмагач курыкмый инде...

Бүретдин. Телеңне йоттың мәллә? Сорауга җавап бир: нишләп миннән курыкмыйсың?

Бәрән. Мин — аңгыра бәрән чөнки! Шуңа курыкмыйм синнән.

Бүретдин. Сарыклар гомер-гомергә аңгыра инде алар...

Бәрән. Ә мин аңгыра гына түгел. Мин — аңгыра сарык җүләре!

Бүретдин. Миңа димәгәе, шыр тиле бул! Әм-ма син миннән куркырга тиеш! Ә мин сине ашарга тиеш!

Бәрән. Менә кызык! Аңгыра сарык җүләре дә булыйм, синнән куркып та торыйм... Юк инде, Бүретдин бәгырькәем, монысы булмас!

Бүретдин, куллары белән башын тотып, арлы-бирле йөренә.

Бүретдин. Ярар... Курыкмасаң курыкма, кадалып кит! Әмма мин сине хәзер ботарлап ашыйм.

Бәрән. Ашый алмыйсың, быр-рат!

Бүретдин *(кабынып)*. Минме?! Мин сине ашый алмыйммы? Сине чәйнәп йотмасам, исемем Бүретдин булмасын!

Куянша *(такмаклый)*.

Бүретдин, Бүретдин,
Әгәр ашый алмасаң,
Исемең булыр Шүретдин!..

Бәрән *(Бүретдингә)*. Ашый алмыйсың! Чөнки мин — аңгыра сарык җүләре! Әгәр мине ашасаң, үзең дә җүләргә әйләнәчәксең...

Куянша. Ишеттеңме, аңгыра бүре тилесе! Болай да ыспырафкысыз җүләр идең... Тагын да җүләррәк чагыңны күрәселәр бар икән әле...

Бүретдин *(Куяншага)*. Җиттеме сиңа, юкмы? Хәзер күрсәтәм мин сиңа ыспырафкысыз җүләрнең кем икәнен!

Куянша. Кишер чәчсәм, кишер үсми,
Ташмы әллә җирегез?
Җүләрләнгән Бүретдингә
Ыспырафкы бирегез!
Их-ма!

Бәрән кычкырып көлә.

Бүретдин. Ник көләсең, ахмак?

Бәрән. Ахмак булганга көләм.

Бүретдин. Беренче тапкыр күрәм мондый шыр тилене!

Куянша. Ә минем инде икенче тапкыр күрүем. Беренчесе син идең, Бүретдин...

Бәрән. Көлегез, әйдә, көлегез... Миңа барыбер. *(Авызын зур итеп ачып исни, киерелә.)* Минем йоклыйсы-ы-ым килә-ә-ә... *(Тирә-юньгә карана, челтәрле ятакны күреп ала.)* Ятып ял итәргә урын да бар икән...

Бәрән ятакка таба бара.

Бүретдин *(Бәрәнгә кычкыра)*. Ятмыйсың! Тукта хәзер үк!

Куянша. Яткырма аны, Бүретдин. Минем ятак ул! Хәзер үзем чыгып ятам.

Бәрән. Кычкырмагыз әле шулхәтле! Колакларымны тондырып бетердегез тәмам.

Бәрән ятакка ятмакчы була, Бүретдин аның беләгәненнән эләктереп ала.

Бүретдин. Ятмыйсың дип әйттеләр бит сиңа, тинтәк! Хәзер син качарга тиеш. Ә мин сине куарга тиеш. Куып тоткач... *(авызын чапылдатып ала)* тәмләп ашарга тиеш... Кача башла тизрәк! Мин эшләп ашарга яратам!

Бәрән. Мин — аң-гы-ра! Ишетәсезме, аң-гы-ра! Шуңа күрә, качарга уйламыйм да. Алай бик качышлы-куышлы уйныйсың килсә, әнә, куянны ку!

Куянша. Кара-кара-кара... Бүретдин абзасын өйрәтеп маташкан була, хәчтерүш! Нишләргә икәнен Бүретдин үзе бик шәп белә ул. Шулай бит, Бүретдин?!.

Бүретдин. Ялагайланма, Кылыйша.

Бәрән *(үз алдында сөйләнгәндәй)*. Ашыйсы да килә-ә-ә... Иртәдән бирле җүнле ризык капкан юк...

Бүретдин. Нинди ашау ди ул! Барыбер минем авызга керәсе ич инде сиңа. Әйдә, сузма вакытны, кача башла!

Бәрән. «Кача башла! Кача башла!..» Туйдырып бетердең инде шул сүзләрең белән. Синнән котылып булмас, ахры... Әйдә болай итәбез, Шүретдин...

Бүретдин. Шүретдин түгел мин, Бү-рет-дин! Аңладыңмы, миңгерәү?

Бәрән *(кыланчыкланып).* Аһ, мин аңгыраны гафу ит, Бүретдин...

Бүретдин. Ярар, бер юлга гафу итәм. Тагын бер мәртәбә Шүретдин дип әйтсәң — үзеңә үпкәлә. Аңладыңмы?

Куянша. Аңлады инде, аңлады. Ахмак, дигәч тә. Ул түгел, мин аңладым, Шүретдин...

Бүретдин. Ә син кысылма, такмакчы! *(Бәрәнгә.)* Йә, аңладыңмы, малакасус?

Бәрән. Аңладым, аңладым. Бүтән Шүретдин дип әйтмим сиңа, Шүретдин...

Бүретдин. Нәрсә дидең?

Бәрән. Аһ!.. Тагын гафу ит мине, Бүретдин...

Бүретдин *(йомшый төшеп).* Ярар. Бер юлга тагы гафу итәм. Әгәр бүтән әйтсәң... Матри!

Куянша. Бүре түгел икәнсең, Бүретдин... Мәмкә икәнсең... Һаман шушы ахмакны ашый алмыйсың. Синең урында мин булса-а-ам... Бу ахмак урынында кишер булса-а...

Бүретдин *(Бәрәнгә).* Йә, качасыңмы инде, юкмы, канса канис? Ачлыктан эчемдә бүреләр улый башлады...

Бәрән. Бүреләр? Нинди бүреләр ул тагы?

Бүретдин. Әй лә... Ялгыш әйттем. «Эчемдә сарыклар акыра башлады» димәкче идем... Әйдә, кача башла!

Куянша. Кач инде җәтрәк! Бүретдин абзаң сиңа әйтә бит.

Бәрән. Болай итик без, Бүретдин: башта син кач — мин куам. Аннары мин куармын — син качарсың... Әгәр тотсаң, ашарсың... Йә, килештекме?

Куянша *(уйлап-нитеп тормыйча).* Килеш инде, Бүретдин, килеш. Бу җүләр барыбер син әйткәнне тыңламаячак.

Бүретдин *(Бәрәнгә).* Ярар, синеңчә булсын. Никадәр тизрәк — шулкадәр яхшырак. Әйдә, куа башла!

Бүретдин йөгереп китә, Бәрән аның артыннан куа.

Куянша. Тоттырма, Бүретдин! Куып тот, Бәрән! Иманын укыт Бүретдиннең! Бүретдин! Тота бит инде сине, кызула! Дүр-рәк!

Капкада Төлкиназ күренә. Бәрән белән Бүретдин бер-бер артлы аңа бәрелеп чыгып чаба. Төлкиназ мәтәлеп кала.

Төлкиназ *(җирдә утырган килеш. Тегеләр чыгып киткән якка карап, күзләрен куллары белән уып ала-ала).* Әстәгыфирулла! Әллә күзләремә генә күренде инде... Алай дисәң, мине төртеп ектылар бит. Га-җә-әп... Бүрене Бәрән куа...

Куянша. Нинди гаҗәп булсын инде — факыт! Бәрән Бүретдинне куа, Бүретдин Бәрәннән кача... Искиткеч тамаша!

Төлкиназ *(урыныннан торып басып).* Нәрсә, әллә Бүретдин тилебәрән орлыгы ашаганмы? Гомердә булмаган хәл бит бу! Хәчтерүш бәрәннән куркып качсын инде...

Куянша *(тәрәзәдән тышка сикереп төшә).* Әле монда теге тинтәк... Бәрәнне әйтәм... мактанып торды. «Бүрене тотып ашагач, төлкенең арт сабагын укытам!» — диде. Ие!

Төлкиназ. Юкны сөйләмә! Булмаганны! Мин аның үзенең арт сабагын укытам. Син мине яхшы беләсең. Шулай бит, Чалыш күз?

Куянша. Шулаен шулай да, Юеш танау... Бүретдин дә башта синең кебек уйлаган иде. Әнә, үзең күрдең бит... Факыт!

Төлкиназ. Бүретдин — Бүретдин ул, ә мин — мин! Хәйләкәр төлке, диләр мине! *(Җырлый.)*

Хәйләкәр минем әти,
Хәйләкәр минем бабам.
Кирәк булса әгәр дә,
Хәзер мең хәйлә табам.

Хәйләлимен, алдалыйм —
Алдалыйм дип алдамыйм...

Куянша *(җырлый).*

Тиле түгел икәнне
Беләсеңдер ич минем:
Синең тозак-хәйләңә
Мин барыбер төшмимен...
Алдала син, хәйләлә,
Ләкин миңа бәйләнмә!..

Син шуны исеңдә тот, Төлкиназ: син — хәйләкәр булсаң, бәрән — аңгыра. Үзең беләсең, аңгыраны бер нинди хәйлә белән дә җиңеп булмый. Өстәвенә, бу бәрән — аңгыраның да аңгырасы, тиленең дә тилесе, җүләрнең дә җүләре, исәрнең дә исәре, сантыйның да сантые, миңгерәүнең дә миңгерәве, дивананың да диванасы, дүррәкнең дә дүрәге!.. Кыскасы, ишәктән дә хужы! Әле миңа да бәйләнмәкче булган иде, шушы йодрыгым белән берне чыраена манчып кына котылдым... Син борчылма, борчылма... Бәлки, сиңа тимәс тә әле...

Төлкиназ. Тиеп кенә карасын! *(Капка тарафына карап йодрыкларын селки.)* Хуҗасының бер тавыгын урлап качармын!

Куянша *(Төлкиназга ярарга тырышкан булып).* Әгәр авылга барсаң, бер очтан миңа берәр килограмм тунна ситнер кишер дә алып кайтырсың әле, яме, Төлкиназ?!

Төлкиназ. Ярар. Җай чыкса алып кайтырмын... *(Янә капка тарафына карап йодрыгын селкеп ала.)* Ух, мин сине, салам сыйрак!

Куянша *(сүзне икенчегә бора).* Ничек соң, Төлкиназ, бүген юлың уңдымы?

Төлкиназ. Уңган иде. Менә мо-о-ондый *(кулын җәеп күрсәтә)* бер әтәч эләктергән идем.

Куянша. Шыттырма инде, Төлкиназ. Шундый әтәч була димени?

Төлкиназ. Ну... моннан аз гына бәләкәйрәк булгандыр инде...

Куянша. Качып котылдымы?

Төлкиназ. Үзем җибәрдем. Чирле булып чыкты. Грипп эләктергән икән.

Куянша. Әтәч үзе әйттемени?

Төлкиназ. Әйе. Суыткычтан салкын сөт алып эчкән булган... Аны ашап, үземә грипп эләктерәлмим бит инде мин. Җитмәсә, шыр сөяктән генә тора үзе.

Куянша. Әле генә менә мо-о-ондый, дигән идең...

Төлкиназ. Аның йоннары гына калын булып чыкты.

Куянша *(кинәт сагая).* Мышнаган тавыш ишетелә!

Икәүләп, тын калып, тыңлыйлар. Бераздан мыш-мыш килеп, мүкәйләп Бүретдин килеп керә: аңа Бәрән атланган.

Бәрән. Әйдә, бахбай! На-на!

Төлкиназ *(ярым пышылдап).* Әстәгыфирулла!

Куянша белән Төлкиназ баскычка елыша төшәләр.

Бүретдин *(тукталып).* Уф! Төш тизрәк, аңгыра! Үләм!

Бәрән *(ашыкмый гына Бүретдин өстеннән төшә. Бүретдин мәтәлеп китә).* Шушындамы? Китчәле, юкны сөйләмәле... Куян өе каршында бүре үлә димени... *(Төлкиназны күреп ала.)* Бәррәч!.. Бусы кем тагы?

Төлкиназ Куяншага сыенмакчы була, тегесе аны үзеннән читкә этәрә.

Куянша. Бә... бә... Бәрән, ул... ул минем бе... белән түгел... Мин... мин моны ызнайт незнай! *(Әкертен генә тәрәзәгә таба бара.)*

Төлкиназ. Ку... ку... янша... ту... ту... ганым... Син... син... Нәрсә! Мин... мин... синең җан дустың бит!

Куянша. Нинди җан дустың булыйм мин синең! Юк-юк! Мин сине ызнайт незнай! *(Җәһәт кенә тәрәзәгә үрмәли дә эчке якка мәтәлеп төшә.)*

Бүретдин хәлсезләнеп ята. Төлкиназ әле аңа, әле Бәрәнгә карый.

Бәрән. Син әллә төлкеме?

Төлкиназ. Әб-бизәтелне. Кем... Бәрән туганым... Мин... мин... төлке... Ие!

Бәрән *(Төлкиназга таба бер-ике адым атлап куя, тегесе качарга мөмкинлек булмаганлыктан, гәүдәсен арткарак авыштыра).* Нишләп мин синең туганың булыйм?

Төлкиназ. Туганым дип ялгыш әйттем... Юк-юк!.. Син минем туганым түгел... Син минем иң якын дустым! Ә болар... *(Куянша белән Бүретдингә ишарәли)...* болар минем дошманнарым...

Бүретдин *(Төлкиназга).* Куркак!..

Төлкиназ. Куркакның үзеннән ишетәм...

Куянша *(тәрәзәдән башын чыгарып).* Ялагай!

Төлкиназ. Ә син... ә син — кишер буры! Вәйт, менә кем син!

Куянша. Ә син — әтәч буры!

Төлкиназ. Ә син — кәбестә корты!

Куянша. Ә син — тавык бете!

Төлкиназ. Ә син... ә син...

Бәрән. Җиттеме сезгә, юкмы, ызгыш чукмарлары!

Төлкиназ. Миңа җитте. Ә менә аңа *(Куяншага ымлый)* җитмәде бугай әле...

Куянша. Җитте, җитте... Миңа да җитте!

Бәрән. Җитсә — бик шәп. Авызларыгызны ябыгыз. Минем йоклыйсым килә. *(Ятакка таба бара.)* Комачауламагыз миңа.

Төлкиназ. Юк, юк... Борчымыйбыз бүтән...

Бәрән. Бүретдин!

Бүретдин. Әү!

Бәрән. Син минем тынычлыгымны сакларсың, яме! *(Ятакка ята.)*

Бүретдин. Ә?.. Ярый, ярый... Саклармын.

Төлкиназ. Тәмле-тәмле, татлы-татлы төшләр күреп йокла, яме!

Бәрәннең гырлаганы ишетелә.

Куянша. Уф! Йоклап та китте аңгыра сарык җүләре. *(Бүретдингә.)* Йә, хәлләрең ничек, бахбай? Билкәйләрең авыртмыймы?

Бүретдин. Көлмә, көлмә, Кылыйша. Сиңа да чират җитәр әле. Бу аңгырадан бөтенесен дә көтәргә була...

Төлкиназ. Чынлап та, өнме соң бу? Әллә төш кенәме?

Куянша. Цирк бу! Аңладыңмы, көлтә койрык? «Бүрене иярләгән бәрән» дип аталган тамаша бу!.. Шулай бит, Бүретдин?!

Бүретдин *(торып баса).* Мин таям. Сез үз җаегызны үзегез карагыз.

Куянша. Ничек инде? Ничек инде?

Бүретдин. Таям, дидем — таям! Вәссәлам!

Төлкиназ. Ә мин — сызам! Мин монда ялгыш кына килеп эләктем. *(Китәргә җыена.)* Сезне белмим, сезне күрмәдем.

Куянша. Ә мин? Мин нишлим?

Бүретдин. Син дә тай!

Төлкиназ. Син дә сыз!

Куянша. Өйне ташлапмы? Шушы ахмакка затлы өйне калдырыпмы? Әти, сәяхәттән кайткач, үтерә бит мине. Сез нәрсә?

Бүретдин. Алайса — тайма. Кал. Бу җүләрне атландырып йөртерсең... *(Китмәкче була.)*

Куянша. Бүретдин абзыкаем, Төлкиназ түтекәем... Зинһарлап сорыйм... Калдырмагыз мине бу ишәк янында... Паж-жалысты!..

Төлкиназ. Ишәк түгел бу — Бәрән!

Куянша. Барыбер, бусы да аңгыра инде. Зинһар, ялгызымны калдырмагыз. Бүретдин абзыкаем, Төлкиназ түтекәем... Мине үтерә бит ул... Аннан соң сезне эзләп табачак та, сезне дә үтерәчәк... Берәм-берәм...

Бүретдин. Син дөрес сукалыйсың бит, Кылыйша. Чыннан да, бу безне берәм-берәм үтерергә мужыт.

Куянша *(җан керә).* Үтер-рә-ә... үтер-рә-ә... Ике дә уйламаячак бу! Үтермәсә дә, гарип калдырачак. Мин әйткәние диярсез менә.

Төлкиназ. Нишлибез, Бүретдин? Моннан котылу әмәлен табарга кирәк.

Куянша. Әллә үзен нитәбезме... *(Үзен-үзе буып күрсәтә.)* Буабызмы әллә?

Бүретдин. Тс-с! Ишетмәсен тагы.

Бүретдин белән Төлкиназ бер-берсенә карашып алалар да Бәрәнгә таба әкрен генә атлыйлар. Тәрәзәдән Куянша да чыкмакчы була.

Бәрән *(гырлаудан туктый, икенче якка әйләнеп ята, йокы аралаш сөйләнә).* Шүретдин!.. Син мондамы?

Бүретдин белән Төлкиназ туктап кала.

Төлкиназ *(Бүретдингә).* Тс-с! Саташып ята...

Тәрәзәдән чыккан Куянша кабат керергә маташа.

Бәрән. Син мондамы... Шүретдин? Тынычлыкны сакла, яме?..

Бүретдин белән Төлкиназ кире чигенә. Куянша тәрәзә тупсасына утыра.

Бүретдин. Булмый. Уянуы бар.

Төлкиназ. Алайса, бүтән әмәл табыйк.

Бермәл өчесе дә уйга тала. Бүретдин белән Төлкиназ әрле-бирле йөренә.

Куянша *(кычкырып җибәрә).* Таптым! *(Тәрәзәдән тышкы якка мәтәлеп төшә).* Ай!

Төлкиназ белән Бүретдин. Тс-с-с!

Куянша *(егылган җиреннән торырга азапланып).* Таптым!..

Бүретдин. Нәрсә таптың?

Төлкиназ. Әйт тизрәк!

Куянша. Аюга әйтергә кирәк. Ул моны «ә» дигәнче ботарлап ташлый.

Бүретдин. Дөрес! Монда нидер бар. Әгәр аю бу divananы юк итсә, бер мичкә бал бирәбез үзенә.

Куянша. Кайдан аласың ул балны? Авыл умарталыгына барыпмы? Умартачы күрсә атып үтерер...

Төлкиназ. Авылга барып йөрмибез. Аюның үз балын урлыйбыз. Мин аның кышка дип сакланган балы кайда икәнен беләм.

Куянша *(сөенеченнән кулларын чәбәкләп ала).* Шә-ә-әп! Башың эшли дә инде үзеңнең!

Төлкиназ *(мактанып).* Кайберәүләрнеке ише генә түгел инде.

Бүретдин. Киттек, алайса. Бәрән уянганчы аюны алып килик.

Төлкиназ. Барыбыз да китмик. Бу ахмак уянса — шикләнер. *(Бүретдингә дәшә.)* Куянша калып торсын...

Куянша. Сез нәрсә? Юк, юк, мин калмыйм!

Төлкиназ. Алай-болай уянса сөйләндерә торырсың...

Куянша. Юк, юк! Сездән калмыйм. Сезнең белән китәм.

Бүретдин. Ярар. Ияр, әйдә. Без әйләнеп килгәнче уянмас әле.

Куянша *(сөенеп).* Уянмый, уянмый! Каты йоклаганы күренеп тора бит әнә! Гырлавын гына карагыз! Трактормыни!.. *(Бәрәннең гырлавы отыры көчәя.)* Әйтәм бит! Үлгән бәрән кебек йоклый.

Төлкиназ. Үлгән бәрән гырлыймыни, җүләр!

Куянша. Үзең син җүләр! Мин бит чагыштырып кына әйттем.

Төлкиназ. Тапкансың чагыштыру!

Бүретдин. Йә, ярар, җитте. Юкка әрепләшмәгез. Киттек әйдә!

Куянша. Киттек!

Бәрәнгә карый-карый, өчесе дә капкага таба юнәлә. Китешли Бүретдин янә башын бәрә, бер кулы белән башын тотып, икенчесе белән Куяншага йодрык селки. Алар күздән югалуга, Бәрән торып утыра.

Бәрән. Уф! Буып үтерәләр дип торам.

Шулвакыт, як-ягына каранып, курка-курка гына Кәҗәмил керә.

Кәҗәмил *(Бәрәнгә).* Синең өчен борчылып ята-ята бөтен гәүдәм оеды. *(Гәүдәсен, беләкләрен угалап ала.)* Качкан җирдән чыгып, тегеләрнең эчләренә тибәрдәй булдым.

Бәрән. Йә, ничек, Кәҗәмил? Шәп куркыттыммы үзләрен? Нәкъ мин әйткәнчә килеп чыкты. Өчесе дә дер калдырап төште.

Кәҗәмил. Кем белә, ахыры ни белән бетәр бит әле.

Бәрән. Борчылма. Мин бөтенесен дә уйладым. Син мине әллә чын-чынлап йоклады дип уйлыйсыңмы?

Кәҗәмил. Юк, кәнишне. Болардан курыкмыйча йоклар өчен тимер йөрәк кирәк.

Бәрән. Безнең йөрәкләр тимердән дә нык, Кәҗәмил.

Кәҗәмил. Ныклыгын кем белә бит әле. Аю килсә, нишләрсең?

Бәрән. Җаен табармын. Бүре хәтле бүрегә атланып йөргәнне.

Кәҗәмил. Бүре — бүре ул... Ә бусы — аю! Башы — казан чаклы, гәүдәсе — мунча хәтле!

Бәрән. Булса ни?! Миңа димәгәе. Әйттем бит инде — мин барысын да уйладым.

Кәҗәмил. Мин күрәзәче түгел лә. Синең ни уйлаганыңны мин каян белим.

Бәрән *(җитди).* Хәзер болар белән сиңа уйнарга туры килмәгәе әле.

Кәҗәмил. Ничек инде миңа? Ә син? Син нишлисең?

Бәрән. Курыкма, мин дә монда булам. Боларны бүтән авылга килмәслек итсәк, бии-бии җырлаячакбыз әле без синең белән, Кәҗәмил. Бүген иртән, монда килгәнче, ничек шәп җырладык, ә? Әллә тагын җырлыйбызмы?

Дәртле-шаян көй агыла. Бәрән бии-бии җырлый башлый.

Бәрән. Урманда яши төлке,
Аю, куян һәм бүре.
Безгә, безнең хуҗага
Зыян ясый һәрбере...

(*Кәҗәмилгә «Син дә кушыл әйдә!» дигән ым-ишарә ясый. Тегесе икеләнебрәк тора.)*

Мин — бәрән, ә син — бәти...

Кәҗәмил *(җырга кушыла).*

Мин — бәти, ә син — бәрән...

Икәү бергә.

Акылга утыртыйк без
Аларны берәм-берәм...

Бәрән *(дәвам итә).*
Бүре безгә тимәсен...
Кәҗәмил. Төлке тавык чәлмәсен...
Бәрән. Аю бал урламасын...
Кәҗәмил. Куян кишер алмасын...

Икесе бергә бии-бии җырлыйлар.

Бәрән, Кәҗәмил.
Мин — бәрән, ә син — бәти...
Мин — бәти, ә син — бәрән...
Акылга утыртыйк без
Аларны берәм-берәм...

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

Шул ук күренеш. Тынлык. Челтәрле ятакта Кәҗәмил ята. Ул, урыныннан торып, куаклык артына поскан Бәрәнгә нидер әйтмәкче була, әмма капка тарафында күренгән Бүретдинне, Төлкиназны һәм Аюулланы күреп, янә урынына ята.

Бүретдин *(калганнарга дәшә).* Тс-с-с!

Төлкиназ. Уянмаган әле. Әйдә, әйдә, Аюулла. *(Аюулланы төрткәли.)*

Аюулла атлар-атламас кына кыймылдый.

Куянша. Әйдә, әйдә, курыкма!

Куянша, җәһәт кенә ишек янына барып, терәүне алып куя. Бүретдин ятак янына килеп карый да өнсез кала. Нидер әйтмәкче була — әйтә алмый.

Төлкиназ *(Аюулланы этә-төртә).* Әйдә, әйдә, Аюулла! Курыкма. Иптәшкә без барын онытма... *(Ятакка күзен төшерүгә, кычкырып җибәрә.)* А-а-а!..

Бүретдин *(телгә килә).* У-у-у-у...

Төлкиназ. А-анда-а-а... а-а-а...

Аюулла. Э-э-э!..

Артларына чигенәләр. Кәҗәмил урыныннан тора, йокыдан уянгандай кыланып, күзләрен угалый.

Куянша *(шәрран акырып җибәрә).* Коткарыгыз! *(Җәһәт кенә өйгә кереп кача.)*

Кәҗәмил *(үз алдына сөйләнгәндәй).* Күптән болай тәмләп йоклаган юк иде... *(Аптыраудан авызын ачып карап торган Бүретдингә.)* Рәхмәт, Бүретдин. Эт шикелле тугры икәнсең!

Аюулла. Шу... шу... шушымы инде сезнең бәрән дигәнегез?

Төлкиназ. Шу... шушы бу... бугай инде-е-е...

Бүретдин. Шу... шушы дип... *(Кәҗәмилгә.)* Син кем?

Куянша тәрәзәдән башын чыгарып карап тора.

Кәҗәмил. Син нәрсә, Бүретдин? Нәрсә булды сиңа? Ни булды сезгә? Минем бәрән икәнлегемне оныттыгыз мәллә?

Куянша *(бик гаҗәпләнеп).* Бәрә-ән?

Аюулла. Мин... мин бер ни дә аңламыйм. *(Бүретдин белән Төлкиназга.)* Кайда сезнең бәрәнегез?

Бүретдин. Әнә бит...

Төлкиназ. ...Каршыда басып тора!

Аюулла. Әллә сез тилергән... Әллә мин аңгырайган... Нинди бәрән булсын бу! Бу бит — бәти! Кәҗә бәтие!

Кәҗәмил. Сез нәрсә! Нишләп бәти булыйм. Мин — бәрән! Аңгыра бәрән мин! Җүләр сарык бәрәне!

Куянша *(башын селки, күзләрен челт-челт йома, үзен-үзе тотып карый).* Син... син бәрән булсаң... Мин... мин керпе, алайса?

Бүретдин, Аюулла, Төлкиназ аңа сәерсенеп карыйлар.

Куянша *(Бүретдингә).* Ә син — Бүретдин түгел, бурсык син! *(Төлкиназга.)* Ә син — тиен! *(Аюуллага.)*
Ә син — кабан дуңгызы!..

Кәҗәмил. Менә әкәмәт! Җүләр хайваннар арасына килеп эләктем мәллә мин? Бүретдин, әйт, нәрсә булды сезгә? Әллә мин төш күреп ятаммы? Уятыгыз мине!

Бүретдин *(Аюуллага).* Миңа калса... Бу бәрән... әгәр дә ул чынлап та бәрән булса... сәвсим *(бармагын чигәсендә биетеп ала)*... ычкынганнар! Бәласеннән баш-аяк! Тайыйк моннан!

Кәҗәмил. Юк, юк, бер кая да китмисез! Минем сезнең һәммәгезгә дә атланып йөрисем килә! *(Ятагыннан сикереп төшә дә Аюулла янына килеп, аның җилкәсенә асылына.)* Әйдә, син башта атландырып йөрт!

Куянша пырхылдап куя. Бүретдин белән Төлкиназ читкәрәк тайпыла.

Аюулла. Син нәрсә? Мин бит ат түгел. Аю мин, аю!

Кәҗәмил. Ә мин — аңгыра бәрән! Шуннан ни?

Бүретдин әкертен генә капкага таба чигенә.

Куянша. Әй, син, Бүретдин, безне бу аңгыра янында калдырып кая таймакчы буласың?

Бүретдин *(туктала).* Юк, юк, таймыйм мин. Өйдә телевизор кабызылган килеш калган иде... Шул искә төште дә...

Төлкиназ *(китмәкче булып).* Ә мин газга аш куйган идем. Шулпасы парга әйләнгәндер инде...

Куянша. Алдашма! Синең үз гомереңдә аш пешереп ашаганың юк. Гел анда-монда сыйланып йөрисең... Син дә бер кая да китмисең!

Төлкиназ. Китмим, китмим... Нишләп китим. Сезне бу ахмак янында калдырып китәмме соң... Юк-юк! Булмаганны.

Кәҗәмил. Сезнең арада иң әйбәте Төлкиназ икән.

Төлкиназ *(мактаганга күңеле булып).* Мин һәрвакыт шулай әйбәт.

Кәҗәмил. Аюулла арыгач, сиңа атланып йөрермен. Әзерләнеп тор яме, Төлкиназ?

Төлкиназ. Ә? *(Хәлсезләнеп, җиргә лып итеп утыра.)*

Аюулла *(Кәҗәмилгә).* Төш әле җилкәдән.

Кәҗәмил. Нәрсә? Син миңа... аңгыра бәрәнгә шулай диденме? Җылыйм бит хәзер. Мин җыласам, каты җылыйм! *(Елаган булып кылана.)* Бә-ә... Бә-ә-ә... Ятим дигәч тә... Мин бит әле, аңгыра булуым өстенә, ятим дә... Бә-ә-ә-ә... Әти-әниемнән, әбекәем белән бабаемнан, абыем белән апамнан, энем белән сеңлемнән башка беркемем дә юк бит минем! Бә-ә-ә-ә...

Аюулла. Җә, җә, җылама. Төшеп кенә тор әле җилкәдән... Әйбәтләп утырырсың...

Кәҗәмил *(елавыннан туктап).* Күптән шулай diләр аны...

Аюулла. Без монда киңәш-табыш итешеп алыйк... Синең күңелеңне ничек күрергә, дигәндәй... Аннан соң атландырып йөрермен сине, җәме? Бар, ятагыңда бераз ятып тор.

Кәҗәмил. Э-э-э... Качар идегез бугай.

Куянша. Качмыйлар инде, качмыйлар... Бар, бар, әйткәннәр бит сиңа — ятып тор.

Кәҗәмил. Ярый, алайса, мин сезгә ышанам... Ятып торыйм аз гына *(ятакка таба бара).* Тик... Качсагыз, үзегезгә үпкәләгез — сезне барыбер эзләп табачакмын. Сезнең патшагыз булачакмын!

Төлкиназ. Ярый, ярый, борчылма.

Аюулла, Бүретдин, Төлкиназ бер читкә китеп сөйләшә башлыйлар. Куянша, өеннән чыгып, алар янына килә. Болар бер-берсенә сыенып пыш-пыш килгән арада, поскан җиреннән Бәрән чыга да ятакка барып ята. Кәҗәмил аның урынына кача.

Аюулла *(ятакка таба борылып).* Без болай итәргә булдык... кем... бәрән дус...

Бәрән *(ятактан калкып).* Нәрсә дисең, Аюулла?

Бәрәнне күреп, һәммәсе дә катып кала.

Төлкиназ. Әстәгыфирулла!

Бүретдин. У-у-у... Җен мәллә бу-у-у?..

Куянша. Тотыгыз мине!

Аюулла. Берни дә аңламыйм...

Бәрән. Йә, киңәшләштегезме?

Бүретдин *(башкаларга карап ала-ала).* Билләһи дип әйтәм, җен бу! Аңгыра җен!

Бәрән. Мыскыл итмә мине, Бүретдин. Син үзең җен! Нишләп мин җен булыйм... Мин — аңгыра сарык җүләре!

Куянша. Тотыгыз мине, тотыгыз!

Төлкиназ. Мине дә тотыгыз! Хәзер аңымны югалтып егылам...

Бәрән. Йә, кайсыгыз мине атландырып йөртә инде? Минем атланып йөрисем килә... Авылда мин гел атланып йөрим: йә атка, йә этка, йә мәчегә...

Төлкиназ. Бу сиңа авыл түгел... Урман бу!

Бәрән. Миңа барыбер. Атландырып йөртүче генә булсын...

Аюулла. Аякларым монда килергә бер генә дә тартмаган иде... Ник сезнең сүзне тыңладым мин...

Кинәт Төлкиназ кулларын бутап чәбәләнә башлый. Барысы да аңа гаҗәпләнеп карыйлар.

Бүретдин. Нишлисең син, җил тегермәне?

Төлкиназ. Корт! Корт бар! Бал корты! *(Чәбәләнә, бөтерелеп йөри.)*

Аюулла. Бал корты? Кайда, кайда ул? Безләгәне ишетелми ич!

Безләү тавышын сиздермичә генә, Кәҗәмил чыгара.

Төлкиназ. Әнә бит, әнә! Чагып үтерә мине! Коткарыгыз! *(Әле берсенә килеп тотына, әле икенчесенә барып елыша.)*

Куянша. Килмә, килмә, минем янга килмә! Китермә миңа бал кортын! Мине корт чагарга ярамый. Аллергия!

Бәрән. Нишлисез сез, тилеләр. Мин бер бал корты да күрмим бит! Сез юри кыланасыз бугай...

Төлкиназ *(чабып йөри).* Аңгыра булуың җитмәгән, сукыр да икәнсең! Әнә бит! Ай! Үтерә! Аюулла, тый бал кортларыңны! Сиңа ияреп килгәннәр алар... Әнә, әнә... Бер өер! Ай!

Аюулла. Әйе шул... Мин дә күрәм... Әнә... әнә... берсе син чәлдерә язган тавык хәтле! *(Чәбәләнә.)*

Төлкиназ. Без-з-з!.. Без-з-з!.. *(Чабулап йөри.)*

Куянша. Килмә, килмә минем янга!

Төлкиназ. Без-з-з!.. Без-з-з!.. *(Бүретдиннең култык астына башын яшермәкче була.)*

Бүретдин *(аннан арынырга теләп).* Кит, кит янымнан! Әнә теге аңгыра янына бар!

Бәрән. Кил, кил, монда кил. Бал кортлары миңа тими алар. Безнең авылныкылар алар!

Төлкиназ. Без-з-з!.. Без-з-з!..

Куянша. Мескенкәем, әллә үзе дә бал кортына әйләнде инде?! Төлкиназ, бар инде җәтрәк, суга барып чум!

Төлкиназ *(Куяншага таба килә)*. Кайда су? Кайда су? Ай!.. Үтерәләр!.. *(Куяншага елыша.)*

Куянша. Кит әле моннан! Мин су түгел лә!

Бәрән *(исе китмәгән булып сөйләнә)*. Бу кортлар — бала кортлар гына... Болар — усал түге-ел... Менә безнең авылдагы ана кортларны күрсәгез иде сез! Тавык чәлдерергә килүчеләрнең чакмаган җирләрен калдырмыйлар инде...

Төлкиназ *(безләвеннән, чәбәләнеп йөрүеннән кинәт туктап)*. Ә?

Бәрән *(Төлкиназга карап сөйли)*. Беркөнне сиңа охшаган бер төлке безнең авылга тавык чәлдерергә килгән булган... Ну кирәген биргәннәр дә инде ана кортлар! Көчкә сөйрәлеп качкан...

Аюулла *(Төлкиназга карап әйтә)*. Булыр, булыр... Үземне чакканнары бар...

Бәрән *(Аюуллага карап)*. Исән түгелдер инде ул төлке. Үлгәндер... Аннан соң беркөнне бер аю килгән булган... Бал урларга. Кортлар аны да тетмәсен теткәннәр! *(Дәртләнеп сөйли.)* Башы... башы... *(Куяншаның йортына төртеп күрсәтә)* менә бу йорт кадәрле булып кабарган-шешенгән, ди... Ул да үлгәндер инде.

Куянша. Аһ!

Бүретдин. Явыз булсалар булырлар икән!..

Бәрән. Кемгә — явыз, кемгә дус алар...

Төлкиназ *(әсәренеп янә чәбәләнә башлый)*. Су! Су!.. Кайда су? Ай! Чагалар, үтерәләр!..

Чабулап йөри, шулай йөргәндә качкан җиреннән калыккан Кәҗәмилне күреп ала. Бәрәннән башкалар анны күрми. Бәрән Кәҗәмилгә «Кач!» дигән ишарә ясый, тегесе яшеренә.

Төлкиназ *(куркып чигенә-чигенә)*. Сакаллы... сакаллы... бал корты! Үтерәләр!

Ул чыгып китүгә, Аюулла кулларын болгарга-бутарга тотына. Бәрән ятакка утырып селкенә, боларны күзәтә.

Аюулла. Тавыклар!.. Тавыклар!..

Бүретдин *(як-ягына карана)*. Нинди тавыклар? Кайда?

Бәрән рәхәтләнеп көлә.

Аюулла. Әнә бит! Әнә бит очалар! Ай! Мине чагып үтерәләр хәзер!..

Куянша *(аптыраганнан гына чәбәләнеп)*. Мескенкәем... Бусы да җүләрләнде бугай... Бүретдин, моның күзләренә тавык күренә башлады... Сиңа да күренмидер бит?

Бүретдин *(чәбәләнә)*. Әлегә юк... Күренми...

Куянша. Ашыкма. Сиңа да күренмәгәе...

Бәрән *(Куяншаның сүзләренә куәт биреп, юри сөйләнә)*. Ә миңа умарталар очканы күренә. Әнә, берәү, икәү...

Куянша. Сиңа күренсә дә ярый. Син болай да җүләр!

Аюулла үрсәләнеп чабып йөри. Шулай йөргәндә, ул да Кәҗәмилне күреп ала.

Аюулла *(әле Бәрәнгә, әле Кәҗәмилгә карый-карый, капкага таба чигенә)*. Очалар!.. Бәрәннәр оча! Кәҗәләр оча! Әнә, әнә! *(Чыгып кача.)*

Бүретдин белән Куянша ул киткән якка карап тора. Бәрән Кәҗәмилне кул изәп чакыра. Кәҗәмил урыныннан чыга да әкрен генә Куянша янына килеп баса.

Куянша. Мескен төлке... Мескен аю... Икесе дә күз алдында тилерде. *(Борылып, Кәҗәмилгә уйламый-нитмичә генә дәшә.)* Ыслабаклар, әйеме? *(Кинәт чырыйлап, гудок тавышы чыгарып, кычкырып җибәрә.)*

Кәҗәмилне Бүретдин дә күреп ала. Ул, күзләрен челт-челт йомып, әле аңа, әле Бәрәнгә карый.

Бүретдин *(башын селкеп ала).* Син... син мондамы, Кылыйша?

Кәҗәмил белән Бәрән дәррәү кычкырып көлә.

Куянша. Мин... мин... монда бугай... Ә син кайда?
Бүретдин. Бел... белмим... *(Кәҗәмилгә.)* Син... Син... бәрәнме?
Кәҗәмил. Бәрән.
Бүретдин *(Бәрәнгә).* Син дә... бәрәнме?
Бәрән. Бәрән инде, бәрән!
Куянша. Сез... сез... ничәү соң?
Бәрән, Кәҗәмил *(икесе бергә).* Без... без — өчәү!
Бүретдин. Тот мине, Кылыйша...
Куянша. Син дә мине тот, Бүретдин...

Икесе бергә тотынышалар. Икәүләшеп капкага таба чигенәләр. Кәҗәмил белән Бәрән, җитәкләшеп, аларга таба атлый.

Бүретдин (*хәлсез тавыш белән).* Синең качарлык хәлең бармы, Кылыйша?
Куянша. Аяклар кыймылдаган сыман, Шүретдин...
Бәрән, Кәҗәмил *(кинәт икесе бергә).* Һәйт!

Бүретдин белән Куянша мәтәлеп китәләр.

Куянша. Караул!
Бүретдин. Качтык!

Икесе дә тиз-тиз мүкәләп, чыгып качалар. Бәрән белән Кәҗәмил кычкырып көлә.

Кәҗәмил. Күрмәгәннәрен күрсәттек үзләренә.
Бәрән. Ә син курыккан идең...
Кәҗәмил. Без тотынсак булдырабыз инде аны! Шулай бит, аңгыра сарык җүләре? *(Көлә.)*
Бәрән. Шулай, шулай, миңгерәү кәҗә тилесе! *(Ул да көлә.)*

Икесе, кочаклашып, бии-бии җырлыйлар.

Бәрән, Кәҗәмил.
Урманда яши төлке,
Аю, куян һәм бүре...
Бездән ерак йөрерләр
Моннан ары һәрбере.

Мин — бәрән, ә син бәти...
Мин — бәти, ә син — бәрән...

Акылга утырттык без
Аларны берәм-берәм...

Бәрән. Кайтабызмы инде авылга, Кәҗәмил?
Кәҗәмил. Чаптык әйдә, Бәрән дус!

Җыр көе астында көлә-көлә чыгып китәләр.

Пәрдә.

## ЯҢА ЕЛ БИШТӘРЕ

*(Әкият-пьеса)*

КАТНАШАЛАР:

Яңаел
Быел
Илдус
Айрат
Баштүрә
Башия
Башаяк

БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Стеналарына: «Яшәсен сөеклебез Баштүрә!», «Баштүрәнең һәр сөйләгәне дөрес!», «Башөсте, Баштүрә!» дигән язулар һәм Баштүрә сурәтләре эленгән бүлмә. Кулларын артка куеп, өстәл тирәли Баштүрә йөренә. Ара-тирә баш чүмечен кашып ала, сурәтләргә, язуларга сокланып карый-карый җыру суза...

Баштүрә. Һин-нә-ләй, мин-нә-ләй,
Кара мамык бияләй.
Кара мамык бияләйне
Мин — Баштүрә кияләй...
Һин-нәләй, мин-нәләй...

Баштүрә *(җырлавыннан туктап кычкыра).* Башия! Башия, дим! Кая олактың, мәнсез?

Мышкылдый-мышкылдый Башия йөгереп керә.

Башия *(башын ия).* Тыңлыйм, Баштүрәм!
Баштүрә. Минем затлы башымда бер иррттерресный план туды...
Башия. Синең затлы башыңда бер иррттерр... иррттерр...
Баштүрә. Сөйләп бетергәнне көт, надан!
Башия. Әйе, мин — надан, Баштүрәм! Сөйләп бетергәнеңне көтәм...
Баштүрә. Көтмә. Бар, тиз генә теге тинтәкне, Башаякны чакыр монда!
Башия. Башөсте, Баштүрә. Хәзер теге тинтәкне чакырам. *(Чыгарга таба борыла.)*
Баштүрә *(аны туктата).* Башия!
Башия. Әү, Баштүрәм!
Баштүрә *(җен ачуы чыгып).* Ниткән «әү» тагын, надан!
Башия. Минават, Баштүрәм. Тыңлыйм, Баштүрәм.
Баштүрә. Теге затлы җыруны җырла. Аннан соң теге тинтәкне чакырырсың...
Башия. Теге затлы җыруны җырлыйм, Баштүрәм. Аннан соң теге тинтәкне чакырырмын... *(Җырлый башлый.)*
Затлы бүрек, затлы тун
Кия безнең Баштүрә-әй...

*(Баштүрә борынын югары чөеп, рәхәтләнеп, изрәп җырны тыңлый.)*

Башбашлар илендә һәркем
Баштүрәне баш күрә-әй...
Их! Яшә, яшәсен...

Баштүрә. Ярар, җитәр... Бар. Башаякны чакыр. Тиз бул!
Башия. Башөсте, Баштүрәм. Хәзер чакырам, Баштүрәм.

Китә. Сәхнә артында аның: «Башаяк! Сөекле Баштүрәбез сине чакыра!» — дигән тавышы ишетелә. Бераздан Башаяк керә.

Башаяк. Чакырдыгызмы, Баштүрәм?

Баштүрә. Минем затлы башымда бер ирртерресный план туды. Сиңа бик җаваплы бер эш тапшырырга уйлап торам...

Башаяк. Мин әзер, Баштүрәм.

Баштүрә. Минем алтын сәгать белән *(сәгатенә карый)* моннан утыз ике минут элек, Башбүкән исемле шымчымнан бик мөһим иррфоррмасия алдым: Яңаел килергә чыккан!

Башаяк. Фәрман бир, Баштүрәм. Хәзер юк итәм мин аны.

Баштүрә. Ашыкма, надан! Аягыңны түгел, башыңны эшләт бераз. Без аны юк итсәк, тагын шул Искеел белән торып калабыз бит, тинтәк! Аңладыңмы?

Башаяк. Аңладым, Баштүрәм.

Баштүрә. Аңласаң, шул: безгә аның үзе түгел, биштәре кирәк! Башбүкән әйтүенчә, ул биштәрдәге шатлык-сөенечләр былтыргыга караганда икеләтә күп икән. Безгә ничек тә шул биштәрне кулга төшерергә кирәк. Әгәр безнең кулга эләксә, зур мәҗлес уздырырга боерык бирәчәкмен... Их, кинәнер идек тә соң!..

Башаяк. Син дигәнчә булыр, Баштүрәм!

Баштүрә. Минем затлы башымда туган ирртерресный план мондый. Тыңла...

Баштүрә, берәрсе ишетмәсен дигәндәй, Башаяк колагына нидер пышылдый.

Баштүрә. Кара аны, былтыргы Яңаелның биштәрен эләктерә алмадың, бу Яңаелның да биштәрен ала алмасаң — үзеңә үпкәлә!

Башаяк. Биштәр синең кулда булыр, Баштүрәм.

Баштүрә. Минем алтын сәгать белән *(сәгатенә карый)* Яңаел килеп җитәргә... тә-ә-әк... бер... ике... Бәй, вакыт аз калып килә икән бит инде... Тәк шту, бер аягың монда булсын...

Башаяк. ...икенчесе — башым кайда — шунда булыр, Баштүрәм!

Китә.

## ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Илдуслар өе. Бәйрәмчә җиһазланган. Ашыгып Быел керә. Ул календарь булып киенгән: түшенә «31 декабрь» дип язылган.

Быел *(бүлмәне күздән кичерә).* Берәү дә юк. Кая киткән инде болар тагын? Соңга калына бит хәзер. Нишләргә? Нишләргә? Кешеләрсез, үзем генә берни дә майтаралмыйм, ичмасам. Ничекләр генә ярдәм итәргә инде...

Шулвакыт көлешкән тавышлар ишетелә. Иңнәренә тимераяклар аскан, кулларына кәшәкә тоткан Илдус белән Айрат керә. Быел алар сөйләшкәнне бер читтә тыңлап тора. Малайлар аны күрмиләр.

Айрат. Малай, тегеләрнең тетмәләрен теттек бит, ә! Бер-бер артлы өч гол бит, өч гол! Капкачы Наилнең телләре тотлыга башлады, мин сиңа әйтим. Шул кирәк аңа, иеме, Илдус? Ату гел кәпрәеп йөри иде. Уен башланыр алдыннан гына мактанып торды бит, җитмәсә: имеш, аның капкасына алка түгел, күлмәк сәдәфе дә үтәрлек түгел, имеш, алканы ул күз йомып та тота ала... Кызык та иттек әле үзен, иеме, Илдус?!

Илдус. Әйе... Анысы шулай шулаен да...

Айрат. Туктале, малай, нишләп кинәт кенә кәефең китте әле синең?

Илдус. Җиңү шатлыгы онытылды әле монда. Бүген кич чыршы бәйрәмендә сөйләячәк шигырь искә төште. Яттан гүпчим белмим бит.

Айрат. Һи, тапкансың инде үзең, малай, искитәрлек нәрсә. Синең бит хәтер генә ни тора!

Илдус. Анысы шулай шулаен да...

Айрат. Чыршы бәйрәменә ярты сәгать кенә калганда да син айн момент әвеш-тәвешлисең. Кая инде синдәге хәтер безгә — каткан тезгә... Син шул турыда уйла: Яңаел безгә нинди сөенечләр алып килер икән?..

Быел *(кинәт телгә килә)*. Әгәр җитди чаралар күрмәсәк, бер генә сөенеч тә алып килмәячәк Яңаел!

Илдус белән Айрат тавыш килгән якка ялт борылып карыйлар һәм Быелны күреп алалар.

Икесе бергә. Кем син?

Быел. Әллә танымыйсыз дамы?

Илдус белән Айрат аңа текәлеп карыйлар.

Илдус. Кайдадыр күргәнем бар кебек тә...

Айрат. Минем дә...

Быел. Быел мин!

Илдус. Быел?

Айрат. Әйе, шул, тач үзе!

Илдус. Син бит безгә букча-букча сөенечләр өләшкән идең узган чыршы бәйрәмендә?!

Быел. Сөенечләр... сөенечләр... Мин сезгә күңелсез хәбәр алып килдем әле менә.

Айрат. Ниткән күңелсез хәбәр ул тагын?

Илдус. Әйе, нинди хәбәр ул?

Быел. Яңаелның сөенечләр-шатлыклар тулы биштәрен урларга җыеналар. Дөресрәге, ул биштәрне алыштырмакчы булалар...

Илдус. Кемнәр?

Айрат. Ничек инде... урларга җыеналар?

Илдус. Каян белдең?

Быел. Былтыр, сезнең янга килер алдыннан, Гасыр бабай миңа өч йөз алтмыш биш көнне ышанып тапшырды да инструкция үткәрде: «Һәрбер көнеңне күзәтеп тор, әрәмгә узмасын, берүк»,— диде. Менә бүгенге, соңгы көнемнең һәр сәгатен, һәр минутын күздән кичерә-кичерә тикшереп-барлап йөргәндә, җилләр миңа күңелсез хәбәр җиткерделәр: өстә, Караболыт материгында, Яңаелга каршы әнә шундый явызлык кылмакчы булып яталар...

Айрат. Кемнәр соң алар?

Быел. Алар әнә шул материктагы Башбашлар илендә яшиләр. Исемнәре дә мәгълүм: Баштүрә, Башия, Башаяк... Былтыр шуларның берсе, Башаяк дигәне, көтмәгәндә миңа һөҗүм итте. Алыш вакытында минем биштәрдәге шактый сөенеч-шатлыкны алып, алар урынына байтак кына явызлыклар, кайгы-хәсрәтләр салып өлгерде. Менә бүген дә Яңаелның юлына каршы төшмәкче була әнә шул явыз. Биштәрне хәйләләп-алдалап алып, аның урынына үзенең кайгы-хәсрәт белән шыплап тутырылган үз биштәрен калдырырга җыена.

Илдус. Алайса, нишләп тик торабыз соң әле без? Тизрәк, ашыгырга кирәк!

Айрат. Әйе, ашыгырга кирәк!

Быел. Әйдәгез, мин юл күрсәтермен...

## ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Урман. Аланлык. Ап-ак биштәр салынган чанасын тартып, җырлый-җырлый Яңаел килә.

Яңаел. Бигрәкләр дә матур дөнья! —
Җиргә аклык бөркелә...
Гүзәллеккә таңнар калып,
Бер елмаям, бер көләм.
Кешеләрнең бик сагынып
Мине көткәнен беләм.

Шуңа күрә сөенечләр,
Шатлыклар алып киләм,
Өләшермен мин аларны
Тынычлык, бәхет теләп,
Яңа яуган кардай ап-ак
Биштәрем үзем белән...

Кинәт елау тавышы ишетеп, Яңаел җырлавыннан туктый.

Яңаел *(тавыш килгән якка кычкыра).* Кем бар анда? Кем елый?

Бәс сарган чыршы артыннан күзләрен уа-уа Башаяк чыга.Ул балалар кебек киенгән. Сөйләшүе дә балаларча. Яңаел, чана бавын кулыннан ычкындырып, аның янына килә.

Яңаел. Нигә елыйсың, үскәнем? Кем тиде?

Башаяк *(лышт-лышт итеп борынын тарта-тарта).* Ур... ур... Урбасарлар... Әйем лә... юл... юл... юлбасарлар... минем вилсәпидемне таладылар! *(Кычкырып елый башлый.)*

Яңаел. Елама, үскәнем, елама. Мин сиңа икенче вилсә... Туктале, ә нишләп соң монда, урманда, вилсәпид белән йөрисең әле, үскәнем? Кыш көне бит чана шуалар...

Башаяк *(кинәт сискәнеп).* Ыңк! Мин... ни... вилсәпидне чанага салган идем...

Яңаел. Исемең ничек синең, үскәнем?

Башаяк. Минемме? Башаяк, Баштүрәм!

Яңаел. Ай-һай, шаян да малай икән син, ә! Башаякбаштүрәм дигән исем була димени?

Башаяк *(ялгышканын аңлап).* Э-э-эм... Ни... Ул минем исем түгел шул... Ие... Кушамат кына... Минем исемем — Басыйр.

Яңаел. Карале, бигрәк матур исем икән. Басыйр. Ә нишләп син, Басыйр, бу урманда чанаңа вилсәпид салып йөрисең?

Башаяк. Мин бит... ни... вилсәпидтә бик йөрисе килгәч... җәйне эзләргә чыккан идем... Каршыма урбасарлар... әйем лә... юлбасарлар чыкты да... *(тагын елый башлый).* Вә-ә-ә... Ә мине... карга батырдылар. Вә-ә-ә...

Яңаел. Елама, үскәнем. Син бит зур егет инде хәзер. Елама, Басыйр. Чанаңны кая яшергәннәрен күрмәдеңме соң?

Башаяк. Ә-әнәү теге чыршы төбендәге көрткә күмделәр. Вә-ә-ә...

Яңаел. Елама, Басыйр. Чанаңны үзем алып киләм. Ә син туныңны кага тор... *(Китә.)*

Башаяк *(баскан җирендә биеп ала).* Ха-ха-ха! Алданды, алданды! Урра, биштәр безнең кулда!

Сикеренгәләп, тиз генә куак артына бара да үз биштәрен алып килә, аны Яңаел биштәре белән алыштыра.

Башаяк *(Яңаел киткән тарафка карап).* Үскәнем, эзлә чананы, эзлә. Тапсаң үзеңә булыр... Хи-хи-хи... *(Чыгып йөгерә.)*

Яңаел *(керә).* Басыйр, син әкәмәт тә егет булып чыктың бит әле...

Ул Башаякның юклыгын күреп аптырап кала. Качкандыр дип уйлап, якындагы куак артларын барып карый.

Яңаел. Басыйр! Басыйр! Кая качтың? Чык, әйдә, монда!

Башаяк күренмәгәч, Яңаел тагын да ныграк гаҗәпләнә.

Яңаел. Менә кызык... Әллә күзгә генә күренде инде?!

Ул шулай аптырап торганда Быел, Илдус, Айрат керә.

Быел *(сөенеп кычкыра).* Ә-ә, Яңаел монда! Исән! Сәлам, Яңаел!

Кул биреп күрешә.

Айрат. Ур-р-ра, өлгердек!

Илдус *(чанадагы биштәрне күреп).* Урррa, биштәр дә монда!

Яңаел. Нәрсәгә шулхәтле сөенәсез? Берни аңламыйм. Гомумән, әллә сез бөтенегез дә күзгә күренәсез инде?

Быел. Их, Яңаел, белсәң иде син безнең ничек борчылганны! Өлгерә алмабыз дип куркып, җан-фәрманга синең каршыңа чаптык. Тәки өлгердек. Карале, алай-болай сиңа берәр явыз бәндә очрамагандыр бит?

Яңаел. Юк-юк, нигә?

Быел. Болай гына соравым...

Яңаел. Әле сез монда килгәнче бер кызык хәлгә юлыктым... Җырлый-җырлый килә идем шулай, ишетәм — кемдер елый. Карыйм — бер малай. «Нигә елыйсың?» — дим моңа. «Вилсәпидемне юлбасарлар талады»,— ди бу. *(Көлә.)* Шундый да шаян малай инде менә. Басыйр исемле. Кушаматы бигрәк тә кызык! Ничек диде әле? Ә-ә-ә... Исемә төште: Башаякбаштүрәм! Әйе, әйе, Башаякбаштүрәм!

Быел, Илдус, Айрат *(өчесе бергә).* Башаяк?

Яңаел. Юк, Башаякбаштүрәм, диде. Сезнең шикелле башта мин дә гаҗәпләнгән идем...

Быел *(хәлсезләнеп).* Биштәр... биштәр...

Илдус белән Айрат чанадагы биштәргә тотыналар, аның авызын чишмәкче булалар.

Быел. Чишмәгез, харап итәсез дөньяны! *(Тегеләр туктап кала.)*

Яңаел. Нәрсә булды? Нишләп өчегезнең дә битләре агарды?

Айрат. Аһ, явыз тәре! Өлгергән бит!

Яңаел. Кем явыз? Минме? Аңлатыбрак сөйләгез әле...

Илдус. Син түгел... Башаяк! Башаяк явыз! Биштәрне алыштырган!

Быел. Әйдәгез, тизрәк Башаякның артыннан куарга кирәк. *(Яңаелга.)* Әйдә, Яңаел, юлда барысын да аңлатырбыз...

Китәләр.

## ДҮРТЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Баштүрә бүлмәсе. Башия белән Башаяк йомшак кәнәфигә чумып утырган Баштүрә тирәсендә чүмәшеп, җыру җырлыйлар.

Башия, Башаяк.

Затлы бүрек, затлы тун
Кия безнең Баштүрә-әй...
Башбашлар илендә һәркем
Баштүрәне баш күрә-әй...
Их! Яшә, яшәсен...

Баштүрә. Ярар, җитәр, тинтәкләрем минем. Яхшы җырлаганыгыз өчен иртәгә берәр нәрсә белән бүләкләрмен үзегезне. Ә хәзер минем затлы соравыма җавап бирегез: затлы боерыгымны ишетмәүчеләр калмадымы?

Башия. Сезнең затлы боерыгыгызны ишеткәннәргә тагын бер кат ишеттердек, Баштүрәм!

Баштүрә. Мәҗлесне затлы итеп бәйрәм залында үткәрергә кирәк. Караболыт материгы гына түгел, бөтен тереклек шауларлык булсын!

Башия. Шулай булыр, Баштүрәм!

Башаяк. Шаулатырбыз, Баштүрәм!

Баштүрә. Табынга бер генә затсыз ризык та куймаска.

Башаяк. Сез дигәнчә булыр, Баштүрәм!

Баштүрә. Табында тел очына тию белән эри торган балыкларның барча төре булсын!

Башаяк. Тел очына тигәнче эри торганнарын да табарбыз, Баштүрәм!

Баштүрә *(сикереп тора).* Андыйлары кирәкми, надан! Мин әйткәнчә эшләргә!
Башаяк. Башөсте, Баштүрәм. Син әйткәнчә эшләрбез!
Баштүрә *(утыра).* Башия!
Башия. Әү, Баштүрәм!
Баштүрә *(сикереп тора).* Нәрсә-ә?
Башия. Минават, Баштүрәм. Тыңлыйм, Баштүрәм.
Баштүрә *(утыра).* Пешекчеләргә минем фәрманны җиткер, затлы уылдык бәлеше пешерсеннәр... Аннан соң, кызыл уылдыкны табада кыздырсыннар. Зәйтүн маенда! Шуны әйтергә онытма! Бар!
Башия *(урыныннан кузгала).* Әйтергә онытмам, Баштүрәм. Барам, Баштүрәм. *(Китә.)*
Баштүрә. Башаяк, сиңа да эш бар.
Башаяк. Тыңлыйм, Баштүрәм.
Баштүрә. Хәзер үк затлы мәҗлес хөрмәтенә күк күкрәт, яшен яшьнәт!
Башаяк. Башөсте, Баштүрәм. Син дигәнчә булыр... ие дә бит...
Баштүрә *(сикереп тора).* Нәрсә? Әле син, хөрәсән, минем затлы фәрманга каршы киләсеңме? Башыңны кистерәм!
Башаяк. Баштүрәм, хәзер кыш көне бит. Күк күкрәтә, яшен яшьнәтә торган машинаның мае каткан. Шистырналары эшләми. Аннан соң быелга дигән бензин запасы да бетте...
Баштүрә. Һе-ем... Ярар. Гаебеңне таныганың өчен бу юлы башыңны кистермим... *(Утыра.)*
Башаяк. Мең рәхмәтлемен, Баштүрәм!

Шулчак төсе качкан Башия йөгереп керә. Керү белән нәрсәгәдер абынып егыла.

Башия. Киләләр! Киләләр! Беттек! Үтерәләр! *(Өстәл астына кереп кача.)*
Баштүрә. Кемнәр килә? Кемнәр бетерә? Кемне үтерәләр?
Башия. Үтерәләр! Үтерәләр!
Баштүрә. Чәчби, дим! Башыңны кистерәм! Минем затлы сорауларыма җавап бир!..
Башия. Биштәрдәге сөенечләр үзегезгә булсын. Үтерәләр! Үзегезгә булсын мәҗлесегез дә... Үтерәләр!
Башаяк *(Баштүрәгә).* Баштүрәм, ниткән бу. *(Бармагын чигәсендә биетеп ала.)* Ычкынган! Җүләрләнгән!
Башия. Син үзең җүләр! Үтерәләр! Кешеләр килә! Яңаел килә!..
Баштүрә *(каушап).* Каян киләләр, чәчби? Тынычлан да тиз генә җавап бир!
Башия. Шуннан киләләр, шуннан! Качыгыз!
Баштүрә *(үзен кулга алып).* Паникага бирелмәскә! Каршылык күрсәтергә! Башаяк, бар, җәһәт кенә явызлык биштәрен алып кил!
Башаяк. Башөсте, Баштүрәм. Хәзер алып киләм. *(Китмәкче була да туктап кала.)* Баштүрәм, явызлык биштәре Яңаел кулында бит.
Баштүрә *(үз башына сугып ала).* Аһ, шайтан алгыры, ялгыштык... Затлы коралсыз калдык...
Башия. Качыгыз! Үтерәләр!

Бүлмәдә ыгы-зыгы куба. Этешәләр, төртешәләр, качарга урын эзләп азапланалар. Җил-җил атлап Яңаел, Илдус һәм Айрат керә.

Айрат. Баскан җирегездән кузгалмагыз!
Илдус *(Баштүрә янына килә).* Ялгышмасам, син Баштүрә буласыңдыр инде? Җә, әйт әле, сөенечләр биштәрен кая куйдыгыз?

Баштүрә дәшми.

Быел. Биштәр кайда дип сорыйлар синнән?

Баштүрә. Билләһи-валлаһи, затлы башым белән ант итәм: мин алмадым, мин күрмәдем.

Яңаел. Биштәрем... Сөенечләрсез нишләрмен инде?

Илдус *(Башия янына килә)*. Ә син, ялгышмасам, Башия буласың бугай?

Башия. Әйе, мин Башия булам, хөрмәтлем.

Айрат. Биштәр кая?

Башия *(Баштүрәгә карап ала. Тегесе астан гына йодрык күрсәтә)*. Минават, хөрмәтлем. Күрмәдем, белмәдем...

Илдус. Тә-ә-әк... *(Башаяк янына килә.)* Ә син...

Башаяк. ...Башаяк булам. Гомердә кеше әйберенә кул сузганым булмады — мин алмадым.

Яңаел. Синмени инде ул — «шаян малай»? Мине алдалап, сөенечләр биштәрен алып китүче Башаякбаштүрәм...

Башаяк. Гомердә алдаганым булмады. Беренче тапкыр күрәм сине.

Айрат. Аһ, явыз, алдакчылар! Мин сезне хәзер...

Быел. Кирәкми, Айрат, тукта! Дошманны үз коралы белән акылга утыртырга кирәк.

Илдус. Әйе, Быел дус, дөрес әйтәсең. Боларның явызлык биштәре безнең кулда бит. Хәзер мин шул биштәрнең авызын чишәм дә печтек кенә явызлык чыгарам. Ул явызлык, без ни теләсәк, шуны эшләячәк.

Биштәр авызын ачып яба. Бер урында хәрәкәтсез басып торган Башаяк белән Башия явыз кыяфәткә керәләр. Башаяк Баштүрә янына йөгереп килә дә аның артына тибә.

Баштүрә *(ярсып кычкыра)*. Нишлисең син, тинтәк? Миңа түгел, әнә тегеләргә тип!

Башаяк. Әһә, эләктеңме? Мә, минем затлы аягымның тәмен татып карале. *(Баштүрәгә тагын тибә.)*

Баштүрә егыла. Шуны гына көтеп torгандай, Башия аңа менеп атлана.

Башия. На-а, малкай! На-а!

Баштүрә. Тыегыз бу хөрәсәннәрне! Үтерәләр бит!

Айрат. Сөенечләр биштәре кая?

Баштүрә *(Башияне атландырып йөри-йөри)*. Мин... ал...мадым... Башаяк алды... Ул... котыртты...

Башаяк. Әһә, мә тагын берне. *(Тибә.)*

Тәмам хәлсезләнгән Баштүрә идәнгә сузылып ята.

Баштүрә. Үт... үт... терәләр! Кот... кот... карыгыз!

Быел Илдуска туктарга ишарә ясый.

Илдус. Явызлык! Биштәргә кире кайт!

Илдус биштәр авызын ачып яба. Башия белән Башаяк элекке хәлләренә кайта. Баштүрә көч-хәл белән генә торып баса.

Баштүрә *(Башия белән Башаякка карап)*. Хөрәсәннәр...

Яңаел. Йә, Баштүрә, минем биштәрем кайда инде?

Баштүрә *(башы белән ымлый)*. Минем затлы сейфымда. Хәзер ачам...

Кесәсеннән зур ачкыч ала да сейфны ача.

Яңаел. Биштәрем! *(Сейфтан биштәрен ала.)* Урра! Биштәрем табылды. Тизрәк чыршы бәйрәменә ашыгырга кирәк!

Илдус. Әйе, ашыгырга кирәк! Минем шигырь дә ятлыйсым бар әле.

Быел. Миңа да бәйрәмдә кешеләр белән саубуллашырга кирәк.

Айрат. Әйдәгез!

Китмәкче булалар.

Баштүрә. Туктагыз! Без сезнең биштәрне бирдек. Сез безнекен кире кайтарыгыз.

Быел. Юк инде. Анысы булмас. Мин ул явызлык биштәрен үзем белән алып китәм. Киләчәктә явызлык булмаска тиеш!

Башия. Хе... Явызлык булмагач, безгә Баштүрә дә кирәкми. Урра! Баштүрә безне буйсындыра алмый. *(Баштүрәгә телен чыгарып күрсәтә.)* Моннан соң мин Башия булмаячакмын. Баширә булачакмын! *(Яңаелга карап.)* Мине дә үзегез белән алыгыз. Минем дә чыршы бәйрәмендә катнашасым килә!

Яңаел. Алабызмы, дуслар?

Быел, Илдус, Айрат *(өчесе бергә)*. Алыйк, әйдә.

Башаяк. Мин дә Башаяк булмыйм. Басыйр булам. Алыгыз мине дә!

Яңаел. Әйдә!

Китә башлыйлар.

Баштүрә. Ә мин? Ә мин?! Явызлыкларым, буйсынучыларым булмагач, мин нишлим инде хәзер? Мине дә алыгыз!

Яңаел җыр башлый. Калганнар аңа кушыла. Җырлый-җырлый китәләр. Баштүрә дә аларга иярә.

Җыр тавышы. Бигрәкләр дә матур дөнья! –
Җиргә аклык бөркелә...
Гүзәллеккә таңнар калып,
Бер елмаям, бер көләм...

Пәрдә.

# БЕЗ БАРАБЫЗ БӘЙРӘМГӘ

(НАШАЛАР:

*Әкият-пьеса)*

КАТ
Кыш малай
Кар күбәләк
Кыш бабай
Кар кызы
Марс
Чулпан
Аю
Бүре
Төлке
Куян
Җәнлек-җанварлар

БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Мәһабәт ак сарай күренеше. Сарай тәрәзәләренең йөзлекләрендәге бизәкләр кар бөртекләрен хәтерләтә. Ике ак мәрмәр баганалы болдыр кыегында «Вакытстан сарае» дип язылган неон утлар уйнаклый. Ап-ак бакча: ак чыршылар, кар чәчәкләр үсеп утыра. Бер читтәрәк фонтан күренә, аннан кар бөртекләре сибелә. Аллеяларда — ак эскәмияләр... Кыскасы, мондагы һәрнәрсә әкияти ак дөньяны хәтерләтә. Кинәт сарай ишеге ачыла. Аннан сөмсерләре коелган ике яшүсмер — актан киенгән Кыш малай белән Кар күбәләк килеп чыга. Кыш малайның кулында — глобус.

Кыш малай (*кулындагы глобусны ваемсыз гына зырылдата*). Уф, тагын барып булмады! (*Глобусны читкә ыргытмакчы була*.)

Кар күбәләк (*Кыш малайның кулыннан тота*). Юк, юк, Кыш малай, ыргыта күрмә. Ярамый!

Кыш малай. «Ярамый, ярамый!..» Ярамаганын беләм лә!.. Ачу килә бит. Былтыр булды былтыр баралмадык. Инде менә быел да өметебез сүнде... Һаман безне баласыталар...

Кар күбәләк. Тиз генә үсә алмаганыбызга без гаепле түгел инде, иеме, Кыш малай?!

Кыш малай. Үстек бит инде. Тагын күпме үсәргә була?

Кар күбәләк. Сиңа да унике яшь инде, иеме? Миңа да.

Кыш малай. Нишләп унике генә булсын! Бер елдан унөч яшь тула абзаңа! Син минем яшемне кечерәйтмәле, яме, Кар күбәләк!

Кар күбәләк. Менәтрәк! Нишләп кечерәйтим ди! Ике елдан минем үземә дә ундүрт яшь тула.

Шулвакыт сарай эчендә көлешкән тавышлар ишетелә.

Кыш малай (*ишек тарафына ишарәләп*). Алар бәхетле-е! Алар бәйрәмгә бара! Әйдә, китик... Безне күреп, безнең баралмаганны белеп сөенмәсеннәр әле...

Ишектән глобус тоткан Кыш бабай белән иңсәсенә нәни букча аскан Кар кызы чыга.

Кар кызы. Менә, ниһаять, син дә, чал Гасыр бабай әйтмешли, тулы вә-ка-ләт-ле Кыш бабай булдың!

Кыш бабай. Ә син — Кар кызы! Каяле, дүкәмитләргә тагын бер күз йөртеп алыйк әле.

Кар кызы (*букчасыннан кәгазьләр ала*). Әле генә караган идек бит инде, Кыш бабай... Гелән-гелән карап, дүкәмитләрне таушалдырып бетермәгәек.

Кыш бабай. Борчылма, Кар кызы. Тагын бер караганнан гына таушалмый ул! Йәле,ниләр язылган анда? Укып җиффәр әле!

Кар кызы. Монда бик матур сүзләр генә язылган инде, Кыш бабай.

Кыш бабай (*глобусны кочаклап, аны назлап-иркәләп*). Укы син, укы! (*Рәхәтләнеп тыңларга әзерләнә.*)

Кар кызы (*кәгазь әйләндереп карый-карый*). Нинди әйбәт кәгазьгә язганнар... Шоп-шома! (*Укый.*) «Яңа ел гали-җә-нап-ләре...»

Кыш бабай (*Кар кызына карап, башын иеп ала*). Без, ягъни мәсәлән...

Кар кызы. Әйе... «Яңа ел гали-җә-нап-ләре... Кыш бабай белән Кар кызы...» (*Реверанс ясап ала.*) Мин, ягъни мәсәлән... (*Укуын дәвам итә.*) «...Татарстанның Олы Имән урманында узачак бәйрәм тантанасына җибәрелә...»

Кыш бабай. Шә-ә-әп!

Кар кызы (*кәгазьләрен букчага сала да кулларын чәбәкләп ала*). Искиткеч!

Кыш бабай (*кулындагы глобусны әйләндерә*). Карыйк әле, кай тирәдәрәк микән ул Олы Имән урманы? Тә-ә-әк... (*Икәүләшеп глобуска карыйлар.*) Әһә! Менә — Та-тар-стан... Татарстан... Матур исем, әйеме? (*Кар кызы «әйе» дигәнне белдереп башын селкеп ала.*) Әһә, таптым! (*Бармагы белән глобуска төртә.*) Менә ул — Олы Имән урманы!

Кар кызы. Күңелем сизә — бик гүзәл урман булырга тиеш!

Кыш бабай (*бармагын Кар кызының борын очына тидереп ала*). Нәфис борыным сизсә сизә инде! — диген...

Кар кызы (*күңеле булып*). Шаяртмале, Кыш бабай.

Кыш бабай. Куанычтан шаяртасы гына килеп тора шул, Кар кызы.

Кар кызы. Җырлап та җибәрмисеңме соң, Кыш бабай?

Кыш бабай. Ә нигә? Җырлыйбыз да без аны! Биеп тә җибәрәбез!

Дәртле, шаян көй агыла. Кыш бабай җырлый башлый. Ул җырлаган чакта салмак кына карлар ява. Кар кызы башта кул чабып тора.

Кыш бабай. Карлар ява тын гына,
Әйлән-бәйлән итәләр...
Кыш бабайны...

Кар кызы (*җырга кушыла*).
...Кар кызын...

Кыш бабай. Һәммә җирдә көтәләр...

Җырның соңгы ике юлын янә кабатлыйлар.

Икесе бергә. Карлар ява тын гына,
Карлар куна учларга...
Ак бәхетләр, шатлыклар —
Бездән теләк дусларга!..

Соңгы ике юлны үзгәртеп җырлыйлар.

Кыш бабай. Якты җырлар...
Кар кызы. ...шат җырлар —
Икесе бергә. Бездән бүләк дусларга...

Җыр көе акрын гына ераклаша, сүнә.

Кыш бабай. Ашыгыйк, Кар кызы. Юлга кузгалырга кирәк. Аңарчы, өйгә кайтып, биштәрне дә аласы бар.

Кар кызы. Тылсымлы таягыңны да онытмыйк тагы!

Кыш бабай. Әйе шул. Әле ярый исемә төшердең... Киттек әйдә!

Кар кызы. Киттек, Кыш бабай!

Китәләр. Кыш малай белән Кар күбәләк яшеренгән урыныннан чыга.

Кыш малай. Шатланган булалар...

Кар күбәләк. Алар урынында без булсак, без дә сөенгән булыр идек, иеме, Кыш малай?!

Кыш малай. Әле ничек кенә сөенгән булыр идек! Ичмасам, менә шушы тирәгә булса да җибәрмәде безне чал Гасыр бабай... (*Глобусның кул тоткасына төртеп күрсәтә.*)

Кар күбәләк. Син нәрсә, Кыш малай! Анда беркем дә яшәми бит!

Кыш малай. Әй лә... Аптыраганнан әйтәм инде...

Кар күбәләк. Аптыраган-йөдәгән, артын мичкә терәгән!

Кыш малай. Терәрсең дә монда! (*Әрле-бирле йөренә. Кинәт үз башына сугып ала да кычкырып җибәрә.*) Эв-ри-ка! Таптым!

Кар күбәләк. Нәрсә таптың, Кыш малай?

Кыш малай. Таптым! Яңа ел бәйрәменә бару җаен таптым!

Кар күбәләк. Әйт инде тизрәк, Кыш малай!

Кыш малай. Таптым... Без дә бәйрәмгә барабыз!

Кар күбәләк. Ничек итеп?

Кыш малай. Очып китеп!

Кар күбәләк. Ничек... очып?

Кыш малай. Глобусны кочып!

Кар күбәләк. Шаяртмале, Кыш малай...

Кыш малай. Ә мин шаяртырга уйламыйм да! Беләсеңме, без дә Олы Имән урманына барабыз!

Кар күбәләк. Безнең... дүкәмит юк бит, Кыш малай!

Кыш малай. Ә без дүкәмитсез барабыз.

Кар күбәләк. Дүкәмитсез безгә кем ышансын.

Кыш малай. Ышанырлар... Ышандырырбыз!

Кар күбәләк. Соң бит... Анда алар да... Кыш бабай белән Кар кызы да булачак!

Кыш малай. Алар кыймылдаганчы, без әллә кайчан анда булабыз инде! Җырла, әйдә, Кар күбәләк... әй лә... Кар кызы! (*Үзе җырлый башлый.*)

Мин дә кидем ак оек,
Син дә кидең пар оек...

Кар күбәләк (*җырга кушыла*).

Әйдә, киттек бәйрәмгә!
Әйдә, тизрәк барыек!..
Карлар яусын тын гына,
Кунсын алар учларга...
Без үзебез — шәп бүләк
Көтеп алган дусларга!..

Җырның соңгы ике юлын болар да янә бер мәртәбә кабатлыйлар.

Кар күбәләк. Кыш малай, син, барабыз-барабыз, дисең дә бит... Безнең бәйрәмдә кия торган киемнәребез юк ич. Киемсез безгә беркем дә ышанмаячак!

Кыш малай. Борчылма, Кар күбәләк... әй лә... Кар кызы. Син миңа таян!

Кар күбәләк, Кыш малайның соңгы сүзләрен туры мәгънәсендә аңлап, аның кайсы төшенә таянырга белмичә тора. Ниһаять, ул аның иңсәсенә таяна.

Кыш малай (*гаҗәпсенеп*). Нишлисең син, Кар күбәләк?

Кар күбәләк. Соң... Миңа таян, дисең ич!

Кыш малай. Һәй, тиле кызый... Мин бит сиңа акыллы өлкәннәр шикелле образлы итеп кенә әйттем.

Кар күбәләк. Ә-ә-ә... образсыз итеп кенә әйтсәң ничек була?

Кыш малай. Образсыз итеп әйтсәк, болай була: син минем тылсымлы сүзләр белүче оста икәнемне беләсең бит инде?..

Кар күбәләк. Беләм, беләм...

Кыш малай. Мин менә шундый сүзләр әйтүгә, минем өстә — Кыш бабай киеме, синең өстә Кар кызы киеме була да куя! Аңлаганскимы?

Кар күбәләк. Башта ук шулай образсыз итеп кенә әйтәләр аны. Менә хәзер аңлашылды.

Кыш малай. Аңлашылса, киттек алайса.

Кар күбәләк. Кит-тек! Олы Имәнгә — бәйрәмгә!

Җитәкләшеп чыгып китәләр.

## ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Матур итеп җиһазланган авыл өе эче. Стенага календарь эленгән — анда «31 декабрь» дигән язу шәйләнә. Көзге каршысына басып, үзенә соклана-соклана, Чулпан җыр җырлый.

Чулпан. Аяз күктә ай йөзә,
Йолдызлар җем-җем яна.
Сибелә якты нурлар
Төнге зәңгәр дөньяга...

Ишек тарафында кулына кәшәкә тоткан Марс күренә. Ул, ишек борысына сөялеп, җырны тыңлый.

Ай йөзгән күк йөзендә
Бер йолдыз булсаң иде...
Җем-җем янып, дөньяга
Нур сибеп торсаң иде...

Кинәт, Марсның кәшәкәсе кулыннан ычкынып, идәнгә шапылдый. Чулпан сискәнеп борыла.

Чулпан. Ай!

Марс. Мин ай түгел — (*сүзгә басым ясап әйтә*) планета! (*Кәшәкәсен иелеп ала.*) Марс мин! Ә син — борчак хәтле йолдызчык! Чулпанчик ягъни!

Чулпан. Куркыттың ич!

Марс. Пардон, мерсимадам! Мин түгел, менә бу таяк куркытты сине! Гафу ит син аны, пажалысты!

Чулпан (*көлеп җибәрә*). Бу кисәү таягы синекедер ич?

Марс. Бу... син әйткән әллә нинди... кисәү таягы түгел... Бу — кәшәкә бу!

Чулпан. Кәкре булгач, барыбер инде... Синекедер бит?

Марс. Минеке! Кемнеке булсын тагы?

Чулпан. Шулай булгач... Димәк, мине син куркыткан булып чыгасың инде...

Марс. Ярар. Синеңчә булсын. Тагын бер мәртәбә гафу ит. Карале, син әйбәт кенә җырлыйсың икән бит. Миңа ошады.

Чулпан (*оялып кына*). Рәхмәт.

Марс. Син үскәч Казанга кил. Мин сине җырчы итәм. Мине Казанда бөтен кеше белә. Көн саен телевизордан җырларсың... «Әлли-бәлли-бәү»дә!

Чулпан. И мактанчык!

Марс. Мин мактанчик булсам, син — Чулпанчик! Икебез дә — «чик-чик»!

Чулпан. Мактанчик түгел, мак-тан-чык!

Марс. Үзең әйткәндәй, барыбер инде.

Чулпан. Бармыйм мин синең Казаныңа.

Марс. Нигә?

Чулпан. Шәһәрдә куркам мин.

Марс. Курыкма. Минем машинага гына утырып йөрерсең.

Чулпан. Китчәле, мактанчык! Синең машинаң юк бит.

Марс. Булмаса — булыр. Әти алып бирә аны миңа. Вилсәпид алырлык акчабыз бар инде безнең!

Чулпан. Синең әле вилсәпидең дә юкмыни?

Марс. Минеке юк, дус малайныкы бар... Әй, миңа вилсәпид кирәкми лә... Машина кирәк миңа!

Чулпан. Син әле машинаны йөртә дә белмисеңдер?

Марс. Өйрәнәм мин. Айн момент! Йә, утырасыңмы минем машинага?

Чулпан. Башта — үс, машина ал, аннан карармын...

Марс. Карыйсы юк. Минем машинага утырасың да җырлап кына йөрисең...

Чулпан. Әй лә — утырмыйм. Куркам. Йә берәр баганага бәрелерсең...

Марс. Минме? Бәрелде ди! Мин бит сигналны кычкыртам! Пип-пип!

Чулпан (*көлеп*). Шуннан соң багана читкә тайпыламы?

Марс. Тайпыла, тайпыла! Тайпылмаса, тормозга басам! Карале, аптыратмале шул баганаң белән... Мин бит сине алырга кергән идем. Әйдә, минем белән барасыңмы?

Чулпан. Кая?

Марс. Урманга. Чыршы бәйрәменә. Шунда җырларсың да.

Чулпан. Нинди чыршы бәйрәме? Урманда андый бәйрәм була димени? Авылда була ич ул!

Марс. Авылда да була, шәһәрдә дә. Beләсең килсә, урманда да була!

Чулпан. Анда кемнәр бәйрәм итә соң? Урман җәнлекләреме?

Марс. Әһә! Бүреләр, төлкеләр, куяннар...

Чулпан. Әйем лә... Мин бармыйм. Куркам.

Марс. Курыкма. Мин барында сиңа беркем дә тимәс!

Чулпан. Ә син кайдан белдең?

Марс. Нәрсәне?

Чулпан. Бүген урманда бәйрәм буласын.

Марс. Бабакай әйтте. Әллә син аның урманчы икәнен оныттыңмы? Ул бөтенесен дә белеп тора. Йә, барасыңмы инде минем белән? Әгәр бармасаң үзем генә китәм.

Чулпан (*икеләнеп кенә*). Барам. Тик... мин барыбер куркам. Бүре тисә?

Марс. Курыкма, дип әйттем бит инде мин сиңа. Бабакай әйтә, бүреләр әйбәт кешеләргә тимиләр, ди. Миңа тимиләр дә тимиләр инде... Чөнки мин — шәп кеше! Син дә әйбәттер бит?!

Чулпан. Бел-мим... Ул турыда уйлаганым булмады.

Марс (*Чулпанны баштан-аяк күздән кичерә*). Болай... әйбәт кешегә охшагансың. Сиңа тимәскә тиешләр. Аннан соң син бүген бәйрәм көн икәнен онытма! Кайсы җүләрнең бәйрәмнең ямен җибәрәсе килсен. Әйдә, кыймылда. Соңга калмыйк тагы!

Чулпан. Мин әле матур киемнәремне дә кимәгән...

Марс. Киен соң!.. Җылырак киен. Салкын тидереп өйдә ятарлык булмасын! Карале, син берәр битлек тә ал инде, яме. Мин бүре булып киенәм.

Чулпан. Ярар, куян булып киенермен, алайса. Син аз гына көтеп тор.

Марс. Аз да түгел, күп тә түгел — биш секунд вакыт сиңа!

Чулпан. Биш секунд? Биш секундта мин сыңар катамны да киеп өлгерәлмим ич!

Чулпан киемнәрен алып кия башлый.

Марс. Өлгерерсең, нибуч! (*Ишетелер-ишетелмәс кенә көйли.*)
Аякта киез ката,
Атлаган саен бата...

Ут сүнә.

ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Урман клубы. Бәйрәмчә җиһазланган. Урта бер җирдәрәк матур итеп бизәлгән чыршы тора. Тиз-тиз атлап, көлешә-көлешә, Бүре белән Куян килеп керә. Икесе дә букча тоткан.

Бүре (*як-ягына каранып ала*). Башкалар килеп җитмәгән икән әле. Без синең белән — беренчеләр!

Куян. Килерләр, әле вакыт бар бит.

Бүре. Назлыгөл, син бәйрәмгә кем булып киенәсең?

Куян. Белер идең бугай? Белмичә генә тор әле, яме.

Бүре. Әйт инде. Бәйрәмдә барыбер беләм бит.

Куян. Алдан әйтсәң, кызыгы бетә аның.

Бүре. Ә мин, беләсеңме, кем булып киенәм?

Куян. Әйтсәң беләм.

Бүре. Сиңа гына әйтәм. Бүтәннәргә әйтмә, яме? Мин шәһәрдән авылга кунакка кайткан малай булып киенәм. (*Букчасын күрсәтә.*) Киемнәр таптым инде.

Куян. Ә мин... ә мин... Әй, әйтмим әле...

Бүре. Әйт инде, Назлыгөл. Мин әйттем бит.

Куян. Башкаларга әйтмисеңме соң?

Бүре. Юк инде, юк. Ант менә!

Куян. Мин... авыл кызы булып киенәм. Чулпан булып!

Бүре. Чулпан? Кайсы... Теге... Куркак кызыймы ул? Быел җәй көне җиләккә килгәч, мине күреп, «Карауы-ыл!» дип кычкырып, тырысын ташлап качканые... Шулмы?

Куян. Әйе инде, әйе. Нәкъ шул булып киенәм. Тик син бүтәннәргә әйтмә, яме?

Бүре. Ярар, дидем бит инде. Ул куркак кызый җырлый да беләдерие түгелме соң?

Куян. Белә. Бик матур җырлый.

Бүре. Сине, алайса, бәйрәмдә җырлатабыз икән.

Куян. Мин җыр өйрәндем инде. Җырлап күрсәтимме?

Бүре. Җыр тыңларга яратам мин. Әйдә, сиптер әйдә!

Куян (*җырлый*).
Аяз күктә ай йөзә,
Йолдызлар җем-җем яна.
Сибелә якты нурлар
Төнге зәңгәр дөньяга...

Бүре (*кул чаба*). Шәп җырлыйсың икән бит син дә!

Куян. Мин бит Чулпан булып кына җырладым. Бөтенләй җырлый белмим мин...

Бүре. Сиңа әртис кенә буласы калган... Зерә әрәм булып ятасың син безнең Олы Имән урманында.

Куян (*мактаганга күңеле булып*). Ул хәтле үк үтереп мактама инде, Бүринур. Борыным күккә тия ич.

Бүре. Җәл, мин дә синең шикелле җырлый белмим.

Куян. Аның каравы, син такмак әйтә беләсең. Сөйләле берәр такмак.

Бүре. Такмак — такмак кына шул... Җыр түгел... Ярый инде, бик кыстагач, бер такмак сөйләми булмас.

Югары очтан түбән очка
Бер көчек өреп кайта...
Сукыр тычкан китап укый,
Мәче кикереп ята.

Куян (*көлә-көлә кул чәбәкли*). Тагын берне, тагын берне сөйлә инде!

Бүре. Су эчендә печән чаба
Ике сарык, бер тәкә.
Бүре буй үстергән чакта
Кайда идең, бүтәкә?..

Куян (*эчен тотып көлә*). Уф! Көлдереп үтерәсең ич, Бүринур...

Бүре (*көлә*). Үлә күрмә, Назлыгөл. Мине минават итәрсең җә!..

Шулвакыт тышта көлешкән-сөйләшкән тавышлар ишетелә.

Куян. Киләләр. (*Тәрәзәгә карый.*) Аю белән төлке килә!

Ут сүнә.

## ДҮРТЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Кышкы урман аланы. Агачлар, куаклар. Сул тарафтарак — киселгән төп. Урта бер җирдә үсеп утырган куак янәшәсендәге баганачыкка «Урман клубы» дип язылган күрсәткеч такта беркетелгән. Баганачык янынннан ике юл китә. Мышкылдый-мыш- кылдый, сул яктан Кыш малай белән Кар күбәләк килеп керә.

Кар күбәләк. Уф! Мин арыдым, Кыш малай. (*Агач төбенә утыра.*) Барып җитәбезме инде?

Кыш малай. Әз генә түз инде, Кар күбәләк. (*Күрсәткеч такта янына килә.*) Менә монда юлны күрсәтүче такта да беркетелгән икән. Әйдә, әйдә, Шүрәле карчыгы шикелле утырма җәелеп!

Кар күбәләк. Аз гына ял итеп алыйм инде, Кыш малай... Арыдым бит!

Кыш малай. Барып җиткәч, иркенләп ял итәрбез. Әйдә, әйдә!

Кар күбәләк авырлык белән генә урыныннан кузгала.

Кар күбәләк. Күтәреп бар инде мине, Кыш малай. Син бит арымаган...

Кыш малай (*сукранып*). Болай җәфа буласыңны белгән булсам, сине ияртми идем мин. Әйдә, кил, җилкәгә асылын!

Кар күбәләк (*Кыш малайның җилкәсенә ятып*). Син — такси ди, иеме, Кыш малай?

Кыш малай. Әһе. Ике аяклы такси! (*Бер-ике адымны көчкә атлый.*) Ай-яй авыр... Бер тонна бардыр син?!

Кар күбәләк. Тун авыр минем. Үзем ярты кило да юк мин.

Кыш малай. Белмим, белмим... Ярты киломы син, ике граммы... Әмма сине сөйрәргә чаналы трактор кирәк. Монысы — факыт! Төш, әйдә... Болай итеп барып булмый. Җитәклим генә.

Бераз җитәкләшеп баргач, Кыш малай, тукталып, артына борылып карый.

Кар күбәләк. Ник тукталдың, Кыш малай?

Кыш малай. Бара тор, Кар күбәләк. Мин хәзер.

Кар күбәләк, артына карый-карый, бара тора. Кыш малай күрсәткеч такта янына килә дә аңа бер тын карап тора. Аннан баганачыкны куак төбенә таба авыштыра. Тиз генә Кар күбәләк артыннан йөгерә.

БИШЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Шул ук күренеш. Кыш бабай белән Кар кызы керә. Кыш бабай аркасында биштәр, кулында — тылсымлы таяк.

Кар кызы. Нинди гүзәл урман, әйеме, Кыш бабай?

Кыш бабай. Нәкъ син сизенгәнчә инде, Кар кызы. Әйдә, ял итеп алыйк әле бераз.

Икесе дә бер төп өстенә җайлашып утыралар. Кыш бабай таягын читкә куя.

Кар кызы. Җәнлекләр безне көтә-көтә көтек булганнардыр инде?!

Кыш бабай. Көтәләр инде, Кар кызы, көтәләр. Синең белән мине һәрбер җирдә шулай көтеп алалар. Борын-борын заманнардан бирле килгән гореф-гадәт. Алар көтә, без киләбез!

Кар кызы. Бүләкләр алып, әйеме, Кыш бабай? (*Кыш бабайның биштәренә җиңелчә генә сугып ала.*) Монда бүләкләр барысына да җитәрлек!

Кыш бабай. Артып та кала әле.

Кар кызы. Чынлапмы? Аларын нишләтәбез?

Кыш бабай. Аларын да өләшеп бетерәбез. (*Көлә.*) Кире алып китмәбез бит инде.

Кар кызы. Мин Яңа ел бәйрәмен шундый яратам, Кыш бабай, шундый яратам! Ә син?

Кыш бабай. Яңа ел бәйрәмен яратмаучылар юктыр аны, Кар кызы?! Мондый искиткеч бәйрәм елга бер генә килә бит!

Кар кызы. Әйдә инде, Кыш бабай, атлый торыйк! Минем тизрәк бәйрәм тамашасында буласым килә!

Кыш бабай. Син, Кар кызы, бер генә дә арымадыңмыни соң?

Кар кызы. Юк, Кыш бабай, кечтеки генә дә арымадым.

Кыш бабай. Маладис та инде син, Кар кызы! Мәрхәбә! Синең белән бергә бару — үзе бер бәйрәм! Әйдә, кузгалыйк булмаса...

Икесе дә урыннарыннан торалар. Кыш бабай таягын алырга оныта.

Кар кызы (*ике тарафка китүче юлга карап*). Кыш бабай, монда юллар икәү бит! Кайсысы белән барабыз?

Кыш бабай *(юлларга карап тора-тора да)*. Монысыннан китәрбез, шәт. (*Кыш Малай белән Кар Күбәләк китмәгән юлга таба ишарәли.*) Шушы юл илтер безне, мөгаен...

Китәләр. Алар китүгә, аланга Марс белән, курка-курка гына, Чулпан керә. Марсның җилкәсендә нәни биштәрләр — аларга бәйрәм киемнәре салынган.

Чулпан. Марс, мин куркам...

Марс. Курыкма, Чулпан, килеп җитәбез бит инде. Аз гына барасы калды.

Чулпан. Аз гына барасы калганын каян беләсең, Марс? Син бит — шәһәр малае!

Марс. Шәһәр малае булсам да, мин бит — урманчы оныгы! Бабай миңа юлны өйрәтте. Монда юл күрсәткеч булырга тиеш! (*Як-ягына каранып эзләнә, куак төбендә яткан багананы күреп ала.*) Әйттем бит — менә ул! Ауган. Җил аударгандыр инде. (*Торгызырга азаплана.*)

Чулпан (*төп янына килә, шуңа утырыйм дигәндә генә Кыш бабай онытып калдырган таякны күреп ала*). Таяк?! Марс, мин таяк таптым!

Күрсәткеч такталы багананы бастырып куйган Марс Чулпанга борылып карый.

Марс. Таяк? Нинди таяк ул? (*Чулпан янына килә дә таякны кулына алып, әйләндереп карый.*) Берәрсе онытып калдыргандыр моны.

Чулпан. Кыш бабайныкы түгел микән бу?

Марс. Син нәрсә, Чулпан, Кыш бабай таягын онытып йөрмәс инде!

Чулпан. Алай димә, Марс, бабайлар хәтерсез була алар.

Марс таякның түгәрәк башын, җентекләп караганда, ялгыш борып җибәрә. Кинәт аланга караңгылык иңә.

Чулпан тавышы. Ай! Нинди караңгы! Мин куркам, Марс...

## АЛТЫНЧЫ КҮРЕНЕШ

Караңгылык кинәт яктылык белән алышына. Тирә-юньдә яшеллек күзгә ташлана. Кыш бабай белән Кар кызы аптырап басып калганнар.

Кар кызы. Нәрсә бу? Без кайда, Кыш бабай?

Кыш бабай. Таяк! Минем тылсымлы таягым!

Кар кызы. Мин эссели башладым, Кыш бабай!

Кыш бабай. Кар кызы, мин бая таякны онытып калдырганмын бит! Һай, хәтерсез башкайларым! Кемдер шуны табып шаярта бугай. Әйдә, тизрәк, кире киттек!

Кар кызы. Мин эри башладым, Кыш бабай!

## ҖИДЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Бишенче күренештәге аланлык. Ул — шулай ук ямь-яшел. Чулпан аптырап Марска текәлгән.

Чулпан. Марс, ни булды урманга? Нишләп барысы да ямь-яшел? Кыш кая китте?

Марс (*аптыраулы*). Белми-им... Мин бу таякның башын борган идем. Әллә бу таяктамы хикмәт?

Чулпан. Мин куркам, Марс...

Марс. Хәзер таяк башын кирегә борып карыйм. Бәлки, чыннан да Кыш бабай таягыдыр бу?!

Чулпан. Шуныкы инде, шуныкы! Кыш бабайның тылсымлы таягы! Тизрәк бор инде, Марс!

Марс таяк башын кирегә бора. Кинәт урманга янә караңгылык иңә. Аны янә яктылык алыштыра — урман аланы әүвәлге кышкы халәтенә кайта.

Марс. Кыз-зы-ык! Могҗиза дисәң дә могҗиза бу!

Чулпан. Мин куркам, Марс... Зинһар, урынына кире куй таякны. Бүтән боргалый күрмә.

Марс. Юк, таякны калдырмыйбыз. Үзебез белән алабыз. Моны, чынлап та, Кыш бабай калдырган булырга тиеш! Бәйрәмгә баргач, үзенә тапшырырбыз. Бәлки, эзли дә торгандыр инде. Әйдә, ашыгыйк!

Китәләр.

## СИГЕЗЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Урман клубының тышкы яны. Тәрәзә янында Кыш малай белән Кар күбәләк. Тәрәзә аша эчкә карыйлар.

Кар күбәләк. Чыршыны ничек матур итеп бизәгәннәр!

Кыш малай. Син бүрегә кара, бүрегә!

Кар күбәләк. Бүре? Кайда бүре? Мин аны күрмим ич!

Кыш малай. Әнә бит! Койрыклы малайга кара! Шул бит инде бүре. Малай кеше булып киенгән!

Кар күбәләк. Күрдем, күрдем! Ул бүремени? Мин аны бит, чынлап та, малай дип торам.

Кыш малай. Әнә тегесе — куян. Күрәсеңме? Кыска койрыклы кызга кара әле.

Кар күбәләк. Күрдем, күрдем! Аны да күрдем! Әйдә, без дә керик инде шунда!

Кыш малай. Ашыкма, йә ашка пешәрсең!

Кар күбәләк. Нинди аш? Анда аш күренми бит!

Кыш малай. Мин бит сиңа образлы итеп әйттем.

Кар күбәләк. Ә-ә-ә...

Кыш малай. Минем бит әле сихер-михер сүзләрен әйтәсем бар. Миңа — Кыш бабай, сиңа — Кар кызы булып керергә кирәк.

Кар күбәләк. Әйдә, алайса, мине тизрәк Кар кызы ит!

Кыш малай. Хәзер. Бас минем янга. Бир кулыңны.

Кулга-кул тотынышып басалар.

Кар күбәләк. Тизрәк, Кыш малай, тизрәк!

Кыш малай. Әчтер-печтер, чүпсәләй!.. Кыштыр-мыштыр, мүкҗәләй!.. (*Төчкерәсе килеп, авызын зур итеп ача*.) Әп... эп... әпчехи!.. (*Кабат төчкерә*.) Ә-ә-п-чехи!

Икесе дә кинәт сәер Кыш бабайга һәм сәер Кар кызына әйләнә: Кыш малай Кар кызы киеменнән, ак толымнан, ә Кар күбәләк — киресенчә, Кыш бабай киеменнән, сакаллы.

Кар күбәләк (*Кыш малайга бармагын төртеп көлеп җибәрә*). Си... синме Кыш бабай? Көлдереп үтерәсең ич!..

Кыш малай (*төксе генә*). Үзеңә кара башта! Аннан көләрсең...

Кар күбәләк (*үзенә карый, сакалын тоткалый*). Мин... мин... Ай! Мин кем, Кыш малай? Нишләттең син мине?

Кыш малай (*янә төчкерә*). Ә-ә-әп-чехи! Син дә клоун, мин дә клоун! Вәйт менә кемнәр без... Ә-ә-әпчехи!

Кар күбәләк. Миңа карап төчкермәле! Ә-ә-әпчехи!.. Нәрсә булды безгә?

Кыш малай. Сихри сүзләрне әйткәндә әпчехиләп ялгыштым... Шулай килеп чыкты...

Кар күбәләк. Хәзер нишлибез инде? Әйдә, тизрәк кабат әйт сихер-михереңне!

Кыш малай. Булмый. Бүтән әйтүдән файда юк. Ялгышырга ярамый иде миңа. Төчкерү харап итте.

Кар күбәләк. Алайса, тиз генә элекке халәтебезгә кайтара торган сихри сүзләреңне әйт!

Кыш малай. Файдасыз. Андый сүзләр көчсез хәзер. Их, ялгышырга ярамый иде миңа...

Кар күбәләк. Берәр нәрсә уйлап тап инде, Кыш малай. Сакал иякне кычыттыра башлады...

Кыш малай. Сиңа да, миңа да түзәргә туры килмәгәе!

Кар күбәләк. Кайчанга тиклем түзәргә?

Кыш малай. Кыш бабай килгәнче. Безне ул гына әүвәлге халәтебезгә кайтара ала.

Кар күбәләк. Ыз-драсте, кодагый! Килеп җиттек, алайса! Уеннан уймак чыгардык!

Кыш малай. Нинди уймак? Ни сөйлисең син?

Кар күбәләк. Бер ни дә сөйләмим. Синең шикелле... (*сүзгә басым ясап әйтә*) о-образлы итеп кенә әйттем...

Кыш малай. Ташлале. Шаярта торган чакмыни!

Кар күбәләк. Түү-тү, бәйрәм! Әллүк — кирегә! Барысы да синең аркада...

Кыш малай. Чәпчемәле син! Уйларга ирек бир.

Кар күбәләк. Башта ук уйлыйлар аны. Көймәң комга килеп терәлгәч түгел...

Кыш малай. Нинди көймә турында сөйлисең син? Ычкына башладың мәллә?

Кар күбәләк. Синең шикелле... (*янә басым ясап әйтә*) о-образлы итеп сөйлим ич!

Кыш малай (*ачуы килеп*). Чукындың инде шул образлы сүзләрең белән! Сине ияртКән мин җүләр!

Кар күбәләк. Ияртмәскә иде! Мин монда сакаллы тиле хәлендә калмас идем. Синең аркада бәйрәм күрәлми калам хәзер.

Кыш малай. Лыгырдама, дидем бит инде! Күрәбез ул бәйрәмне! Керәбез дә күрәбез.

Кар күбәләк. Шушы кыяфәт беләнме?

Кыш малай. Ә нигә? Шушы кыяфәт белән! Безнең бүтән юл юк. Әйдә, атла, ни булса — шул булыр... *(Ишеккә таба бара.)*

Кар күбәләк (*теләр-теләмәс кенә аңа ияр*ә). Күрәселәр алда икән әле!..

Клуб эчендә «Кыш бабай! Кар кызы! Тизрәк килегез!» дигән сүзләр ишетелә.

## ТУГЫЗЫНЧЫ КҮРЕНЕШ

Дүртенче күренештәге урман аланы. Кыш бабай белән Кар кызы әүвәл киткән юлларыннан уфылдый-уфылдый кире әйләнеп кайта.

Кар кызы (*агач төбенә килеп утыра*). Уф! Таякны онытуың аркасында күпме вакытны әрәм иттек, Кыш бабай...

Кыш бабай. Әйтмә дә инде, Кар кызы. Гафу ит, мин хәтерсезне. Интектереп йөрттем сине.

Кар кызы. Интегүен интекмәдем лә мин... Кайда соң таягың, Кыш бабай? Кай төштә калдырган идең? (*Як-ягына карана. Кыш бабай таягын эзли.*)

Кыш бабай. Менә шушы син утырган төп кырыена гына куйган сыман идем...

Кар кызы. Монда юк бит, Кыш бабай. Бүтән җирдә калдырмагансыңдыр ич?

Кыш бабай (*һаман эзләнеп*). Юк инде, Кар кызы, юк... Шушында гына куеп торган идем. Берәрсе тапкандыр да алып киткәндер инде, мөгаен... Хараплар гына булдык... Таяксыз Ак Сарайга кайтырга ярамый ич безгә!

Кар кызы. Син кайту турында уйлыйсың, Кыш бабай... Әле бит без бәйрәмгә дә барып җитмәгән!..

Кыш бабай. Барырбыз, Кар кызы, барырбыз. Бәйрәм дә күңелле узар. Анысына шикләнмим мин. Менә таяксыз калдык, таяксыз! Шуңа эч поша!..

Кар кызы. Хәзер нишлибез инде, Кыш бабай?

Кыш бабай. Алдан ук кайгырмыйк әле. Бәлки, берәр игелекле җан иясе кулына эләккәндер таяк?! Яхшыга өметләник. Табылыр, иншалла!

Кар кызы. Әйт сүзеңне, Кыш бабай!

Кыш бабай. Кузгалыйк без, Кар кызы. Көттермик дусларыбызны.

Кар кызы урыныннан тора. Күрсәткеч тактаны күреп ала.

Кар кызы. Кыш бабай! Карале, юл күрсәткеч! Баягынак юк иде шикелле...

Кыш бабай (*багана янына килеп*). Әйе шул. Юк иде, ә хәзер бар. Кызы-ык... Һәм сә-ер... Бу юл күрсәткеч дөрес күрсәтсә, без бит бая ялгыш юлдан киткән булып чыгабыз түгелме соң?

Кар кызы. Шулай шул, Кыш бабай!

Кыш бабай. Әле күпме адашып йөргән булыр идек... Болай булгач, онытылып калган таякка рәхмәт кенә укыйсы инде безгә!.. Әйдә, Кар кызы, ашыгыйк!..

Кар кызы. Әйдә, Кыш бабай!

Китәләр. Ут сүнә.

## УНЫНЧЫ КҮРЕНЕШ

Клуб эче. Җәнлек-җанварлар чыршы тирәли әйләнә-әйләнә кычкыралар:

— Кыш ба-бай!
— Кар кы-зы!
— Тиз-рәк ки-ле-гез!

Ишектән Кыш малай белән Кар күбәләк күренә. Җәнлекләр, аларны күреп, кинәт туктап калалар.

Кыш малай. Исәнмесез, дуслар?!
Кар күбәләк. Саумысез?!

Җәнлекләр бер-берсенә карашалар.

Җәнлекләр (*барысы бергә*). Ис... сәнме... сез!
Бүре (*кайсына карарга белмичә*). Ис... сәнме... Кыш бабай!
Куян (*күзләрен шарландырып*). Ис... сәнме... Кар кызы!
Кыш малай. Бәйрәмегез мөбарәк булсын!
Кар күбәләк (*үзе дә сизмичә сакалын сыйпый*). Әйе, түгәрәк булсын!
Аю. Бер... бергәләп узсын!
Төлке. Рә... рә... хим итегез!
Бүре (*Куянга пышылдый*). Син... берәр нәрсә аңлыйсыңмы?
Куян (*башын селки*). Юу-у-ук...
Кыш малай. Безне сагынып көткәнсездер инде, дуслар?!
Бүре. ...көттек, дип...
Куян. ...көттек инде!..
Җәнлекләр *(бергә)*. Ие, көттек инде!
Кыш малай. Атлап түгел, чабып килдек...
Кар күбәләк. Килә-килә арып беттек...
Кыш малай (*Кар күбәләккә пышылдый*). Мин тагын нәрсә дияргә тиеш әле?
Кар күбәләк (*җилкәсен сикертә*). Әллә тагы... Белмим...
Кыш малай (*җәнлекләргә*). Ә... әйе... Арый-арый килеп беттек!..
Кар күбәләк (*аның толымыннан тарта*). Ни сөйлисең син, Кыш бабай?
Кыш малай *(каушый, аптырап торган җәнлекләргә)*. Ә... әйе... Бетә-бетә килеп ардык!..
Куян (*«Кыш бабай» янына килә дә аның толымын тотып карый*). Син... Чынлап та, Кыш бабаймы соң?
Кыш малай. Кыш бабагыз инде, Кыш бабагыз... Яраткан Кыш бабагыз!
Бүре (*Кар күбәләкнең сакалын тотып карый*). Син дә... Кар кызымы?
Кар күбәләк. Әйе, Кар кызы мин!
Бүре. Ә нишләп сакалың бар синең, Кар кызы?
Кар күбәләк (*ни әйтергә дә белмичә тора*). Сакалмы? Әйе шул, сакалым бар минем. Мин бит... Ни бит...
Бүре (*кинәт сөенеп*). Ә-ә-ә... Белдем-белдем! (*Кыш малайга да, Кар күбәләккә дә карый-карый*). Сез бит... кызык булсын өчен шулай иткәнсез... Шулай бит?!
Кыш малай (*куанып, Бүренең башыннан сыйпый*). Башлы да икәнсең үзең! Әйе, без сезгә кызык булсын өчен шулай иттек! Дөрес әйтәмме, Кар кызы?
Кар күбәләк. Дөрес әйтәсең, Кыш бабай. Бик дөрес!
Куян. Ә-ә-ә-ә... Сезнең бүләкләрегез кайда соң, Кыш бабай?

Кыш малай белән Кар кызы бер-берсенә карашып алалар.

Кар күбәләк. Бүләкләр?!
Кыш малай. Нинди бүләкләр? Ә-ә... Бүләк-лә-әр?! (*Кар күбәләккә.*) Кайда безнең бүләкләр?

Кар күбәләк. Кайда дип... (*Кулы белән ишек тарафына ишарәли.*) Шунда инде, шунда!

Кыш малай. Ә... әйе... безнең бүләкләр... сезнең бүләкләр...

Кар күбәләк. Хәзер алып киләләр бүләкләрне.

Кыш малай (*җанланып*). Әйе, хәзер алып киләләр. Ярдәмчеләребез алып килә! Әйдәгез аңарчы нитә торыгыз... Һөнәрләрегезне күрсәтә торыгыз...

Куян. Синең, Кыш бабай, тылсымлы таягың да юкмы?

Кыш малай. Тылсымлы таяк? Нигә ул тылсымлы таяк?

Бүре. Чыршы утларын кабызырга!

Кыш малай. Ә-ә-ә... утларны кабызыргамы? Әйе шул, аларны кабызырга кирәк. (*Кар күбәләккә.*) Таяк белән кабызалармы аны?

Кар күбәләк (*җилкәсен сикертә*). Мин каян белим... Син бит Кыш бабай...

Кыш малай. Ни бит... дусларым... Тылсымлы таякны да бүләкләр белән бергә алып киләләр хәзер... Борчылмагыз, бөтенесе дә булыр: бүләкле таяклар да, таяклы бүләкләр дә...

Кар күбәләк (*Кыш малайга карап, аның бутап сөйләвенә аптырап, башын селкеп ала*). Гаҗәпләнмәгез, дуслар. Кыш бабай юлда килгәндә бик арыды. Арыганлыгы әнә теленә үк чыкты. Шуңа күрә бутабрак сөйли. Син ял итеп тор, Кыш бабай.

Кыш малай. Юк, юк, мин арымадым!

Кар күбәләк (*аны эткәләп*). Арыды, арыды! Хәзер ял итә ул. Урындык бирик әле Кыш бабайга!

Кемдер урындык китереп куя.

Кар күбәләк. Утырып тор, Кыш бабай! (*Пышылдабрак.*) Утыр инде җәтрәк! (*Җәнлекләргә карап елмая.*) Карт шул инде Кыш бабай. Бик тиз арырга гына тора... Шулай бит, Кыш бабай?

Кыш малай. Шулай, Кар кызы, дөрес әйтәсең... Арырга гына торам. Арымасам да арыйм, арысам да арыйм...

Кар күбәләк. Бабай хәл җыя торсын... Ә без... Әйдәгез, дуслар, чыршы тирәли әйләнеп җырлыйк әле!

Куян. Нинди җыр җырлыйбыз соң?

Кар күбәләк. Матур җыр җырлыйк. Сез башлагыз, мин кушылырмын.

Һәммәсе чыршы тирәли кулга-кул тотынышып баса. Кар күбәләк тә алар арасында. Җәнлекләр җыр башлыйлар.

Чыршы, чыршы, без сине,
Сагынып көттек ел буе.
Син тагын да матур булып,
Бизәлгәнсең бу юлы...

## УНБЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Урман клубының тышкы ягы. Марс белән Чулпан тәрәзә аша эчкә карыйлар. Марсның җилкәсендә — биштәр, бер кулында — Кыш бабай таягы.

Марс (*клуб эчендәге «Чулпан»ны күреп гаҗәпләнә*). Менә әкәмәт! (*Әле тәрәзәгә, әле Чулпанга карый.*) Анда да син, монда да син!

Чулпан (*ул да, гаҗәпләнеп, әле тәрәзәгә, әле Марска карый*). Әйе шул! Анда да син, монда да син!

Марс. Кыз-зык... Ничек була инде бу?

Чулпан. Мин дә — икәү... Син дә — икәү... Безнең күзгә генә күренәдер бу, Марс?!

Марс (*үз башына сугып ала*). Белдем, белдем! Барып җитте башыма.

Чулпан. Нәрсә белдең? Әйт инде тизрәк!

Марс. Беләсеңме, Чулпан, алар... (*тәрәзәгә ишарәли*) алар... без түгел! Алар мин дә, син дә түгел.

Чулпан. Кемнәр соң алайса?

Марс. Әнә, кара... Мин дигәне — бүре... Син дигәне — куян... Алар без булып киенгәннәр генә! Аңладыңмы инде, Чулпан?!

Чулпан. Әйе шул... Менә хәзер аңладым.

Марс. Ә без аларның үзләрен кызык итәбез хәзер...

Чулпан. Ничек итеп?

Марс (*биштәренә ишарәли*). Менә бу биштәрне мин тикмәгә генә күтәреп йөриммени? Монда бит без бәйрәмгә кия торган киемнәр! (*Таякны бер читкә куя да биштәрен сала*.) Бер минуттан мин — бүре, син куян булачаксың хәзер... Әйдә, киеник җәтрәк!

Киенә башлыйлар.

## УНИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Клуб эче. Җәнлекләр чыршы тирәли җырлый-җырлый әйләнүдән туктыйлар.

Куян. Кыш бабай, чыршыдагы утларны кайчан кабызасың инде?

Бүре. Безгә дигән бүләкләреӊ дә һаман килеп җитми.

Кыш малай. Ни бит... балалар... (*Кар күбәләккә*.) Әйт инде син дә берәр сүз...

Кар күбәләк. Хәзер килеп җитә безнеӊ бүләкләр... Тылсымлы таяк та хәзер монда булачак!

Кыш малай. Әйе... Борчылмагыз, балалар... Берегез дә бүләксез калмассыз...

Куян (*Кыш малайга сырпалана*). Миңа нинди бүләк бирәсең, Кыш бабай?

Кыш малай (*әле Кар күбәләккә, әле Куянга карап*). Сиңамы? Без сиңа... сиңа без... бүләк итәм... итәбез... Сиңа без...

Кар күбәләк (*аңа ярдәмгә килә*). Кыш бабай, нинди бүләк икәнен әйтмичә тор әлегә. Сер булып торсын!

Кыш малай. Дөрес әйтәсең, Кар кызы. Сер булып торсын әлегә...

Шулвакыт ишек тарафында бүре булып киенгән Марс, куян булып киенгән Чулпан пәйда була. Һәммәсе дә аларга текәлә.

Бүре (*Марска төртеп күрсәтә*). Бүре?!

Куян (*Чулпанга ишарәләп*). Куян?!

Марс белән Чулпан. Исәнмесез, дуслар!

Кыш малай (*Кар күбәләккә*). Кемнәр болар?

Кар күбәләк. Күрмисеңмени, Бүре белән Куян ич!

Бүре (*Марс янына килә*). Синме Бүре?

Марс. Әһә! Мин — Бүре!

Куян (*Чулпанга*). Ә син Куянмы?

Чулпан (*чигенә, Марска елыша*). Минме?

Куян (*үчекләгәндәй*). Юк, мин!

Чулпан. Син — Куян...

Куян. Ә син?

Чулпан. Мин дә Куян...

Марс. Әйе, ул — Куян. Ә мин — Бүре!

Бүре (*әтәчләнеп*). Син — Бүре түгел, мин — Бүре! Чын Бүре мин!

Кыш малай. Балалар, балалар! Әйткәләшмәгез! (*Бүрегә*.) Борчылма, син — Бүре, син!

Куян. Ә мин — Куян, чын Куян!

Кыш малай. Әйе, дөрес, син — Куян.

Кар күбәләк. Дуслар, тынычланыгыз әле. Юкка бәйләнмәгез. Болар бит Бүре белән Куян булып кына киенеп килгәннәр. (*Марс белән Чулпанга*.) Шулай бит?

Марс *(башын селки)*. Шулай, шулай.

Чулпан (*Марска елышып*). Без бит бәйрәмгә дип килдек. Ә сез безгә бәйләнәсез... Мин бит — Чулпан. Авыл кызы мин!

Марс. Ә мин — шәһәр малае. Марс мин! Авылга кунакка гына кайткан идем...

Ишектә Кыш бабай белән Кар кызы күренә. Бүлмәдәгеләр башта аларны күрмиләр.

Кыш бабай. Нишләп күңелсез әле сез, дуслар?

Һәммәсе дә керүчеләргә борылып карый.

Барысы бергә. Кыш бабай?! Кар кызы?!

Кыш малай белән Кар күбәләккә карыйлар. Тегеләр нишләргә дә белмичә басып торалар.

Кар кызы. Исәнмесез, дуслар!

Җәнлекләр (*аптырап кына*). Исән-ме-сез!

Бүре. Мин берни дә аңламыйм. (*Кыш бабайга*.) Син дә — Кыш бабай... (*Кыш малайга*.) Син дә — Кыш бабай... Ике Кыш бабай...

Куян (*әле Кар кызына, әле Кар күбәләккә карый*). Ике Кар кызы... Мин дә берни дә аңламыйм.

Марс. Сезнең кайсыгыз чын Кыш бабай соң? Кайсыгыз чын Кар кызы?

Кыш малай (*Кыш бабайга күрсәтә*). Ул... ул — Кыш бабай... Гафу итегез мине!

Кар күбәләк. Мин Кар кызы түгел... (*Кар кызын күрсәтә.)* Ул — Кар кызы... Без шаярттык кына... Без... без...

Кыш малай. Безнең бәйрәмдә катнашасыбыз килде. Бик-бик килде! Кичерегез безне, зинһар!

Куян. Их, сез!.. Алдакчылар!.. Шулай ярыймы инде?

Кыш бабай. Зыян юк, дуслар. Ачуланмыйк аларны. Күреп торасыз ич, гаепләрен таныдылар. Шулай бит, Кыш малай?

Кыш малай. Әйе, әйе... Без таныдык... Кичер, Кыш бабай!

Кар күбәләк. Гафу ит, Кар кызы.

Кар кызы Кар күбәләкнең чәчләреннән иркәли.

Марс (*кинәт*). Таяк! Тылсымлы таяк! Кыш бабай, без бит синең тылсымлы таягыңны тапкан идек! Мин хәзер!

Тиз генә чыгып китә дә тылсымлы таякны алып керә, Кыш бабайга бирә.

Кыш бабай. Рәхмәт яугыры! Менә бит, Кар кызы, таягыбыз да табылды.

Кыш малай. Кыш бабай, зинһар, әүвәлге халәтебезгә кайтар инде.

Кар күбәләк. Мине дә, Кыш бабай! Туйдым бу сакалдан! Кычыттыра да кычыттыра, кычыттыра да кычыттыра...

Кыш бабай. Хәзер, хәзер, дусларым! Тылсымлы сүзләремне әйтим әле... Чухырый-мухырый-бәйнәләй, кыштырый-мыштырый-әйләнәй!

Кыш малай белән Кар күбәләк әүвәлге халәтләренә кайта. Һәммәсе дә сөенешеп кычкыра.

Кыш малай. Рәхмәт, Кыш бабай!

Кар күбәләк. Рәхмәт сиңа, Кыш бабай. Ачуланма инде безне, яме!

Кыш бабай аларның башларыннан сыйпый.

Кыш бабай. Бүтән вакытны үз белдеклелегегез белән йөрмәгез, ярыймы?! Алайса, әллә нинди күңелсез хәлләргә таруыгыз бар...

Бүре. Кыш бабай, чыршы утларын кабызасыңмы инде? Вакыт җитте бит.

Кыш бабай. Ашыкма, Бүре...

Ул тылсымлы таякның башып бора да идәнгә дөп итеп төртеп ала, чыршыда утлар гөлт итеп кабына.

Барысы бергә. Ур-р-ра!

Кыш бабай. Яңа ел котлы булсын, дуслар!

Биштәрен ала да аннан бүләкләр чыгара башлый. Аларны Кар кызы өләшә.

Куян, Бүре (*икесе бергә*). Бәйрәм башланды. Әйдәгез, чыршы тирәли әйләнәбез!

Кыш малай. Әйдәгез!

Җәнлек-җанварлар, Марс белән Чулпан чыршы тирәли әйләнә башлыйлар. Көй агыла. Һәммәсе дә җырлыйлар:

Чыршы, чыршы, без сине
Сагынып көттек ел буе...
Син тагын да матур булып
Бизәлгәнсең бу юлы...

Җыр көчәя. Бәйрәм дәвам итә.

Пәрдә.

# УРМАНДАГЫ ТАМАША

КАТНАШАЛАР:

Чүрәле
Түрәле
Бүрәле
Тазамат
Хыялбай
Шартуар
Карату
Ала-Кола
Хәйбулат
Бики
Галия
Серле тавыш

Бакча. Алмагач төбенә Хыялбай сузылып яткан. Арка терәгечле эскәмиядә Тазамат китап укып утыра.

Хыялбай. Әгәр әнә теге зур алма... Юк, тегесе, бәләкәйрәге... кинәт өзелеп... минем башыма төшсә...

Тазамат (*китап укуыннан туктап*). Карале, Хыялбай, син ничек уйлыйсың, кайчан да булса диюләр, җиде башлы аждаһалар яшәде микән?

Хыялбай (*борылып карамый гына*). Юк... (*Сөйләнүен дәвам итә.*) ...Һәм мин, Ньютон шикелле, кешеләрне шаккаттырырлык...

Тазамат. Шүрәлеләр дә яшәмәде микән?

Хыялбай. Юк... ачыш ясасам! Йә булмаса җәй көне кар яудыра торган нәмәстәкәй уйлап тапсам...

Тазамат. Ә минем бабай әйтә, яшь чакта шүрәле күрдем, ди...

Хыялбай. Ялганлый ул синең бабаң. Әкият... Йолдызларга оча торган кораб уйлап тапсам ничек булыр икән?.. Төтен чыгаргычы итеп самавыр торбасы куйсам, иллә дә шәп булачак!

Галия керә. Малайларның сөйләшкәнен сиздермичә генә тыңлап тора.

Тазамат. Мин, нишләптер, әкияткә ышанам. Шүрәлеләр бардыр төсле. Ә син нигә әкият яратмыйсың, Хыялбай?

Хыялбай. Юк-барга ышанырга минем вакытым юк... Әгәр дә мин самавыр торбасы урынына... иске матайның төтен чыгаргычын куеп карасам...

Тазамат. Кызык, бүрәнә ярыгына бармагын кыстырган теге шүрәленең оныклары бар микән?

Галия (*сүзгә кушыла*). Бар! Берсе — син, икенчесе... (*Көлә.*) Икенчесе — Хыялбай!

Малайлар борылып Галиягә карыйлар.

Тазамат. Исәнме, Галия?

Галия. Исәнмесез-саумысыз, әтәчегез күкәй салган, нигә чыгып алмыйсыз?

Хыялбай. Бал корты дип торам, колак төбендә син безелдисең икән. Нәрсә кирәк? Йомышың булса, әйтмә... бабай әйтмешли, атчәливәй! Тазаматка укырга, миңа уйларга мишәйт итмә.

Тазамат. Миңа комачауламый ул. Утыр, Галия, эскәмиягә.

Галия. Утырсам, озак торам. Нишлиләр микән дип, хәлләрегезне белергә генә кергән идем.

Тазамат. Каникулда нишлиләр инде — ял итәләр. Менә без дә ял итәбез.

Хыялбай. Мин ял итмим, мин уйлыйм.

Галия. Без, кызлар, иртәгә урманга барабыз. Теләсәгез, сез дә безнең белән бара аласыз. Шүрәлеләр белән танышып кайтырсыз! (*Көлә.*)

Хыялбай. Мин бармыйм. Минем вакытым юк.

Тазамат. Әйтүең өчен рәхмәт, Галия. Мин барам. Хыялбай да барыр.

Галия. Ярый алайса, мин киттем. (*Китә.*)

Хыялбай. Чаубомбино! Пока! Иртәгә тагын кил.

Тазамат. Галия белән төксе сөйләшмә инде бүтән. Кыз кеше бит ул. Безне дус итеп йөри...

Хыялбай. Башны катырмале. Уйларга комачаулыйсың... Төбе тишек чәйнекне ямап, аны бензин багы итәргә була...

Тазамат (*хыялга янә бирелеп*). Шүрәлеләрнең исемнәре була микән? Буладыр. Алар да җан иясе бит, име, Хыялбай?

Хыялбай (*җен ачулары чыгып, сикереп тора*). Тазамат кына түгел, Казамат булып чыктың син, билләһи-валлаһи!

Шулвакыт алмагачның иң зур алмасы Хыялбайның башына дыңк итеп килеп төшә.

Хыялбай (*үрле-кырлы сикерә*). Ай, үләм, һай, башым ярылды! Беттем, беттем, башсыз калдым! Һай!..

Тазамат эчен тотып көлә.

Хыялбай. Ачу китереп көлмәле, ичмасам... Һай!.. Синең аркада космик кораб уйлап табалмый калдым... Башта бернинди уй калмады...

Тазамат. Яңа Ньютонның башын алма харап итте! Нишләрбез инде моннан соң? И, бигрәкләр дә кызганыч... Ха-ха-ха!

Хыялбай җиргә иелеп алманы ала да ачу белән еракка ыргыта. Кинәт дөнья караңгылана. Күк күкрәгәндәй, нидер дөберди, шалтырый. Ерактан тавыш ишетелә.

Серле тавыш. Ялгыштың, Хыялбай, алманы ыргытып бик нык ялгыштың. Ул алма эчендә син уйлап табарга хыялланган космик корабның сызымнары бар иде. Ялгыштың, Хыялбай! Хыялыңны харап иттең. Ул алманы табу өчен сиңа шактый тир түгәргә туры киләчәк!

Дөнья яктыра. Бакчаның эзе дә калмаган. Урман. Аланлык. Малайлар элекке халәтләрендә басып торалар.

Тазамат (*як-ягына карана*). Кая килеп эләктек без, Хыялбай?

Хыялбай (*ачу белән*). Кая булсын, әкияткә! Әкият-мәкият, шүрәле-чүрәле дип башны катырдың бит. Менә сөен инде хәзер!

Тазамат. Чыннан да, әгәр дә без әкияттә булсак, нинди кызык булыр иде, име, Хыялбай? Кайткач, малайларга сөйләп, күзләрен дүрт иттерер идек, име?!

Хыялбай (*үчекләп*). Име, име... Синең аркада космик кораб югалтып...

Хыялбай, бер ноктага текәлеп, катып кала.

Тазамат. Хыялбай, Хыялбай, дим. Нәрсә булды сиңа?

Хыялбай иреннәрен кыймылдата, нидер әйтә, тик тавышы ишетелми.

Тазамат. Ни булды сиңа, Хыялбай? Телеңне йоттың мәллә?

Хыялбай (*тотлыга-тотлыга*). А-а-анда... ке-е-емдер... ба-а-ар!

Тазамат Хыялбай төртеп күрсәткән тарафка карый.

Тазамат. Мин беркемне дә күрмим бит.

Хыялбай. Ә-ә-әнә... те-е-егендә... ка-а-ара.

Тазамат. Әй, кем бар анда? Чык монда! Без синнән барыбер курыкмыйбыз. Шулай бит, Хыялбай?!

Хыялбай. Шу-у-улай.

Агач артыннан башта Чүрәленең, аннан Түрәле белән Бүрәленең башлары күренә. Хыялбай Тазаматка елыша.

Тазамат. Чыгыгыз монда. Без сезгә тимибез.

Хыялбай (*пышылдап диярлек*). Ча-ак-акырма, Та-а-азамат, бе-е-езне... бетерә-ә-әләр бит алар...

Тазамат. Чыгыгыз, әйдә, курыкмагыз! (*Хыялбайга.*) Син дә курыкма. Күрәсең бит, үзләре дә шүрлиләр.

Хыялбай (*Тазаматка тагын да елыша төшеп*). Ми-и-ин ку-у-уркмыйм.

Башта Чүрәле, аннан Түрәле белән Бүрәле куркып кына агач алдына чыгып басалар.

Тазамат. Йә, таныш булыйк: мин Тазамат булам. Ә бу минем дустым — Хыялбай. Сезне кемнәр дип белик?

Чүрәле (*бераз шикләнеп*). Без — шүрәлеләр. (*Сул кулы белән маңгаена ике мәртәбә сугып ала.*) Мин — Чүрәле. Ә болар — Түрәле белән Бүрәле.

Түрәле белән Бүрәле, Чүрәле шикелле, үз маңгайларына ике мәртәбә сугып алалар.

Тазамат (*гаҗәпләнеп*). Сез шүрәлеләрмени? (*Хыялбайга.*) Әйттем мин сиңа, шүрәлеләр булырга тиеш дип. Күрдеңме инде?

Хыялбай. Кү-ү-үрәм...

Тазамат. Сез нишләп йөрисез монда?

Чүрәле. Без монда яшибез.

Түрәле белән Бүрәле. Әйе, без монда яшибез. Ә сез нишләп йөрисез?

Тазамат. Безме? (*Көлемсерәп.*) Без ни... (*Хыялбайга карый.*) ...сезне күрергә дип килгән идек.

Чүрәле, Түрәле һәм Бүрәле, бер-берсенә елышып, артка чигенмәкче булалар, агачка бәреләләр.

Тазамат. Курыкмагыз шулхәтле. Без сезгә тимибез, дидек бит. Шулай бит, Хыялбай?

Хыялбай (*башын селки*). Әһә.

Чүрәле. Без сездән курыкмыйбыз, сакланабыз гына.

Тазамат. Әйдә, килегез әле мондарак. Сөйләшик. Ачыктан-ачык. Нәрсәдән сакланасыз? Әйтегез. Күрәсез ич, безнең кулда бернинди дә корал юк.

Шүрәлеләр шикләнеп кенә малайларга якынлашалар.

Тазамат. Йә, әйтеп җибәрегез, нәрсәдән сакланасыз инде?

Чүрәле. Хәйләдән. Сез — хәйләкәрләр. Безне хәйләләп, бүрәнә ярыгына бармакларны кыстырмакчы буласыз.

Тазамат. Андый уйның башка да килгәне юк. Шулай бит, Хыялбай?

Хыялбай. Шулай. Андый уйның башка да... Һай! (*Башын тота*.) Алма!

Шүрәлеләр сискәнәләр.

Хыялбай (*куркуын онытып*). Малайлар, берәрегез алма тапмадымы? Шундый зу-у-ур! Яшел!

Шүрәлеләр елмаялар.

Түрәле. Алма бит агачта була.

Бүрәле. Алмагачта, диген.

Хыялбай (*өметсезләнеп кулын селти*). Тапмадык диегез инде, ичмасам. Карале, алай-болай тапсагыз, миңа бирерсез, яме?!

Чүрәле (*дустанә елмая*). Ярар. Тапкач та бирербез.

Хыялбай. Алдаламыйсызмы?

Тазамат. Хыялбай, ташлале шул алмаңны. Әйттеләр бит инде сиңа. Шактый тир түгәргә туры киләчәк, диделәр. Үзең әйтмешли, юк-бар белән шүрәлеләрнең башларын катырмале.

Хыялбай (*үпкәле тавыш белән*). Синең шул булыр инде.

Тазамат. Шулай итеп, сез безне хәйләкәрләр дисез, ә?

Чүрәле. Әйе. Һәм әшәкеләр дә. Сезнекеләр урманга килеп, учак ягалар да ниндидер тилерткеч су эчәләр, без аңламый торган сүзләр катыштырып җырлар җырлыйлар. Аннары бер-берсенә: «Син — хайван! Син — шүрәле!» диләр дә әүмәкләшә башлыйлар...

Түрәле. Утаткыч белән җәнлекләрне үтерәләр.

Бүрәле. Әллә нинди тозаклар куялар. Без аларны җыеп яшерәбез. Әле бүген дә сезнекеләрдән икәү тозаклар куеп йөри. Без башта сезне шулар дип уйлаган идек.

Тазамат. Борчылмагыз, без андыйлар түгел. Шулай бит, Хыялбай?

Хыялбай. Әйе, без андыйлар түгел. Гомумән, без андыйлар түгел. Без — әйбәтләр. Безнең башта бары... Һай! Алма!

Тазамат көлә. Шүрәлеләр дә аңа кушыла.

Тазамат. Бу алмаң белән көлдереп үтерәсең син безне, Хыялбай.

Хыялбай. Синең шул булыр инде...

Кинәт ботак сынган тавыш ишетелә. Барысы да сагая.

Тазамат. Курыкмагыз, өлгергән нарат күркәләре генә ул. Шулар җил искән саен коела. Чүрәле дус, теге тозак куючыларның кайсы якка киткәнен карап калмадыгызмы? Без аларны бу урманга икенче аяк басмаслык итәр идек.

Чүрәле. Без аларның кайда йөргәннәрен белеп торабыз. Хәзер алар (*кояшка карый*) гел туктый торган җирләрендә ял итеп ятарга тиешләр. Ә... аларны ничек итеп урманга аяк басмаслык итеп була соң?

Тазамат. Ничек итеп дип... Хәзер бер-бер хәйлә уйлап табабыз. Хыялбай, йәле, башыңны эшләт әле!

Хыялбай. Эшләтерсең монда. Алма төшкәннән бирле берни уйламый. Шул алмадан башка.

Тазамат. Ул алма турында онытып тор инде син, Хыялбай. Тозак куючы абзыйларны акылга утыртырга кирәк бит.

Уйга талалар. Ут сүнә.

ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Диюләр өне. Шартуар телевизор карый. Бер почмакта Карату утын түмәре күтәреп басып тора.

Карату. Шартуар хуҗам, кулларым өзелеп төшә инде, җәзагызны кире алсагыз сана.

Шартуар ишетми, бирелеп телевизор каравын белә.

Карату. Шартуар хуҗам, түмәрне идәнгә куярга рөхсәт итсәгез лә. Сез ашаганнан калган сөякне өч көн буе ялап йөрер идем.

Шартуар дәшми.

Карату. Алтыннан да кадерле хуҗам...

Шартуар (*кинәт чәрелдәп кычкыра*). Үтеррәм!

Карату куркуыннан түмәрен төшереп җибәрә.

Шартуар. Чебен урынына сытам! Туктыйсыңмы, юкмы, хөләпә!

Карату түмәрен алырга иелмәкче була.

Шартуар. Иелмәскә! Минем фәрманнан башка кыл да кыймылдатмаска дип күпме әйтергә була сиңа, тишек борын!

Карату үрә катып басып тора. Шартуар тынычлана. Телевизорны сүндерә дә Каратуга таба борыла.

Шартуар. Карату, җәзаны туктатам. Сиңа сүзем бар. Монда кил!

Карату. Шартуар хуҗам, аяк астыгызда олтан булыйм, тыңлыйм сезне!

Шартуар. Тыңла һәм хәтереңдә тот. Телевизордан әле генә бер кызыклы тапшыру карадым. Безгә эш чыгарга тора. Бик җаваплы эш. Кыскасы болай: унҗиденче кварталда, теге, шүрәлеләр аланында ике яшь адәми зат пәйда булган. «Чырмырбыр» телекомпаниясенең атаклы хәбәрчесе Ала-Кола шуларның бер төркем шүрәлеләр белән сөйләшеп торганын сиздермичә генә кинога төшергән. Безнең урманда ял итеп, һава сулап йөргән җанкыяр дусларыбызның арт сабакларын укытырга җыеналар. Сүзнең ни турында барганын аңладыңмы инде хәзер?

Карату. Бик яхшы аңладым, Шартуар хуҗам.

Шартуар. Аңласаң шул: хәзер үк җанкыяр дусларыбызны эзләп табасың, күрәсең, кисәтәсең. Шулай-шулай диген. Тизрәк таегыз моннан диген. Юкса, хәлләрегез мөшкел булачак, диген. Аңладыңмы?

Карату. Бик яхшы аңладым, Шартуар хуҗам.

Шартуар. Җә, нәрсә аңладың инде, тинтәккәем минем?

Карату. Хәлләре мөшкел булачагын аңладым, Шартуар хуҗам.

Шартуар. Яхшы. Түмәрне урынына куй да — күз алдымнан югал. Әгәр дә мәгәр фәрманны җиренә җиткереп үтәмәсәң, үзеңә үпкәлә — җәзаның иң катысын бирәчәкмен! Шылдымы, хөләпә?

Карату. Шылды. Бик яхшы аңлашылды, Шартуар хуҗам! Китәм. Барып җитәм. Әйтәм. Кисәтәм дә кайтам.

Китә. Шартуар ишекле-түрле йөренә.

Шартуар (*үз-үзе белән сөйләшә*). Әгәр дә мин болай итсәм, тегеләй була... Әгәр дә мин болай итсәм, тегеләй була... Юк, болай да булмый, тегеләй дә. Тукта! (*Маңгаена сугып ала.)* Шәп фикер! Уйлый торгач тәки таптым бит! Бар да соң инде үземдә баш! Тәмам адәм мәсхәрәсенә калачаклар икән бу бәндәләр. Эч катканчы көләселәр бар икән әле бүген! (*Башын кашып ала*.) Тә-ә-әк... Ала-Коланы чакырасы булыр. Килсен. Күрсен. Кинога төшерсен. Мине. Теге адәми затларны ничек итеп көлкегә калдырганымны да төшерсен сурәткә. Тә-ә-әк... Каяле, шалтыратыйм әле... (*Телефон көпшәсен ала, саннарны җыя*.) Бер-бер... йөз унбер... тагын бер-бер... тагын йөз унбер... Тә-ә-әк... Алло! Алло! Ала-Кола әфәндеме бу?

Ут сүнә.

ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Беренче күренештәге аланлык. Сәхнәдә — Тазамат белән Хыялбай. Бераздан, ух-вах килеп, Чүрәле, Түрәле һәм Бүрәле керә. Өчесе бергә ярыгына чөй кыстырылган бүрәнә күтәргәннәр. Чүрәленең билбавына нәни балта кыстырылган.

Чүрәле. Менә шушы бүрәнә инде ул. Безнең Шүрәле бабай бармакларын шушында кыстырган. (*Бүрәнәне җиргә куялар*.)

Тазамат. Карале, бу бит бик шәп тарихи экспонат! Ничек сакланган бу?

Чүрәле. Анысын бабай белә инде. Ул саклаган. Өч ел элек вафат булды бабай. Шуңынчы беркемне дә якын китермәде бүрәнәгә. Без ялгыш ярыгына бармак кыстырудан курыкты. Бу бүрәнәнең кайчан да булса кирәге чыгар әле, ди торган иде бабай. Менә бит, тәки бүген кирәге чыкты!

Хыялбай. Бу бүрәнәне, теге абзыйларны акылга утырткач, мәктәп музеена куярбыз, яме, Тазамат?!

Тазамат. Дуслар бирсә алып кайтырбыз.

Чүрәле. Безгә нәрсә, алырсыз. Без аны барыбер саклый белмибез. Шулай бит, малайлар?

Түрәле. Шулай, шулай.

Бүрәле. Шулай.

Тазамат. Җә, нишлибез? Кузгалабызмы?

Чүрәле. Бик вакыт. Тизрәк кыймылдарга кирәк.

Барысы да бүрәнәне күтәрергә дип иеләләр. Җәһәт кенәкүтәрәләр. Шулвакыт Шартуар белән Ала-Кола килеп керә. Ала-Кола киноаппарат аскан. Икесе дә кешеләрчә киенгән.

Шартуар (*шат елмаеп*). У-у-уххх! Маладсы, җегетләр, маладсы! Өмәгә бердәм тотынгансыз. Ала-Кола, кинога төшерә башла! Мине дә төшерергә онытма.

Тазамат, Хыялбай һәм шүрәлеләр берни аңламыйча, бүрәнә күтәргән килеш басып торалар. Ала-Кола кинога төшерә башлый.

Тазамат. Карале, ни... кем, апа...

Шартуар. Апа түгел, Шартуар абзаң булырмын мин, үскәнем.

Тазамат. Шартуар абзый, нинди өмә ул?

Шартуар (*гаҗәпләнгән булып*). Бә-ә-әй, әле сез өмә булганын белмичә эшлисезмени? Хуплыйм, хуплыйм. Маладсы! Дию әйткәч... Тьфү! Кеше әйткәч, аны кем дә эшли. Күрәм, сез үзегез башлап йөрергә яратасыз икән. Мондый асыл җегетләр белән җир җимертеп эшләргә була. Маладсы!

Хыялбай. Шулай да, абзый, әйтегез әле, нинди өмә соң бүген?

Шартуар (*имән бармагын өскә чөеп*). Бүген, үскәнем, би-и-ик зур өмә! Бүген, үскәнем... бүген... урман чистарту өмәсе! Бүген менә шундый бүрәнәләрне, корыган ботак-чатакларны бер урынга җыеп яндырабыз...

Чүрәле. Абзый, бу бүрәнәне яндырырга ярамый. Бу бүрәнә... (*Аңа «эндәшмә» дигән ишарә ясап, Тазамат төртеп ала.*)

Шартуар. Ярар, сезнеңчә булсын. Монсын яндырмабыз. Бу капка баганасына бик әйбәт икән. Әйдәгез, күтәреп торып арыгансыздыр. Илтеп куйыйк тиешле урынга. Ала-Кола, карап торма. Төшер киногa, төшер. Мине төшер. Аларны да...

Ала-Кола агачка сөялеп тә, иелеп тә, җиргә ятып та төшерә.

Тазамат. Шартуар абзый, безнең дуслар әйтә...

Тазамат Шартуарның койрыгын күреп ала. Шикләнә.

Шартуар. Әйт, үскәнем, әйт. Җә, нәрсә ди сезнең дуслар?

Тазамат. Шартуар абзый, сезнең артта койрык сыманниндидер әйбер асылынып тора...

Шартуар (*каушап*). Ә-ә-ә... Ниме... син аны әйтәсеңме? Ул бит ни... Ни бит ул... кәҗә тиресе. Билгә ураган идем. Мин дә ни бит... ырматиз! Һай ул билемнең сызлаукайлары! Кайчагында шундый итеп чәнчи — үләм дип торам! Шул ырматизга бернинди дә дару-фәлән уйлап таба алмыйлар... (*Сөйләнә-сөйләнә, койрыкны эченә яшерә.*)

Шартуар койрыкны яшергән арада Тазамат Чүрәленең колагына нидер пышылдый.

Тазамат. Шартуар абзый!

Шартуар. Әү, үскәнем!

Тазамат. Безнең Чүрәле дус әйтә, безнең өйдә шул ырматизны бетерә торган бик шәп дару бар, ди. Малайлар тиз алып килсеннәр мәллә? Өйләре ерак түгел аларның...

Шартуар. Өйләре ерак булмаса, тиз генә алып килсеннәр соң, алайса.

Тазамат. Бүрәле, Түрәле! (*Боларга күз кыса.*) Барыгыз, алып килегез шул даруны.

Тегеләр китәләр дә, куаклык артына посып, боларны күзәтеп торалар.

Тазамат. Һай, бик авыр икән бит бу бүрәнә. Малайлар әйләнеп килгәнче, җиргә куеп торыйк.

Бүрәнәне әкрен генә җиргә куялар.

Шартуар. Ала-Кола дус, хәзергә төшерми тор...

Ала-Кола агач төбенә утыра да аппараты белән кайнаша башлый. Шартуар йөренә. Тазамат, Хыялбай һәм Чүрәле үзара бәхәсләшкән кебек кыланалар.

Тазамат (*Хыялбайга*). Юк, син хаклы түгел. Минемчә, Чүрәле дөрес әйтә.

Шартуар боларның сүзләренә колак сала.

Хыялбай. Юк, минеке дөрес! Монда бер бармак кына сыя.

Чүрәле. Бәхәсләшмә инде, Хыялбай. Ике, дигәч, ике инде!

Шартуар (*сүзгә кушыла*). Ни турында бәхәсләшәсез, үскәннәрем?

Тазамат. Менә, Хыялбай әйтә, бу бүрәнә ярыгы бер бармак киңлегендә, ди. Ә без әйтәбез, Чүрәле белән икәү, ике бармак киңлегендә, дибез. Шулай икәнен Хыялбай үзе дә күреп тора. Барыбер сүзен бирми — бәхәсләшә.

Хыялбай. Минеке дөрес!

Тазамат. Әнә бит, һаман үзенекен сукалый...

Шартуар. Һи-и, юкка бәхәсләшәсез... Хәзер беләбез аны. (*Бер кулын бүрәнә ярыгына кыстыра.*) Хәзер беләбез... Тә-әк...

Шулвакыт Чүрәле билендәге балтасын ала да бүрәнә ярыгындагы чөйгә сугарга әзерләнә — Шартуар аны күрми.

Тазамат (*тавышын нечкәртә төшеп һәм сузып*). Дию абзы-ый!

Шартуар. Әү, үскәнем... Ә?

Шул мизгелдә Чүрәле балтасы белән чөйгә суга. Чөй чыгып оча.

Шартуар. Ой! Үләм! (*Урсәләнеп кычкыра, бәргәләнә*.) Төшер... әй, ычкындырыгыз бармакларны! Үләм!

Шулвакыт Шартуар дию халәтенә кайта. Ала-Кола аны кинога төшерә башлый. Башкалар дәррәү көлә. Бүрәле белән Түрәле яшеренгән урыннарыннан чыгалар.

Тазамат. Дию абзый, тынычланыгыз... Хәзер ырматизны бетерә бу дару... Ха-ха-ха!

Шартуар. Уһ! Аһ! Бармакларым минем... (*Ала-Колага ярсып кычкыра*.) Төшермә мине, төшермә! Ух! Сиңа әйтәм, тинтәк сарык!

Ала-Кола аның сүзләрен ишетми, төшерүен белә.

Тазамат. Дию абзый, ырматиз беттеме инде? Әллә һаман да чәнчеп-чәнчеп авыртамы?

Шартуар. Бетте, бетте... Тизрәк ычкындырыгыз! Үләм!

Хыялбай. Ычкындыруын ычкындырырбыз да ди. Ә син моннан соң нишләрсең микән, дию агай?

Шартуар. Тизрәк җибәрегез генә... Берни дә эшләмәс идем. Өйдә телевизор гына... тьфү!.. радио гына тыңлап ятар идем. Ала-Колау-у! Ала-Кола дускаем, төшермә инде кинога. Ух!..

Тазамат. Ярар, җибәрик без моны, дуслар. Тәүбә итте бит. Инде яңадан начар уй белән йөри икән... Ул чагында без аның белән башкача сөйләшербез!

Хыялбай. Әйе, без сезнең белән башкача сөйләшербез! Ишеттеңме, дию агай? Чүрәле, әйдә, чөеңне кире сук!

Чүрәле чөйне алып, аны бүрәнә ярыгына тыга да балтасы белән суга башлый.

Шартуар. Уф! (*Бармакларын бүрәнә ярыгыннан алгач, җиңел сулап куя*.) Сезнең белән бүтән очрашырга язмасын...

Тазамат. Дөрес сөйлисең, дию абзый. Бар, юлыңа ак җәймә.

Шартуар (*бармакларын угалап*). Үзегезнең юлыгызга ак җәймә... (*Мыскыл итеп*.) Үскәнкәйләрем! Күңелсез хәлгә тарсагыз — мине искә төшерерсез!

Уфылдап чыгып китә, аны кинога төшерә-төшерә Ала-Кола да китә.

Хыялбай. Каян килеп чыкты бу дию? Һич башыма сыйдыра алмыйм. Кем әйткән аңа безнең монда икәнлекне?

Чүрәле. Урмандагы һәр агачның колагы бар, Хыялбай. Әгәр акрын кыймылдасак, тозак куючыларның китеп барулары мөмкин. Дию ялгызы гына эш итмәс...

Тазамат. Шулай шул, Чүрәле дус. Дию тикмәгә генә ишарә ясамагандыр: «Күңелсез хәлгә тарсагыз — мине искә төшерерсез»,— диде бит. Җанкыярларны кисәтеп куюлары бар. Җәһәтрәк булыйк.

Кузгалырга әзерләнәләр. Ут сүнә.

## ДҮРТЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Сәхнә уртасында учак яна. Хәйбулат, авыз эченнән нидер көйли-көйли, учакка коры-сары өсти. Сулы казан тотып Бики керә.

Бики. Теге чишмә корыган. Кансирвы калайлары гына аунап ята. Инешкә үк барырга туры килде. (*Учак өстенә казан аса*.)

Хәйбулат. Бу кадәр озак йөргәч, мин сине чишмәгә баткансың дип торам. (*Көлә.*) Әле ярый суы кипкән икән.

Бики. Үзең бит, теге көнне, пычагымамыни бу чишмә безгә, дип, җыен чүп-чарны шунда тондырдың. Хәзер менә синең аркада инешкә чабарга туры килә.

Хәйбулат. Ничава, чишмәләр күп алар, бер җирдә корыса, икенче җирдән бәреп чыгалар. Әйдә, биштәрдәге ризыкларны, теге нәмәстәләрне ә-әнәү җәймәгә чыгарып сал. Сине көтә-көтә, минем эчтә бүреләр улый башлады инде.

Хәйбулат учак тирәсендә кайнаша. Бики биштәрдәге әйберләрне чыгара башлый.

Хәйбулат (*хыялга бирелеп сөйләнә*). Бики, теге, соңгы тозакка бик шәп куян эләксә, ә?! Сыйланыр идек тә соң синең белән!

Бики. Ашказанын котыртма әле, Хәйбулат абзый. Болай да авыздан сулар килеп тора...

Шулвакыт еш-еш сулап Карату керә.

Карату (*тегеләргә карап*). Уф, өлгердем бит тәки!

Бики кулына тоткан шешәләрне кире биштәргә яшерә. Каушаганы сизелә. Әле Каратуга, әле Хәйбулатка карый.

Хәйбулат. Син кем? Исәнмесез-саумысызың кая?

Карату. Исәнмесез-саумысыз! Минем исемем — Карату. Сезне кисәтергә килдем.

Хәйбулат. Килгәнсең икән, матур гына китә дә бир. Сау килеш. Юкса, сөякләреңне дә җыя алмассың! *(Бикигә карап.)* Йөриләр шунда кешенең тәмле ялын бүлеп. (*Каратуга.)* Бу хәтле дә җен-перигә охшасаң ошарсың икән. Нәрсә, урманда адаштың мәллә?

Карату. Юк, адашмадым. Мин сезне кисәтергә килдем. Тиздән монда шүрәлеләр килә. Сезнең арт сабакны укытырга!

Хәйбулат. Нәрсә?!

Карату (*куркып кала*). Шүр... шүр... шүр...

Хәйбулат. Күрсәтәм мин сиңа хәзер шүрәлене! Бики! Типкәләп озат бу карачкыны! Тормасын каршыда күзле бүкән булып...

Бики Каратуга таба атлый. Тегесе чигенә.

Карату. Мин бит... сезгә... изгелек... теләп... ә-ә-ә... се-е-ез!

Хәйбулат. Бики, дим!

Бики иелеп таяк ала. Карату чыгып кача.

Хәйбулат (*тынычлана алмыйча*). Вәйт, син аны, ә! Тинтәк тәре! Шулхәтле перигә әйләнгәнче эчмәсә! Шүрәле-шүрәле дип, әкият сатып, безнең белән сыйланмакчы була. Әле ярый, бәхете бар икән. Үзем тотынсам, сөяге дә калмый иде...

Бики. Дөньяда әллә нинди кешеләр дә була, име, Хәйбулат абзый?! Эзләп карасаң, безнең шикелле әйбәт кешеләр дөньяда бармак белән генә санарлыктыр әле ул, име?

Хәйбулат. Сөйләп торасың тагын син дә. Безнең шикелле шәп кешеләр дөньяда юк инде ул, юк!

Бики. Хәйбулат абзый, әллә минәйтәм, шулпа кайнап чыкканчы теге тозакны карап килимме? Бәлки, берәр куян эләккәндер?!

Хәйбулат. Бар, бар, Бики. Мин учакны караштырып торам. Куян эләккән булса, шунда ук суеп алып килерсең. Тунавын монда тунарбыз...

Бики китә.

Хәйбулат (*үзе алдында сөйләнә*). Һиндер-һиндер, лә-лә-лә... Әллә Бики юкта бераз нитеп... капкалап алыйм микән? Аш кайчан өлгерә әле ул. Шулай итмичә дә булмас...

Җәймә янына килә. Биштәргә кулын тыга. Шулвакыт Бики керә.

Бики. Хәйбулат абзый, сукыр тычкан да эләкмәгән!

Хәйбулат тиз генә биштәрдән кулын тартып ала.

Хәйбулат. Ә... Эһе-эһе... Эләкмәгәндер шул әле. Тозакны яңа гына куйдык бит... Мин әле монда... Ни... тоз эзлидер идем. Ашны кабып караган идем, тозы җитми сыман тоелды... Дөньяда иң сөймәгән нәрсәм — тозсыз аш. Тозсыз аш ул — куян эләкмәгән тозак сыман...

Бики. Мин үзем дә тозсыз аш яратмыйм. Баягынак бер савыт тозны ялгыш ашка койган идем. Эчтән шүрләп йөрдем. Хәйбулат абзый иманны укыта икән болай булгач, минәйтәм. Син дә тозлы аш яраткач, таман гына булыр әле...

Хәйбулат. Дөрес эшләгәнсең, Бики. Тик минем бүген, нишләптер, аш ашыйсы килми әле. Әллә соң булган ризыкларны капкалый торабызмы?

Бики. Сез ни дисәгез, шуңа риза инде мин, Хәйбулат абзый. Әйдә, аш кайнап чыкканчы...

Шулвакыт Тазамат белән Хыялбай керә.

Тазамат. Тәмле булсын ашларыгыз, абзыйлар!

Хәйбулат (*төксе генә*). Син әйтмәсәң дә тәмле була ул. Ни йомыш?

Тазамат. Бик зур үтенечебез бар иде, абзыйлар. Мәктәп сәхнәсендә «Шүрәле» турында спектакль куймакчы идек...

Хәйбулат. Анда минем ни эшем бар. Миңа димәгәе, «Кәҗә белән Сарык»ны куегыз... Хи-хи-хи! (*Кисәк көлүдән туктап*.) Шуннан?

Хыялбай. Шуңа чөй кыстырылган бүрәнә кирәк булды да урманга килдек...

Хәйбулат. Берегез генә сөйләгез һәм сүзегезне кыска тотыгыз!

Тазамат. Без андый бүрәнәне таптык. (*Сәхнә читенә карап кычкыра*.) Малайлар!

Чүрәле, Түрәле, Бүрәле, юри кыланып, бөгелә-сыгыла, ух-вах килеп, теге бүрәнәне күтәреп керәләр дә учак тирәсенә куялар.

Хәйбулат. Болар кемнәр тагын?

Тазамат. Болар — шүрәле булып киенгән безнең малайлар...

Хәйбулат. Шуннан...

Тазамат. Күреп торасыз, бу бүрәнәне сөйри торгач, безнең җеп өзәрлек тә хәлебез калмады... Сигезенче кварталда гына җигүле атыбыз тора. Буш итмәс идек, абзыйлар. Шунда хәтле генә илтешмәссез микән? Төшкә хәтле кайтып җитмәсәк, директор абый ачулана инде...

Хәйбулат. Директорыгызны әйтер идем... Бүрәнә күтәрергә бала-чага җибәрмәсә... Ярар, тиз генә илтеп тә куйдык, ди... Ә ул сезнең «буш итмәс идек» дигәнегез ни аңлата?

Тазамат. Безнең декорациягә-мазарга дигән акча бар, ие...

Хәйбулат. Ярар, сүз белән тамак туйдырып булмас... Бики! Тот, әйдә, теге баштан! Бу бала-чагадан котылып булмас... Буш итмәбез, дип тә торалар...

Икесе дә бүрәнәгә иеләләр, кулларын ярыкка кыстырып күтәрмәкче булалар.

Тазамат. Чүрәле, әйдә, булыш абзыйларга!

Чүрәле тиз генә чөйне сугып чыгара. Тегеләр җиргә егылалар.

Хәйбулат (*ярсып кычкыра*). Аһ, шайтан балалары! Кагыгыз чөйне җәтрәк! Аһ...

Бики. Үләм, Хәйбулат абзый, үләм!.. Ой!..

Тазамат. Ничек соң, абзыйлар, без корган тозак? Куяннарның бәргәләнүе күз алдына килдеме?

Хәйбулат. Аһ, син, эт баласы!

Тазамат. Ялгышасың, абзый. Мин дә синең кебек үк кеше. Тик синең кебек ерткыч түгел. Җәнлекләрне дә харап итеп йөрмим. Урманга да зыян китермим. Ә болар... (*шүрәлеләргә күрсәтә*) Чын шүрәлеләр. Алар да сезнең кем икәнлегегезне күптән белә...

Хәйбулат. Кулларны ычкындырыгыз, дим, сабакылар...

Тазамат. Анысы булмас инде, абзыйлар. Бер диюне ычкындырып карадык инде без. Акылга утырганга охшамады. Бәлки, сез авылга кадәр шушы бүрәнәне күтәреп кайткач, акылга утырырсыз...

Хәйбулат. Кара син аларны, йомыркалар тавыкны өйрәтә башлады... Кулларны ычкындырыгыз, дим!

Хыялбай. Тавышыгызны саклагыз, абзый. Кирәге чыгуы мөмкин.

Шулчак Хыялбай җәймә өстендә бер зур алма күреп ала.

Хыялбай. Алма! Тазамат! Малайлар! Теге алма бит бу!

Хыялбай алмага дип омтыла, әмма аны алырга өлгерми. Хәйбулат алмага җан көче белән тибеп җибәрә.

Хәйбулат. Кеше алмасына үрелмә, малакасус!

Кинәт беренче күренештәге кебек, дөнья караңгылана. Нидер шалтырый, дөберди.

Серле тавыш. Хыялбай! Иртәме-соңмы, син ул алманы табачаксың. Мин сиңа ышанам. Кешелекле бул, тугрылыклы бул! Тазаматтан үрнәк ал!

Дөнья яктыра. Беренче күренештәге бакча. Хыялбай алмагач төбендә ята. Тазамат эскәмиядә китап укып утыра.

Хыялбай. Әллә төш күрдем инде мин. Бернәрсә дә аңламыйм. Шүрәлеләр, диюләр, җанкыярлар... Кызык!

Тазамат. Мин дә бит синең янында идем, Хыялбай. Хәтерләмисең дә. Әкият дөньясында булдык бит!

Хыялбай. Шулай бугай шул. Карале, Тазамат, теге шүрәлеләр нишләде микән инде?

Бакчага Галия керә.

Галия. Бөтен дөньяны бетереп сезне эзләп йөрим. Баксаң, сез монда алма санап ятасыз икән!

Тазамат. Алма санамыйбыз, ә китап укыйбыз. Шулай бит, Хыялбай?

Хыялбай. Шулай. Китап укыйбыз. Әкият китабы!

Галия. Күрше авылда бер кызык хәл булган әле. Ишеттегезме?

Тазамат. Нинди кызык ул? Сөйләп җибәр, булмаса!

Галия. Ике абый урманнан бүрәнә күтәреп кайткан, ди. Ярыгына бармакларын кыстырып...

Тазамат белән Хыялбай сагаеп тыңлыйлар. Хыялбай яткан җиреннән сикереп тора. Башына бер алма төшә. Ул аны сизми.

Галия. Шүрәлеләр кысты, дип әйтәләр, ди. Урманга бүтән аяк та атламыйбыз, дип әйтәләр, ди... Тагын нindидер алма шартлады, дип әйтәләр, ди...

Тазамат белән Хыялбай шаркылдап көлә башлыйлар. Галия сәерсенеп карап тора-тора да үзе дә аларга кушыла.

Пәрдә.

## ШАГЫЙРЬ ҺӘМ АНЫҢ ИҖАТЫ ХАКЫНДА КҮРЕНЕКЛЕ ӘДИПЛӘРНЕҢ ФИКЕРЛӘРЕ

Соңгы елларда төрле жанрларда шактый яңа исемнәр танылуы аеруча сөендерә. Ләбиб Лерон да профессиональ дәрәҗәсе өлгереп җиткән сәләтле язучы, шигырьдә, прозада бердәй иркен йөзә. Әсәрләренә терелек, табигыйлек, камиллек биреп торган хасият — юмор, сатира. Әсәрнең җаны — бала күңеленә ачкыч ул. Монда табыш — кыскалык гарантиясе, калганы укучы күңелендә дәвам итә, аның тормышка мөнәсәбәтен билгеләшә.

Ләбиб иҗатындагы төрлелек сәләтенең колачын күрсәтеп тора. Актив эшли ул, шигырьләр, хикәяләр белән бергә, замана әкиятләре тудырды, пародияләре белән дә танылып өлгерде. Курчак театрына да, миниатюралар театрына да җитешә, язучы үз стихиясендә әнә шулай иркен ачылырга тиеш.

*Шәүкәт Галиев,*
Татарстанның халык шагыйре, Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты

* * *

Ләбиб һәр жанрда да үзен иркен хис итә. Шунысы әһәмиятле: шагыйрь балалар белән нәкъ аларча сөйләшә, дустанә аралаша. Шигырьләрендә, кечкенә шаян хикәяләрендә бернинди акыл сату юк, акыллы булып кылану юк. Ләбибнең әсәрләрендә бала үз дөньясын күрә, шатлана яисә үзенчә борчыла...

*Зөлфәт,*
Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты

* * *

Ләбиб татар балалар әдәбиятына да, балалар күңеленә дә өстәмә байлык булып урнашырлык шигырьләр таба ала. Табышын балаларча җитез хәрәкәтләр, тиз үзгәрешләр аша уздырып, укучы күңелен үзенә ияртә. Аның вакыйгаларына биреләсең дә, шомалык һәм ритм турында онытасың, бары укыйсы гына килә. Хикмәт — үзгәрештә, вакыйгаларда һәм хәрәкәттә генә дә түгел — Ләбиб сәнгатьчә тәэсир итүнең күптөрле алымнарын сиземләп яза, шуның белән безне үзенең тагын да зуррак мөмкинлекләре барына ышандыра. Ләбиб Лерон балаларны уйлата, нечкә күңелле, кешелекле, шәфкатьле итә торган шигырьләр язарга омтыла.

*Рөстәм Мингалим,*
А. Алиш исемендәге премия лауреаты

* * *

Ләбиб Леронның иксез-чиксез шигъри иҗат мәйданында үз токкан юлы, үзе генә аралаган сукмагы, үз өлкәсе бар. Ул — юмор-сатира. Яшь язучының бу өлкәдәге эзләнүләре һәм шиксез уңышлары аны профессиональ сыйфаттагы әдәбиятка сукмак салучы яшь әдип дип атарга мөмкинлек бирә.

Ләбибнең көлүе — әче, мыскыллы, шәхесне юкка чыгаручан түгел, ә сыгылмалы, ипле, әмма һич кенә дә килешүчән булмаган көлү. Икенче төрле әйткәндә, аның юморы тупас хахылдау булмыйча, зыялыларча тирән мәгънә салынган эчке елмаю булып тора.

Ләбиб Лерон лирикада да ипле. Ул шигырьдә әтәчләнми, чәчрәп кычкырмый, бер стакан суда тайфун уйнатмый.

Л. Леронның юморны аерыбрак яратуы аның юмористик әсәрләрне проза белән сынап каравыннан да күренә. Аның оста сюжетлы, нечкә кинаяле, культуралы телле кечкенә проза әсәрләре игътибарны үзенә җәлеп итә.

*Гәрәй Рәхим,*
Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты

* * *

Ләбиб Лерон инде җитди язучы һәм аның язмышы әдәбият белән, халык язмышы белән гомергә бәйләнгән.

Беренчедән, ул — үткен күзле яшь каләм. Әдәбият язмышы белән ул ныклап кызыксына, укый, һәм мәкаләләре, һәм шигырьләре, һәм пародияләре белән бүгенге мәсьәләләргә мөнәсәбәтен белдерә, ягъни ул — актив, оператив язучы. Икенчедән, Ләбиб — балалар әдәбияты өчен җан атучы шагыйрь, җитди шәхес. Ул балалар өчен туктаусыз иҗат итә. Чөнки ул — тумыштан ук балалар язучысы.

Өченчедән, Ләбиб ул — миһербан иясе, кече күңелле кеше, әдәбиятны, кайберәүләр кебек, мин-минлек күрсәтү мәйданы итеп түгел, җигелеп, авыр йөк тартыр өчен сайлаган егет. Боларның барысы да — Ләбибнең өлгергән язучы икәненә дәлил.

*Рабит Батулла,*
Г. Исхакый исемендәге премия лауреаты

## ЭЧТӘЛЕК

### ТӨСЛЕ ШИГЫРЬЛӘР

Татар баласы
И ямьле дә соң дөнья!
Татар теле дәресендә
Хәерле иртә!
Сизми калганбыз...
Көзге бакчада
Бакчабызда бер бала бар...
Буталмыш илендә
Бу — кайвакыт? Әйт, балам!
Кышкы сурәт
Радиога салкын тигән
Чаңгы белән дус булсаң
Көяләй
Телевизор караганда
Минем батыр куяным
Түзмәдем
Йөри торган урындык
Гөлләр рәхмәте
Песи булсаң иде
Хуш киләсең, Яңа ел!
Яз — бәйрәмнәр фасылы
Әни бәйрәме
Көлә-көлә кем килә?
Апрель
Кояшлы яңгыр
Нәкыя
Казлар һәм бәбкәләр
Нәни димәгез миңа
Кояшны кочкан малай
Җәй көтә безне...
Соклангыч дөнья
Миңлегата борчак ата
Җил көймәсе
Мәче балалары
Кояш — энем уенчыгы
Сабан туе, Сабан туе...
Сәбәп нидә?
Марат барган җылы якка...
Автобушлар
Көзге кирәк
Җәйге бәхәс
Болан баласы
Бакалар
Без — табигать баласы
Яңгырның ял көне
Светофор — тәмлетамак?!
Милиционер абый
Үрдәк хыялы
Сарут
Әнис
Куяннар санамышы
Ачуландым
Сараватта кем ята?
Булышчы

Кем бәхетле?
Үзенә охшаган
Гаҗәп хәлләр
Арыган малай зары
Августка кереп барабыз...

БӨТЕРЧЕК ҖЫРЛАР

Бишек җыры (*Татар халык көе, Разыя Еникеева эшкәртүендә*)
Чума үрдәк, чума каз (*Татар халык көе, Разыя Еникеева эшкәртүендә*)
Зөһрә кыз (*Фәннүр Галимов көе*)
Керпе шатлыгы (*Разыя Еникеева көе*)
Җиләкләр (*Разыя Еникеева көе*)
Көчегем (*Зиннур Гыйбадулла көе*)
Күбәләк (*Разыя Еникеева көе*)
Яфрак бәйрәме (*Разыя Еникеева көе*)
Тауда (*Разыя Еникеева көе*)

ШИГЪРИ ӘКИЯТЛӘР

Акмамык һәм Улбайадаш
Кәҗә белән Сарык
Аучы Барый
Кырлай юлы тап-такыр...
Убырлы себеркесе
Әкиятче малай

КИРЛЕ-МЫРЛЫ КИҢӘШЛӘР

Иртә уянасың килмәсә...
Җылыйсың килсә...
Батыр булсаң...
Матур булсаң...
Сүз тыңлыйсың килмәсә...
Табигатьне яратсаң...
Китап бүләк итсәләр...
Клоун булсаң...
Атаклы әләкче булыйм дисәң...
Кешегә чокыр казысаң...
Саран булсаң...
Уйныйсың килсә...

ХИКМӘТЛЕ ХИКӘЯТЛӘР

Әбием, әнием һәм мин
Җиләктән кайтканда
Безнең очта
На-а, бахбай!
Үскәч
Бәхтияргә эт кирәкме?
Яратам
Гает бәйрәме

ӘКӘМӘТ ӘКИЯТЛӘР

Мин чәчтем кишерне!
Шүрәле абзый шүрләде
Зөһрә кыз — безнең авылдан
Бах-бах! Гөрс-гөрс!..
Хыялый Акбай
Мактанчык Мырыйнур

Тәгәрмәчле чана
Яшел куык
Сәяхәтче Фим-Фом, укымышлы Кәҗә яки аларның Алдарстан илендә күргәннәре
Биш бармак
Мики-ки-ки!
Мәче малае Шукбай
Кикрикҗан белән Бүртәй маҗаралары
Чык, кошчык һәм кояшчык
Кәҗә угылы Кәҗәми
Юрисүричүп
Күзге кыйпылчыгы
Татлы әкият
Балыкчылар
Хыял
Киребеткән
Яңа ел әкияте
Тычканнар туе
Борчак шыттырам
Шурулла белән Шүрвәли
Борчак боткасы
Кое һәм борын
Язгы әкият
Сары әкият

КЕЧТЕКИ ӘКИЯТЛӘР

Канатлы сыер
Укымышлы сарык
Куркак күркә
Сагыз чәйнәүче кәҗә
Тавык сандугачмы?
Канатлы болытлар
Ташлар ахмак түгел
Эскәмия — матай
Акбай менгән читәнгә
Ашамсак каз
Шагыйрь бүре
Балыклар да укый
Сәгать күкесе

МӘЗӘКИЯТЛӘР

Кипкән Балык... ачлык игълан итә
Кыхмырый, Мыхмырый һәм Шыхмырый
Замана балалары
Шөгыль
Син — супербала?!
Кире уйлады
Транзистор үч ала
Алсу алма
Дөге боткасы
Бәрәңгетор
Йөз процент
Ике чиләк су
Инша
Очты, очты каргалар...
Камилнең көләсе килә
Попугай
Кабак бәлеше
Пирамида

Чеметерелиун йолдыз
Һичшиксез шулай булачак!..
Эләкте
Шәп итте
Тишек хәтер
Автопортрет
Каткан прәннек
Фокуска каршы — фокус
Бәхәс
Шамакай
Утлы туп
Кушамат
Көтәбез
Чын күңелдән
«Тала ике беләгем...»
Батыр малай
Суперчана
Бонжур, малай!
Сыбызгы

КӘМИТЛӘР

Чәпәләй һәм Тәпәләй маҗаралары
Аңгыра сарык җүләре
Яңа ел биштәре
Без барабыз бәйрәмгә
Урмандагы тамаша

Литературно-художественное издание

Для детей юношества

**Лябиб Лерон**
(Леронов Лемон Леронович)

Я ОБНИМАЮ СОЛНЦЕ

Стихи, песни, сказки, пьесы-сказки

*(на татарском языке)*

Редакторлары *Л. Ә. Гыйззәтуллина, Н. Р. Акмалов*
Бизәлеш редакторы *Л. С. Золондинова*
Техник редакторы *Ә. С. Трофимова*
Корректорлары *Т. Н. Сәгъдуллина, Г. Р. Сафиуллина*
Компьютерда биткә салучысы *Л. Г. Зиргизова*
Рәсемнәрне компьютерда эшкәртүче *Э. Ф. Нурмөхәммәтова*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 21.01.2004. Форматы 60 ә $90^1/_{16}$. Офсет кәгазе. «Школьная» гарнитурасы. Офсет басма. Басма табагы 19,0 + форз. 0,25. Нәшер-хисап табагы 11,88 + форз. 0,39. Тиражы 3000 д. Заказ Я-845.

«Мәгариф» нәшрияты. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.
Издательство «Магариф». 420111. Казань, ул. Баумана, 19.
Тел./факс (8432) 92-57-48.
http://magarif.kazan.ru
E-mail: magarif@mail.ru
«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы. 420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.